

# ГАЗИНУР МОРАТ




**Шигырьләр, поэмалар**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос = Тат) – 5
М 66

**Морат Газинур**

М 66 Төнге әверелеш: Шигырьләр, поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 399 б.

Табигать һәрбер кешене ирекле итеп яралта. Шуңа күрә аның өчен бу дөньяда иректән дә кадерлерәк берни дә була алмыйдыр. Әлеге мәҗмугада тупланган шигырь һәм поэмаларда шагыйрьнең җан хөрлеге, шәхес иреге турында уйланулары үзәккә алына.

ISBN 5–298–04117–5

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Газинур Морат, 2005

# I БҮЛЕК





## *Вакыт безне ваксытмады бугай*

*Вакыт безне ваксытмады бугай,*
*Ачыкканда бирде икмәген.*
*Елмайтты да, елатты да еллар,*
*Тик барыбер елак итмәде.*

*Вакыт безне ваксытмады бугай,*
*Күшеккәндә бирде чикмәнен.*
*Какса — какты, сукса — сукты еллар,*
*Тик барыбер сукбай итмәде.*

*Вакыт алай ваксытмады бугай,*
*Иманага бирде Даланы.*
*Еллар безне иманасыз итте,*
*Тик имансыз итә алмады.*

*Вакыт безне ваксытмады бугай...*

## ГАЛӘМИ ӨН

Айда, диләр, сәер өн бар,
Айда, диләр, шундый хәлләр.
Әгәр Күкләр өнсез торса,
Сәер булыр иде мәгәр.

Әгәр Күкләр өнсез калса,
Туфан кубар иде күптән.
Безгә азан мәкаме дә
Кайтаваздай иңгән Күктән.

Кайтаваздай һәр ярымай
Кунып калган манарага...
Галәми өн мәкаменнән
Ходай бирмеш таң ярала.

Галәми өн мәкаменнән
Яраладыр илаһи моң.
Моң сүрәсе булып иңгән
Һәрбер Сүзе Илаһының.

Айда азан ишетелгән... —
Җирдә йөри шундый хәбәр.
Әгәр Күкләр өнсез торса,
Сәер булыр иде мәгәр...

## ШӘМАИЛ

Изге Айга карап улашканда,
Ырлашканда шайтан өере,
Ай, мәчетле шәмаилләр торган
Түр башында татар өенең.

Түр башында шәмаилләр торган.
Шанлы, данлы, ханлы чаклардан
Бу нигезне шайтан оялаудан
Көрси аяте дә саклаган.

Шул аятьне күңел түрләренә
Онытканбыз ләкин эләргә.
Яшәп ятыш менә — шайтан кебек —
Фәрештәсе качкан эргәдә.

Гаҗәп түгел — соңгы пәйгамбәрең
Торып утырса да кабердән.
Ни көтәсең — сыңар чабатасын
Түр башына элгән дәвердән?
Ни көтәсең?

Гаҗәп түгел — Хозыр Ильясның да
Килеп төшсә сыртка таягы.
Әлиф кебек кадим Хәлфә үзе
Шул таякка йөргән таянып.

Гаҗәп түгел — борынгы бер бабаң
Сугып имгәтсә дә билеңне...
Шәмнәр түгел — шәмаилләр торган
Түр башында Татар Иленең.

## КАНАТЛЫ БАРС

Очып түгел — тәпиләп тә
Ничә гасыр кичелгән...
Очар иде — чарасы юк —
Канат очы киселгән.

## БУ ХАЛЫК...

Нужасын да, әйе, мазасын да,
Казасын да күргән бу халык.
Мең алданып, алдануга күнгән,
Талануга күнгән бу халык.

Дөньяның бар шатлыкларын җыеп,
Яңадан бер бүләсе иде.
Әткәй-әнкәйләрнең күзендә дә
Бер куаныч күрәсе иде.

* * *

Ил корабын күптән упкын йоткан,
Дию йоткан башын алыпның.
Ярык тагаракта Идел кичеп
Яткан мәле әле халыкның.

Аваз килә Идел төпләреннән:
Сез кичәргә тиеш Иделне.
Шулай гына коткарырга мөмкин
Ирегеңне, Туган илеңне.

## ХӘТЕР КӨНЕ

...Тагын кемнәр бисмилласыз
Укый анда хәтемне?
Хәтернең дә хәтәре бар,
Хәтәрнең дә хәтере.

Хәрабәдәй пыскый хәтер,
Ханбикәдәй моңая...
Ходайның һәр бирмеш көне
Хәтер көне болай да.

Хәттин хәтәр хәтер көне
Безнең һәрбер көнебез.
Яндырылган дастаннарның
Ахак кузы, көле без.

Зилзиләдән гөлләр түгел —
Көлләр калган сибелеп...
Кем җиңелгән җиңә-җиңә,
Кемнәр җиңгән — җиңелеп.

Хәтәрдән дә хәтәр хәтер.
Ул — саваплы каргыш та.
Казый абзый шул хәтерне
Куйган, имеш, тавышка.

Тавышланып йөрмәсеннәр
Йөгәнсезләр, янәсе;
Хәтер түгел — хәмер кирәк
Сиңа, Хода бәндәсе.
Җир сукала, иген ик син,
Йә аркан иш... комлыкта...

...Ә безгә шул тавыш-тынсыз
Качу кирәк коллыктан.
Безгә очып китү кирәк
Вакыт аккан уңайга.
Ходайның һәр бирмеш көне
Хәтер көне болай да.

* * *

*Р.К.*

Булмаса халыкның
Әгәр дә үз Иле,
Илбасар телендә
Җыр язар шагыйре.

## АРАН

Бәйсезлегең бәйдә бәргәләнә,
Бәйсезлегең бәйле әлегә.
Бәйгеләрдә бәйге тоткан кавем,
Бәйсезлегең тоткын хәлендә.

Бәйгеләрдә бәйге тоткан Атың
Тышауланган килеш аранда
Сугымчыны көтә...
Араннарда
Атлар бетеп барган заманда

Сугымчылар арта: суга алар,
Күсәк белән суга Атыңа.
Атсыз йорттан мал-бәрәкәт китә,
Дәүләт китә... Арба ватыла.

Атсыз да һәм Ватансыз да калгач,
Үзең җигеләсең арбага...
Бүген әнә тышауланган Атың
Сугымчыны көтә аранда.

Күзендә — яшь, юатырга теләп,
Җиләс җилләр ялмый ялларын.
— Коткар, Хуҗам, — диеп, Атың бүген
Шәкүр картка гүя ялвара.

— Коткар, Хуҗам, — диеп, Атың бүген
Аран аратасын кимерә.
Йортың, җирең, телең таланганда,
Ат карагы булсын иләндә.

Ат карагы булсын — йолып алсын
Арандагы тоткын Атыңны...
Бу җиһанда Аты-малы качкан
Күп араннар инде ватылды.

Кемнәр анда Атлар аранын да
Хөр биләмә диеп атады?
Юк, араннар бәйсез була алмый,
Бәйдә яшәгәндә Атлары.

Атны бүген урлап чыгу кирәк,
Урлап чыгу — башка чара юк.
Артта — Ил-йорт.
                    Алда — имперфронт —
Чигенергә инде чама юк.

## МОНАЗАРА

Пишкадәмнәр арасында
Моназара һаман:
Ни аңлата татар үзе,
Ни аңлата Казан?

Аңлаешсыз булдык...
Ахры,
Безгә шулай язган...
ТАРлыктан — татар, КАЗАдан
Яралгандыр Казан.

## САБАК

Уртак малны эт тә җыймас,
Эт тә җуймас чаманы.
Адәм башын адәм ашар,
Килсә этләр заманы.

Эт көненә калыр халык,
Эт көненә калыр ил.
Эт ялаган сөякне дә
Тарткалаучы табылыр.

Табыныңа ыргытырлар
Калдык сынык-санакны.
...Уртак малны этләр ашый —
Дүрт гасырлык сабактыр.

## СУСАНИН

Тарихларны кичә-кичә
Хәлдән тайдык. Сусадык.
Юл сорадык чишмәләргә —
Юл күрсәтте... Сусанин.

Эзләп киттек чишмәләрне —
Чишмәләрне тапмадык...
Дәверләр куйган капкынга
Кемнәр генә капмадык та,
Кемнәр генә капмадык.
Капкында да Тәңре хакын,
Алла хакын хакладык.

Без дә чыгарбыз хак юлга —
Гасырларны кичәрбез.
Ирек дигән чишмәләрнең
Ятып суын эчәрбез.

Без дә чыгарбыз хак юлга.
Юллар уң булсын!
Амин!
Каршыда — җиде юл чаты,
Юл чатында — Сусанин (!)

Килбәте шул ук. Искечә.
Нияте, бәлки, үзгә?
Белмибез — әллә адашкан,
Әллә юл сайлый безгә.

## КИСТӘН

Илендә бер бүки идек,
Үги идек, дисәм,
Баскынның үз башына да
Килеп төште кистән.

Үз кистәне килеп төште,
Бүре аулый торган...
Бүредән син читтәрәк йөр,
Сарык булсаң, туган.

Бүредән син читтәрәк йөр,
Карган шунда, сүген.
Тик онытма — ул бит бүре,
Ул бит бүки түгел.

# КАЗА

Не спи, казак: во тьме ночной
Чеченец ходит за рекой.

*А. Пушкин*

## 1

Бөркете юлыкса казага,
Кыялар ярдәмгә киләдер.
Заманнар үзгә дә, тик менә
Казалар үзгәрми нигәдер.

## 2

Кыясы тарыса бәлагә,
Оясын яклыйдыр шоңкары.
Козгыннар казынган оядан
Казалар китсә дә, шом калды.

## 3

Казага юлыкса юлында,
Халык та сыгыныр шаһ иргә...
Кай ара назыйргә әйләнгән
Зинданнар илендә шагыйрь дә.

## 1995 ЕЛ, 9 МАЙ

Чарасыз калган фәрештә
Кулына сур алган чакта,
Ил-халыклар бер-берсеннән
Ярлыкау сораган чакта,

Сугыш ачып йөрде баскын
Бөркетләр яшәгән якта...

## БАЛБАЛЛАР ИЛЕ

Бу илдә табынып кына
Яшиләр.
Һәрбер чатта —
Балбаллар.
Кайсы — иләмән,
Кайсы атланган атка, —

Кулында — кылыч.
Билендә —
Алтатары.
Кичәге.
Ничә җанны кыйды икән
Бу алтатар, ничәне?

Кемнәр каны саркый икән
Кылычы кынысыннан?..
Әмер генә булсын —
Җайдак
Кабат яу чабар сыман.

Кабат яу чабар сыман ул —
Иңдерелсен тик әмер...
Илдә таш балбал ишәйсә,
Башларга бетә кадер.

Илдә балбаллар ишәйсә,
Кадер бетә Аллага.
Ә бу илдә көн итәләр
Табынып таш балбалга.

## ЧЫПЧЫК КАРАГЫ

Чыпчыклары илнең җим тапмыйча
Чалкан ятып үлгән чакларда,
Теләнчеләр йөргән авылларда,
Теләгәннәр башны сакларга.

Теләнчеләр йөргән сала буйлап,
Биштәренә салып өметен.
Ә мин менә гасыр азагында
Өметләнмәскә дә күнектем.

Әллә инде безнең якларга да
Иялэште чыпчык карагы —
Чыр-чу сирәк хәзер...
Ни калада,
Ни салада чыпчык калмады.

Азау ярган гасыр азагында,
Язмышларның агач атында
Утырабыз менә, хәер эстәп,
Гомерләрнең урам чатында.

Өстә — чикмән. Гүя качаклар без.
Көек исе килгән җилләрдән
Хәбәр көткән кебек утырабыз,
Хәер эстәп Туган илләрдә.

Теләнәбез телсез калмас өчен,
Урам телле соң без ник һаман?!
Телең өчен тезләнергә була,
Теләнергә калгач бик яман.

Ашлы булу — башлы булу, имеш,
Кем бар ашка бездәй баш орган?!
Ил башына баш органнар килсә,
Ил дә чери башлый башыннан.

Башлы булу — башлык булу, имеш,
Шулай, имеш, ташка басылган.
Ашлыдыр шул, әйе, башлыдыр шул,
Йөри белгәч халык башыннан.

Ә без менә гасыр азагында,
Гомерләрнең урам чатында
Утырабыз һаман, хәер эстәп,
Язмышларның агач атында...

## ЗАМАНА

Бәреләдә сугыла ул,
Бәреләдә... сүгенә.
Әлләширбәт, әлләшәраб
Тәме килә сүзеннән.

Бәреләдә сугыла ул,
Бәреләдә... сүгеләә.
Әлләзурлык, әлләхурлык
Исе килә үзеннән.

## КАРАБАХ

Яшең кипмәс —
        үз җирендә
Мөһаҗир булып тусаң...
Өеңдә дә җәнҗал кубар,
Илеңдә дәҗҗал булса.

# КОШ ХОКУКЫ

*Туфан Миңнуллинга*

Хакны әйтергә дә хокук кирәк.
Әйтим дисәң ярып турысын,
«Птичье право» дигән гыйбарәсе
Искә килеп төшә урысның.

Һава ярып, әнә кошлар оча,
Кош тоткандай яңа күзләрең.
Күкне иңләп очкан кошка баксаң,
Искә килеп төшә үз хәлең.

Үз хәлеңне күршеләрдән сора —
Ут-күршеләр яши күршеңдә...
Хакны әйтергә дә хокук кирәк,
Кош хокукы кирәк кешегә.

Ут-күршеләр әнә ут салганнар
Тарихыңа синең, телеңә.
Ничә гасыр тарих пыскып ята, —
Казынабыз бүген көлендә.

Хакны әйтергә дә хокук кирәк,
Хакны әйтүчеләр илдә бер.
Кошлар хокукына ия җаннар
Кеше хокукына иядер.

Хаклылар да, хаксызлар да сыйган
Империя дигән калыпка.
Империя калыпларын ватып,
Хөр мәмләкәт төзи халыклар.

Ирек яуларга да хокук кирәк,
Сорап алып булмый irekне.
Кошлар хокукына ия халык
Бәйсез халык — димәк, ирекле!

Һава ярып, әнә кошлар оча,
Син очасың бары төшеңдә.
Кеше булырга да хокук кирәк,
Кош хокукы кирәк кешегә.

## БОЛГАР

Эргәсендә чиркәү тора.
Ирегемне чикләп тора.
Галиләре кол ителгән —
Хан төрбәсе биктә тора.

# ТӨНГЕ РИГАДА ЛАТЫШ КЫЗЫ БЕЛӘН СӘЯСИ СӨЙЛӘШҮ

Бездә Ирек мәйданы бар,
Сездә — Ирек һәйкәле.
Һәйкәлгә ничек барасы,
Латыш кызы, әйт әле?

Сәждә кылыймчы сезнең дә
Азатлык алласына.
Һәйкәлгә ничек барасы
Мин — татар баласына?

Ә син, юллар ябык, дисең,
Анда, дисең, атышлар —
Латыш җирендә кан коя
Урыслар һәм латышлар.

Латышлар илендә, дисең,
Интерфронт, ОМОНнар...
Җантимер итеп урысны
Яши бирә Гапоннар.

Без дә, дисең, күп татыдык
Кимлекне вә тарлыкны.
Тик җиңеп булмый Иреккә
Һәйкәл куйган халыкны.

Сездә бар Роза Турайдас,
Бездә бар Сөембикә...
Тарихлар сере — йозакта,
Тарихлар сере — биктә.

Син дә юллар ябык, дисең,
Азатлык алласына.
Әйт алайса, нишләргә соң
Мин — татар баласына?!

*Дубылты. Гыйнвар, 1991*

# АЧЛЫК

*Поэма*

> ...Ирек хакына шәһит китү генә мәгънәгә ия була. Тик шул чагында гына кеше үзенең бөтенләй үк үлмәячәгенә ышана...
>
> *Альбер Камю*

## 1

Идел-йортлы ил идек,
Идел кичәр ир идек,
Иделләргә төн иңде,
Илләргә кайгы килде.

Тәхет өчен талашып,
Үзара якалашып
Яткан чакта биш надан,
Тотты Мәскәү якадан.

Тотты Мәскәү умырып —
Йә, кем безне яклаган? —
Тәре баганасына
Элеп куйды якадан.

Янәсе, татар, чынык —
Торабыз тыпырчынып.
Чайкалабыз җилләрдә
Туган-үскән җирләрдә.

Туган-үскән җир, имеш,
Килмешәк татар килеш.
Ватаны булмый колның —
Тәкъдирең белән килеш.

Колның булмый Ватаны,
Кичерү юк татарны.
Тизрәк язсын дененнән,
Тизрәк язсын теленнән.

Дененнән язган татар
Тугры була эт кебек, —
Анасын сатканда да
Онытмас ул этлеген.

Ирек, азатлык, имеш,
Муенчак кигән килеш...

Ә без менә эт түгел,
Этлек юк уебызда.
Сездә баскын уедыр,
Качкыннар уе бездә.

Качкынлык — каныбызда,
Качарбыз барыбыз да —
Качкан күк чукынудан,
Иманга тукынудан.

Качкын булу илеңдә
Мең каза, мең газаптыр.
Шуңа да без ил белән
Кычкырабыз: «АЗАТЛЫК!»

...Әләм булып илләрдә
Җилфердибез җилләрдә.

## 2

1991 елның май урталары. Нәкъ җырдагыча — алмагачларның чәчәккә узган чаклары.

Казан шәһәре утлы таба сыман чыжлап тора. Әгәр улбу була калса, тәмуг сакчылары йөрәгеңне шул табага салып кыздырачак.

Ирек мәйданы күзгә күренмәс чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алынган. Бүген ул Лонг-Кеш төрмәсен хәтерләтә.

Мәйданда — АЧЛЫК. 1981 елда ун ирланд егете Лонг-Кеш төрмәсендә сәяси ачлык тотудан һәлак булган иде.

Безнең башка ниләр язды икән?

Үлем турында уйлыйсы да килми. Ачтан үлү коточкыч авыр, диләр. Г.Ибраһимовның «Адәмнәр»ен укыгач, моңа үзең дә ышанасың.

Ихтимал, мең еллар дәвамында ураза тотып яшәгән халык ачлыкны чагыштырмача җиңелрәк кичерәдер. Аның вөҗүде ачлыкка тизрәк җайлашадыр.

Хәер, безнең тарих болай да ачлыктан тора. Без инде 1552 елдан бирле ачыгабыз. Кайчандыр болгар бабаларыбыз урыс халкын ач үлемнән саклап калган.

Ә без — ачыгабыз...

Хөр булырга хакы бардыр җирдә
Һәрбер кызның, һәрбер угылның...
Ачлык тотып ачыклады халкым
Кояш астындагы урынын.

Ачлык тотып ачыклады халкым
Өлешенә тияр көмешен.
Кара йөзләр кабат каркылдады:
— Бөтенегез ачтан дөмексен!

Кара йөзләр кабат кара яга
Биләүдәге ирек йөзенә.
Ирек чыраенда күренмәсен
Татарлыкның хәтта эзе дә.

Русиянең ач күзенә төшкән
Ак кына ла булды бу халык.
Ничә гасыр дөнья бутый-бутый,
Үзе бетте Рәсәй буталып.

Бар үткәне фетнәләрдән тора,
Фетнәләрдән тора бүгене.
Фетнә дигән эфьюннән булыр
Империяләрнең үлеме.

Терәү белән терәтергә мөмкин
Ишелергә торган йортны да.
Терәүле йорт хуҗасының эше
Узмас лэкин ярым-йортыдан.

Ә терәүле йортның хуҗалары
Хәйран булып яши вәйранга...
Империя оныклары әнә
Чукмар айкап йөри мәйданда.

Империя оныклары әнә
Чукмар айкап саклый ирекне.
Кемнәр — хатын, кемнәр халкын кыйнап
Күрсәтәләр илдә ирлекне.

Азмы алар —
Мәгълүм әкияттәге
Бер дивана Иван хакына
Яулар чапкан кара полковниклар
Ата-бабасына, халкына.
(Тик үзеңнән качып булса икән,
Посып кына калкан артына.)

Танк белән таптарга да була,
Атарга да була безләрне.
Буй кыскара, уй кыскара бара,
Яши икән халкың тезләнеп.

Буй кыскара, уй кыскара бара. —
Кемгә хаҗәт — гарьлән, гарьләнмә...
Без бәләкәй түгел, дия-дия,
Әверелеп беттек кәрләгә.

Алып буйлы халык идек юкса,
Яралган соң нинди каннан без?
Илсез калмас, телсез калмас өчен,
Ачлык тотар көнгә калганбыз.

Рәсәйне тик булмый ышандырып,
Сан юк сиңа — ачык, ачыкма...
Кытлык-мохтаҗлыкта яши-яши
Ул күнеккән инде ачлыкка.

Ачлык-патша хуҗа аңа күптән,
Ачлык-патша хуҗа тәхеткә.
Өч инкыйлаб күргән бабамны да
Ул озата барган ләхеткә.

Гомер буе иген иккән бабам,
Чабагачы исән һаман да.
Булмас, димә, булган, булган, туган,
Илдә чыпчык үлгән заман да.

Илдә хәтта чыпчыклар да үлгән,
Үлмәс дигәннәре — уйдырма.
Илдә бүген кемнәр антын сатып,
Алтын сатып тамак туйдыра.

Йортындагы соңгы мал-мөлкәтен
Сатып эчкән сәрхуш баш сыман,
Алтын сатып тамак туйдыралар...
Мәйданнарда ава таш сыннар.

Мәйданнарда таш балбаллар ава,
Мәйданнарда тагын инкыйлаб.
Инкыйлабның соңы — инкыйраздыр...
Инкыйлаблар белән ил кыйнап,
Яши Рәсәй һаман ЮКсыл булып,
Гел юксынып яши үткәнен.
Казан алып кабат ат казану
Телләрендә инде күпләрнең.

Күңелдәге, әйе, телгә чыга,
Сәрхушнеке һәрчак телендә.
Баскынлыкның кара махмырыннан
Айный алмый Рәсәй бүген дә.

Хөр булырга хокукы бар юкса
Һәрбер кызның, һәрбер угылның.
Ачлык тотып ачыклады халкым
Кояш астындагы урынын.

**3**

Татар күленнән Татар бугазынача сузылган империя күмеләчәк каберне Литва берьялгызы казый башлады.

Балтыйк иленең ирекккә ачыккан халкы Империя танкларын, кулга-кул тотынышып, җырлап каршылады.

«Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә» дигән мәхбүс татар шагыйре. Бер төн эчендә 13 каһарманның җаны кыелды.

Алар арасында татар кызы Лорета Асанавичюте (Хәсәнова) да бар иде...

Кара эшләр караңгыда,
Кара төндә кылына.

Үрмәли мәкер —
Җаныңа
Якыная тын гына.

Үрмәли мәкер җаныңа,
Кара үрмәкүч сыман...
Ватаның сыйган —
Танкның
Йолдызлы мушкасына.

Ирекнең хакы, һай, кыйммәт,
Бирелми ирек бушка.
Учыңдагы бер йомарлам
Ирекне эзли мушка.

Үрмәли мәкер җаныңа,
Үрмәли тәнең буйлап.
Литва күген дегет белән
Куйганнар гүя буяп.

Үрмәли мәкер җаныңа,
Йотар булып тереләй.
Бу төн дә күчәр тарихка
Варфоломей төнедәй.

Кара эшләр караңгыда,
Кара төндә кылына.
Литва төне ясин чыга
Мөэмин татар кызына.

## 4

Иң шәп индеец — үле индеец, дигән генерал Шеридан.
Иң шәп татар — маңкорт татар, диләр Иван Пересветов оныклары.
Дәүләтсез халык маңкортлаша бара.

Маңкорт — кол дигән сүз.
Империя — коллар дәүләте ул.
Кол белән колонизатор бер үк тамырдан ясалган.
Адольф де Кюстин Рәсәйне халыклар төрмәсе дип атаган.
Маңкортлар шул төрмәнең назыйре булып хезмәт итә.
Ихтимал, татар дөньяда иң маңкортлашкан халыклар исәбенә керәдер.
Маңкорт — үзен һәрчак интернационалист дип саный.
Әйе, кол — интернациональ төшенчә: колның милләте булмый.
Социалистик Хезмәт Каһарманы М. К.нән аермалы буларак, мин үземне россиян дип исәпләмим.
Минем ирекле буласым килә...

Үч-кинә тотмыйм тарихка,
Билбауда йөртмим балта...
Җирдә моң кимегән саен,
Илдә маңкортлар арта.

Җирдә моң кимегән саен,
Кыскара бара хәтер.
Яәҗүҗ-мәәҗүҗ дигәннәре
Китап сүзе лә — хактыр.

Яәҗүҗ-мәәҗүҗ кавеменең
Дәвере килде мәллә?
Маңкортлыктан йолып калыр
Мәһдиең кайда, бәндә?

Яәҗүҗ-мәәҗүҗ кавеменең
Дәвере, димсең, алда?
Телсезлек, денсезлек күчкән
Кансызлык булып канга.

Кансызлар азмы халыкның
Иреген атты терәп.
Яши татар маңкортлары
Халкыма коллык теләп.

Яши татар маңкортлары
Сафсата сата-сата...
Улымны телсез калудан,
И Тәңрем, үзең сакла.

Сакла хәтерсез калудан,
Сакла Иделен, йортын.
Сакла берүк —
Хәтеребез
Болай да ярым-йорты.

Болай да ярым-йорты без,
Ярым-йорты ил, иләт...
Дәште Кыпчак карынында
Киләчәк ята иңрәп.

Тулгак тота чал Даланы —
Ауный дүңгәләк булып.
Безме ул — дүңгәләк кебек
Тамырсыз үскән буын?!

Үткәнен үтергәннең тик
Киләчәген кем таныр?..
Дәште Кыпчак карынында
Тыпырчына кентавр...

**5**

Казан алынгач, урыс патшасы ир затыннан булган һәммә татарны кылычтан үткәрергә әмер биргән. Арба чәкүшкәсеннән биегрәк буйлы һәр кешене шушы язмыш көткән.

Ихтимал, бу коточкыч җәзадан котылыр өчен, башын аска иебрәк, тәгәрмәчтән бәләкәйрәк күренергә тырышкан карсак ир-егетләр, малайлар да булгандыр. Кем белә, иелгән башны кылыч кисми, дигән тәгъбир дә, бәлки, шул заманнарда барлыкка килгәндер әле...

Тәкъдирен дә тәгъбир итеп язган,
Тәкъдир тактасында һәр сүз анык:
Арба тәгәрмәче буйлы калган
Тарих тәгәрмәче буйлы халык.

Тәкъдир тактасында һәр сүз тәгъбир,
Шагыйрь җаны сеңгән һәрбер сүзгә.
Башсыз калмыйм, диеп, баш имәгән,
Баш бирмәгән халык — димәк, түзгән.

Кисек башлы халык Кисекбашны
Юкка гына уйлап тапмагандыр.
Дию өннәреннән йолып алып,
Ил уллары аны яклагандыр.

Кисек башлы халык Кисекбашны
Бәетләргә салган, кыйссаларга...
Елмаерга хәтта өйрәнгән ул,
Куйганда да башын кискәләргә.

Елмаерга хәтта күнеккән ул —
Кисекбашлы тәкъдир күнектергән.
Тел яшереп телсез кала язган,
Денсез кала язган — дүнеп деннән.

Тел яшереп телсез кала язган,
Илсез кала язган аздан гына.
Камчылы бер ишан табылмаган
Базарында, бөтен Казанында.

Ник табылсын — ишан чалмасыннан
Ыштан тегеп кигәч заманасы.
Көпчәк буйлы калгач, көчектән дә
Каргаласы икән, таланасы.

Ә көчекләр Казан урамыннан
Өрә-өрә куа Кисекбашны.
Әгәр сиңа ялгыш абынса ул,
Урам ташы, берүк кичер башны.

Кичерә күр, кичерә күр берүк, —
Минем баш ул ауный, — татар башы.
Татар башын татар ашый-ашый,
Дуңгызлык та бетте татарлашып.

Татар атын татар сата-сата,
Калды атлар ишәк көннәренә.
И кадерсез атым, камчы тотып
Атланмады сиңа кемнәр генә.

Аранга да бикләп кыйнадылар,
Кыйнадылар тышау кидереп тә.
Тышау — зынҗыр.
Котылырмын димә,
Аран аратасын кимереп тә.

И кадерсез атым, билләреңә
Мин атландым бүген, —
Башсыз җайдак.
Тик язмасын берүк абынырга:
Еллар — түмгәк.
Барыр юллар — тайгак.

Тарих бизмәненме бизгәк тота —
Үзгә кыса, димәк, үзгә калып:
Кылыч буйлы булып калачактыр
Кылыч тотып ил яулаган халык.

## 6

Чиратлар иле бу.
Бу илдә чиратсыз туарга да, үләргә дә ярамый.
Үз вакытыннан алдарак туганнар гомер бакый каргалып,
тукмалып көн итә бу илдә.
Халыклар баш итчегә чиратка тезелгән.
Ә түмәрдән телләр тәгәрәшә... телләр тәгәрәшә...

Ә халыклар ясак түли теллә тә.
Кабалага төшсәң, бар да талана.
И кардәшем, «мин — бәйсез»
дип масайма, —
Анаң телен кыздыралар табада.

И кардәшем, «мин — бөек»
дип масайма, —
Балаң телен талаталар этләрдән.
Иң дөресе — чиратка бас мунчага —
Арынырга вакыт мура-бетләрдән.

## 7

Ач торабыз.
Ачыгабыз.
Ачынабыз язмышка.
Безнең тәкъдир-язмышларны
Иблис тә шул язышкан.

Ач торабыз.
Ачыгабыз.
Ашыгабыз... җиңәргә.
Ачынабыз...
Дәҗҗал булып
Әҗәл баскан иңнәргә.

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Ашкынабыз ирекkә.
Ә дәҗҗалдан юк котылу —
Ханбикәңне биреп тә.

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Качкыннар без. Качаклар.
Бәхет эзләп чәчелгәнбез —
Без бәхеткә ач татар.

Ачыгабыз. Ач торабыз.
Баш орабыз ташларга.
Держиморда гөрзиләре
Төште безнең башка да.

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Асылда без —
Үлемсез.
Үлгәндә дә тик яртылаш
Үләрбез без —
Күрерсез!

## И ВАКЫТ...

Тәмәке көле койгандай
Орынасың йолдызларга...
И Вакыт, киләчәгемме,
Үткәнемме көтә алда?

Кайнар көл — йолдыз коела
Төнге тынлык упкынына.
Тәңре гүя кырын ятып
Махра көйрәтә тын гына.

Учымны пешерә көле...
Хәлләремне шуннан аңла.
И Вакыт, кояшлы таңмы,
Нейтротаңмы көтә алда?

...Эндәшмәде Вакыт.
Бары
Утлы чукмарын алды да
Сөембикә манарасын
Кыйшайтып куйды тагын да.

## УЛ КӨН...

Һәммәсенә түзгән,
        күнгән хәтер
Күнегалмас ләкин үлемгә.
Өчпочмаклы кайгы булып яши
Авылымда ул көн бүген дә.

Әбкәйләрнең сандык төпләрендә
(Ак бүзләре белән янәшә)
Өчпочмаклы кара хәсрәт булып
Яши ул көн, яши һәм яшәр.

Һәм вәхшинең яңа варислары
Табынганда кабат тәрегә,
Борманнардай посып ята ул көн
Ярчык булып — Илем тәнендә.

Замананың яңа залимнәре
Үрелгәндә кабат кынына,
Ракетадай посып ята ул көн
Җирнең күкрәк куышлыгында.

Һәммәсенә түзгән,
          күнгән хәтер
Күнегалмас ләкин үлемгә —
Кара кайгы булып яши ул көн
Авылымда минем бүген дә.

Әбкәйләрнең сандык төпләрендә
(Туй күлмәге белән янәшә)
Соңгы
        набат булып
                күкри ул көн.
Хәтер белән хәтер ярәшә...

# ҺӘЙКӘЛЛӘР

Нинди генә һәйкәлләр юк җирдә...
Әйтер сүзем — алар хакында.
Һәр халыкның үз һәйкәле була
Мәйданнарда — чорлар чатында.

Һәр халыкның үз һәйкәле була
Иң-иң асыл кыз-улларына.
Үз-үзенә һәйкәл куйдырганны —
Император, патша — барын да

Беркөн төртеп аударачак халык
(Аударгандай мәгълүм патшаны).
«Канлы якшәмбе»ләр белән генә
Куркытырмын димә син аны!

Столыпин кулы белән генә
Бугазлармын димә халыкны.
Муенына таш бәйләнгән килеш,
Мең батты ул, мең кат калыкты.

Һәр халыкның үз һәйкәле була,
Табынганы була, изгесе —
Этләргә дә һәйкәлләр бар җирдә —
Ихтирам һәм дуслык билгесе.

Баш иягә лаек этләр азмы,
Атлар? Кошлар? Җәнлек-җанварлар?
Әнә казлар Римне коткарганнар...
Бу тарихта эзле* алар да!

---

* Г.Тукай шигыренә ишарә.

Баш ияргә лаек кошлар азмы? —
Оча белгәннәргә дан! дан! дан!
Һәр халыкның үз һәйкәле була —
Үз язмышы — канга буялган.

Кешелекнең уртак һәйкәле ул!
Постаментта — Хыял һәм... афәт.
Һәр заманның үз һәйкәле була —
Залимнәргә һәйкәл — эшафот.

## 1942 ЕЛНЫҢ КЫШЫНДА КИСЕЛГӘН КАЕНГА

...Шушы каенга сөялеп,
Кем көткәндер җанкаен.
Азмы гашыйкны ят күздән
Яшергәндер бу каен.

Авылымның азмы асыл
Ир-егетен, агаен
Үлемсезлек фронтына
Озаткандыр бу каен.

Авылыма өчпочмаклы
Хат килеп төшкән саен:
— Сабырлык бирсен Ходай, — дип,
Юаткандыр әбиләрне,
Юаткандыр бу каен.

Авылымда соңгы тумәр
Утын беткәч, мөгаен,
Салкын мичкә үзе кереп
Дөрләгәндер бу каен.

# АЛМА-РИВАЯТЬ

*Триптих*

## I

Юк,
Кизәнүем түгел лә
Ырымга йә Аллага —
Җир-әнкәбез дә, мөгаен,
Яралгандыр алмадан.

Ул чакта да Җир-алмага
Ят куллар үрелгәндер.
Ә ул карышкандыр...
Шуңа
Оҗмахтан сөрелгәндер.

Утлы тәмуг газабына
Ничек түзгәндер җаны?..
Оҗмах кануннарын бозган
Адәм белән Хәваны —
Гүя мөһаҗирләрне —

Үзенә сыендырган ул,
Бәйсез бер дәүләт сыман.
...Һәм чәчкәгә узгандыр Җир
Гашыйклар карашыннан.

Кизәнүем түгел һич тә
Ырымга йә Аллага —
Җир-әнкәбез дә, мөгаен,
Яралгандыр алмадан.

Фал ачуым да түгел бу,
Болай да һәрни анык —
Бер алманы юкка гына
Бишкә бүлмәгән халык.

## II

«Бер алманы бишкә,
әй, бүләек...»
Заманага сабак-гыйбрәт булсын —
Трояны* барып күрәек.

Трояны барып күрәек бер,
Барам дисәң, җае табылыр.
Антик чорның шәһре Болгарына
Сәҗдә кылып кайтыйк, табынып.

Чал хәрабә каршысына басып,
Йөз гасырга, әйдә, тын калыйк.
Һәм сөңгегә җан-калканны элеп,
Тутык кылыч белән чаң кагыйк.

Тапталудан ташка әверелгән
Йөрәкләрне тыңлыйк...
И күңел,
ни диярсең? —
Һәр хәрабә — музей,
Һәр җинаять — экспонат бүген.

Ә без — турист.
Индә — фотоаппарат —
Гүя хәтер!
(Шундый гасыры!)
Җирдә, бәлки, һәр хәрабә — зират,
Һәр җинаять — кабер ташыдыр.

...Ә алма — сау.
Орлыкларын тиран
Нейтрон үлем итеп чәчәдер.

* Риваятьләр буенча Троя һәлакәтенә алма сәбәпче булган.

Вәхши өчен һәр хәрабә — һәйкәл,
Һәр җинаять, бәлки, чәчкәдер.

Бу кешелек гамьсез балачагын
(Ут-күз белән шаярган чагын!)
Хәтерендә гүя шулай саклый:
Троя…
        Сталинград…
                Нагасаки…

## III

Бурзайларга ташлап кына
Үтереп булмый аны —
Материалист Акылны,
Материалист Аңны —

Җирдә даһи туып ята —
Тулгак тота җиһанны.

Җирдә даһи туып ята —
Әйтерсең күктән иңә:
Пешкән алма күк — чеменнән
Өзелеп төшә җиргә.

Төн уртасында атылган
Киек йолдыздай янып,
Пәйгамбәрдәй пәйдә була
Төп законы дөньяның.

Алмага
        алма тартыла,
Даһилык — гадилектә.
Алмага
        алма тартыла —
Гадилек — камиллектә.

Алмага
алма тартыла,
Чебеннәр — тирес-ашка.
Алмага
алма тартыла,
Икар җаннар — Кояшка.

Шундый гади!
Даһи уйлар
Әйтерсең күктән иңә —
Пешкән алма күк — чемennән
Өзелеп төшә җиргә.

## ИМИТАЦИЯ

Бәллүрдәге затлы кальвадосны
Чөмерде дә кнопкага басты.
Һәм кискәдән тәгәрәде... глобус —
Тәгәрәде гүя Атлант* башы.

## КӘСЕП

Нинди генә кәсепләр юк җирдә!
Көн күрәләр хәтта атып, асып...
Тираннар да кайчак шагыйрь булган,
Кисә-кисә шагыйрьләр башын.

* Атлант Фарнезский статуясы күздә тотыла.

* * *

...Ятимнәргә —
Түбә булыйм.

Сәрхушләргә —
Тәүбә булыйм.

Адашканга —
Сукмак булыйм.

Тук йөзләргә —
Тукмак булыйм.

Гашыйкларга —
Тирмә булыйм.

Сәфилләргә —
Төрмә булыйм.

Абынганга —
Терәк булыйм.

Хашәпләргә —
...Элмәк булыйм.

# ВАКЫТ МАШИНАСЫ

*Поэма*

## Автопролог

Урам буйлап ага машиналар.
Ашыгалар. Кая ашыгалар?
Тимер ташкын. Чатта — светофорлар.
Ярый әле чатта светофор бар.

Ярый әле урам чатларында —
Кисәтү һәм тыю тамгалары.
Кисәтү һәм тыюлардан торган
Дөньялыкта бу бер чара бары.

Бу бер чара — бәлки, чарасызлык.
Тизлек баса иңгә — гүя баскын.
Бозлык дәверенә кайтмасмы җан,
Ярларыннан чыкса тимер ташкын?

Бу бер чара — бәлки, чарасызлык.
Компьютерлар чыкса чыгырыннан,
Һәм роботлар фетнә куптарсалар,
Термик кайнарлыкка чыдармы җан?!

Галим кулындагы колбалардан
Килеп чыкса әгәр супергеннар,
Беләм, Хоттабычка, ярдәм сорап,
Ялварачак без яшисе еллар.

Тыюларга карап тормаячак —
Без җырлыйсы җырлар ялварачак.
Хакыйкатькә илтер юлларны да
Кызыл күзләр күзләп тора һәрчак.

Кызыл күзләр күзли, кызыл сүзләр.
Һәр заманның кызыл күзе — үзгә!
Һәр заманның кызыл сүзе — үзгә!
Фидакярләр янган учакларның
Кызыл шәүләсеме безнең йөздә?!

Хакыйкатькә илтер ул юлларны
Кичә ала мәгъруур затлар гына.
Инквизиция учаклары яна
Галиҗәнап Тарих чатларында.

Инквизиция учаклары яна
Авыл булып, кала, илләр булып.
Аягүрә үрли ялкыннары,
Брунодай кыю ирләр булып.

Тарих чатларында светофорлар —
Кисәтү һәм тыю тамгалары.
Кисәтү һәм тыюлардан торган
Дөньялыкта бу бер чара бары.

Бу бер чара — бәлки, чарасызлык.
Тизлек баса иңгә — гүя баскын.
Бозлык дәверенә кайтмасмы җан,
Ярларыннан чыкса тимер ташкын.

### 1. Мәгарә

Мәгарәдә учак яна,
Мәгарәдә — бәйрәм.
Ут тирәли бала-чага
Уйный әйлән-бәйлән.

Әтиләре аудан кайткан,
Әниләре — эштә:
Ут саклыйлар.
Ә учакта...
Соңгы мамонт пешә.

Ә учакта — соңгы мамонт
Тыпырчына юкка:
Алласыз әле кешеләр —
Табыналар утка.

Табына алар Кояшка,
Табыналар Көнгә.
Зуррак калҗа үзенә
Таләп итми кем дә.

Аллалар да иңәр ансы —
Балбал булыр ташлар.
Ырудашлар бер-берсен
Утка сала башлар.

Ә хәзергә аллалар юк,
Һәркем үзе Алла.
...Кешелек әле гүяки
Карындагы бала.

### 2. Бастилия

Дөнья буйлап кызыл шәүлә йөри —
Офыккача сузган ул кулын.
Таң җилферди баррикадаларда,
Ал байраклар булып.

Таң җилферди...
Жанна* кабызган ут
Дөрли һаман, өскә үрли ул,
Империя тәхетенә үрли —
Хөрлек уты сүнми, үлми ул.

Пошаманга төшкән хакимият
Белә, әлбәт, белә нишләргә —
Хөкем чыгара ул, әмер бирә:
Ут — фетнәче!
Башын кисәргә!

(...Ирektәшләр башын кисә-кисә,
Әверелгән чорлар кискәгә.)

Утның холкы, табигате шундый:
Өйрәнмәгән ул баш иярргә...
(Ирек җанын кыя-кыя, чорлар
Әверелгән Бастилиягә.)

Тик Ут-хәким сүзен хаклый халык —
Төкерә дә хаким сүзенә,
Бастилияләрне вата-вата,
Ул хөр дәүләт төзи үзенә.

Таң җилферди...
        Баррикадаларда
Ташлар яна. Ташлар — яралы.
Азатлыкның Кәгъбә ташы алар.
Узаманнар уттан ярала.

* Жанна д'Арк.

Таң җилферди...
Жанна кабызган ут
Дөрли һаман, өскә үрли ул,
Империя тәхетенә үрли,
Хөрлек уты сүнми, үлми ул.

### 3. Разлив

Ничә гасыр чайкаладыр Ирек
Самодержавие дарларында.
Җитте вакыт! —
Россиянең черек
Диварларын төртеп аударырга.

Үз илендә эмигрант булып,
Кавказын да күрде, Себерен дә... —
Ничә гасыр сөргендәдер Ирек,
Самодержавие сөргенендә.

Сәясәтен гүя ятак итеп,
Самодержавие зина кыла.
Ничә гасыр зиндандадыр Ирек,
Самодержавие зинданында.

Җитте вакыт! —
Сенат мәйданында
Декабристлар гүя суга набат.
Россиянең черек диварлары
Калтыранып куя соңгы кабат.

Җитте вакыт! —
Чаң кагар чак илдә —
Чиркәү чаңы түгел — Герцен Чаңы!
Парижларны алган бу халыкның
Зимнийларны беркөн алачагын

Хәбәр итәр өчен кирәк чаңнар!
Чаң кагардай кыю, асыл җаннар!
Азмы дарлар чаңга әверелгән —
Ә Рәсәйдә дарлар... азмы алар?!

Ничә гасыр чайкаладыр Ирек
Самодержавие дарларында.
        Җитте вакыт! —
Россиянең черек
Диварларын төртеп аударырга.

...Казна кесәсенә керә-керә
Типтергәндә барча түрә-кара,
Ил каргышы, Разливка килеп,
Шалаш кора...

### 4. Клячкин

Чиксезлеккә якынайган саен,
Күңелен ник шомлы моң сара?..
Илдә — Пасха. Бәйрәм итә Казан,
Дене, теле бүтән булса да.

Бәйрәм итә Казан.
    Гөрли базар.
        Гөрли урам.
            Халык исерек.
Хәзер инде җантимерләрең дә
Шакый алмас шагыйрь ишеген.

Печән базарының этләре дә
Йөри алмас хәзер иснәнеп.
Ишми ишан кебек ишәге дә
Донос түгел,
Язар истәлек.

...Ә халыкны уятырга вакыт,
Уйланырга вакыт бер туктап.
Уянырга!
Баш очында әнә
Монархия-тукмак.

Дөнья читлегенә сыешалмый
Хөрлек даулап очты һәр җыры.
Халыкларның уртак төрмәсендә
Шагыйрьләр дә тоткын, зынҗырлы.

Шагыйрь җанын чукып канга баткан
Каракошның кара томшыгы.
Царизмның төрмә карцерында
Азмы даһи үлгән тончыгып.

Хөрлек кенә даула —
        Шәхесеңне
Буар елан булып буарлар.
Чын шагыйрьләр вафат булмый, үлми —
Чын шагыйрьләр һәлак булалар.

Илдә — Пасха.
        Чиркәү звонарьлары
Бертуктаусыз әнә чаң кага.
Бәйрәм итә халык.
Баш очында
Кадакланган Христос чайкала.

### 5. Ятим малай

*Каберташка уелып калган сурәт:*
*атом гөмбәсе утлы дар элмәгенә охшаган.*

...Башта әтисен астылар,
аннан — әнисен.

Чаң кагарга теләдеме —
җил куйды исеп.

Карт палач абынды гүя
үз өрәгенә.
Канлы хәнҗәрен батырды
җил йөрәгенә.

Ыңгырашты камышлы күл.
Шашты. Түзмәде.
Чокып чыгарды карт палач
аның күзләрен,
зәңгәр күзләрен.

«Бер генә тере шаһит та
калмасын җирдә!»
Утлы элмәктә тирбәлде
дөм сукыр ир дә.

Утлы элмәктә тирбәлде
гөнаһсыз Ай да.
Утлы элмәктә тирбәлде
ятим малай да.

...«Очар тәлинкә»ләр очып
узды якыннан...
...Мамонтлар борылып ятты
кыйбла ягына...

...Сөңгесен атты мезазой
мәңгелек аша.
...Палачның канлы шәүләсе
чәчрәде ташка.

### 6. Мораторий

Чакма чагып учак тергезгәндә,
Якты эзләгәндә кармаланып,
Дөньяны да беркөн ут ялмар, дип
Уйламагандыр да бабаларым.

Искәрмәгәндер дә —
Учакларның
Ярсып-ярсып җилдә очкынлавын.
Чакма чагып ут элдергән алар—
Чорлар буйлап очкан очкыннары.

Уйламагандыр да бабаларым
Шул очкыннан мәхшәр кубачагын.
Каян белсен алар
Утка беркөн
Хуҗасызлык хуҗа булачагын.

Каян белсен алар?
Мәңгелек дип,
Кабул кылган кануннар да туза.
Чор чатында тыю тамгалары:
«Тукта! —
Утка хуҗасызлык хуҗа!»

Чор чатында — тыю тамгалары.
Тыю тамгалары искерми ул.
Нинди кытлык заманда да халык
Хуҗаларга кытлык кичерми ул.

Чор чатында — тыю тамгалары:
«Хуҗасызлык хуҗа утка —
Тукта!»
Реакторда Вакыт калган туктап —
Мораторий — утка!

Мораторий — димәк, гамьсезлеккә!
Мораторий — димәк, мәнсезлеккә!
Мораторий — ялган матурлыкка!
Мораторий,
Мораторий — утка!

Җылы урын даулап өргән эткә —
Мораторий — комсыз түрәлеккә!
Мораторий — фикри сәрхушлеккә!
Мораторий,
Мораторий — утка!

Мәңге, мәңге, мәңге мораторий —
Иш, тугандыр бабам Ишморатка.
Сугышта ул ике улын җуйган
һәм бер башын... —
МОРАТорий — утка!

Реакторда Вакыт калган туктап —
Реактор — гүя крематорий.
Минем бабам крематорийда янган —
Мораторий!..

### 7. «Ашыгыч ярдәм»

Килер ул көн,
    килми калмас —
Без дә таярбыз хәлдән...
Әнә, күр, урамнар буйлап
Чаба «Ашыгыч ярдәм».

Кая шулай ашыга ул —
Кем тарыган бәлагә?
Берәүнең стресс-махмырдан
Йөрәге кага мәллә?

Кая шулай ашыга ул,
Дуамалланып, улап —
Яшь хатынны тәү мәртәбә
Тотамы әллә тулгак?

Кая шулай ашыга ул,
Шом салып күңелләргә?
Бәгъзе Хода бәндәләре
Хәтерен җуйган мәллә?

Кая шулай ашыга ул,
Нигә шулай ашыга?
Берүк катгый «STOP» кына
Очрамасын каршына.

Кая шулай ашыга ул, —
Дөньямы тайган хәлдән?
Сикәлтәле чорлар буйлап
Чаба «Ашыгыч ярдәм»...

# ЛИТВА МОЗАИКАСЫ

## 1. Литва

Туфрагыңа аяк бассам,
Тарих үзе дәшә күк.
О Литва!
Син — Чюрленис хыялында
Туган бөек әсәр күк.

Урманнарың дайна суза —
Гыйбрәтле дә, кызык та.
Кичке эңгерең гүяки —
Төсле музыка.

Тын кысыла чал Вильнюсның
Сынаулы карашыннан.
Серле крепость-кальгаларың
Халык хәтере сыман
Аягүрә.

Ил-көн гамен, җан хөрлеген
Саклый алар бүген дә.
Беләм, Литва, туфрагыңа
Ирек каны түгелгән.

Ирек каны... Йөрәгеңдә
Ал гөлләр булып шыткан.
О Литва!
Әнә, күрәмсең,
Коена алар чыкта.

Бер гөлгә дәшкән идем дә...
Оятлы булдым мәллә?
Литвача сөйләшә бугай
Сездә гөл-чәчәкләр дә.

Туфрагыңа аяк бассам,
Үткәннәрем дәшә күк.
О Литва!
Син — Чюрленис хыялында
Туган бөек әсәр күк.

### 2. Үле тел

Мин — үле тел,
        Мин — әрвах тел,
Сезгә дәшәм, тереләр.
Онытырга мөмкин, диләр,
Хәтта ана телен дә.

«Пер аспера ад астра» —
О мәгърур йолдыз иле!
Кайчандыр газиз җиремдә
Мин дә туган тел идем.

Азмы телгә ана булдым,
Хәтерлимсең, и гавам?
«Ин вина веритас», — дидем, —
Гөлсарга чумды галәм.

Галәм — гүя Атлантида,
Йолдызларда — невроз,
Вакыт-табиб мөһер суга:
— Атеросклероз!

Сезгә дәшәм. Ишетәмсез?
Ишетәмсез, тереләр?
Онытырга мөмкин, диләр,
Хәтта ана телен дә.

Сак булыгыз, тереләр!
Сак булыгыз, тереләр...

### 3. Литвада, Татар күле буенда килгән уй

Бер сүз яши миндә,
Яши гыйбрәт булып:
— Җиде бабаң атын
Белү фарыз, улым.

Шәҗәрәңне берүк
Җуя күрмә ялгыш.
Кыйбласыз җаннарга —
Мәңгелек каргыш.

Эзлә бабаңнарны
Диңгезләр ягыннан,
Иделләр ярыннан,
Эзлә улларыңнан.

Фалчылар сөйләр ул —
Ышан тик Хәтергә.
Чын тарих хакында
Калган ни хатирә?!

Бер көн үзегез дә
Тарихта каласы...
Тын, тымызык күлдә
Чайпала карашым...

### 4.Межелайтис

*Экспромт*

...Борынгы Вильнюс урамнары буйлап атлаганда, капыл гына шагыйрьнең «Дайна»сы хәтеремә килде...

— Межелайтис кайда яши? — дип сорадым мин аңардан.

Ул мине шагыйрьнең фатирына кадәр озата барды...

— Межелайтис кайда яши?
— «Урман әкияте»ндә.
Әнә тыңла:
Литва имәннәре шавы
Яңгырый барча телдә.

— Межелайтис кайда яши?
— «Төнге күбәләкләр»дә.
Күбәләктәй утта янган
Халыклар бар әле дә.

— Межелайтис кайда яши?
— Азат, мәгърур «Кеше»дә.
Иле горур булса, шагыйрь
Мәһабәт тә, көчле дә.

— Межелайтис кайда яши?
— Һәр литвалы җанында.
...Чал Литва хәтер яңарта,
Шагыйрь — хәтер ярында.

### 5. Пирчюпис

Пирчюпистай дөрли хәтер —
Вәхшиләрме ут салган.
Укмашкан болытлар күктә —
Гүя корым, кисәү, кан.

Ут ялмый Яшәү авазын—
Сулышны буа төтен.
Ут ялмый нарасыйларны —
Бәгырьне ала өтеп.

Ут ялмый соңгы өметне—
Кисәү кала җаннардан.
Халык хәтерен ялмый ут...
...Тарих чигәсендә — кан!

Ургып-ургып ут бөркелә
Җир-тәмуг морҗасыннан.
Инфарктлан илләр ава
Пабло Неруда сыман.

Гөлләр ава инфарктлан,
Йөрәген тотып ава.
Пирчюписта ләйсәннәр дә
Күз яше булып ява.

Пирчюпистай дөрли хәтер —
Вәхшиләрме ут салган.
...Кичке шәфәкъ. Балтыйк яна.
Ут эчендә — заман.

## 6. Литва татарлары

Кардәшләрем... Литва татарлары...
Горур татар! Серле татарлар.
Нинди генә җилләр ташлагандыр —
Мәгърибтә дә азмы татар бар?!

Нинди генә җилләр ташлагандыр,
Тарих, әйдә, үзе сөйләсен...
Яр буенда тыпырчынып ята
Нух бабайның ярык көймәсе.

## 7. Литва-91, 13 гыйнвар

...Ватан тагын кан эчендә,
Ватан тагын яралы.
Мөнбәрләргә менде кабат
Империя ялганы.

Асылына битлек япкан
Ялган тагын калыкты —
Төнге баррикада булып
Күтәрелгән халыкны

Таптап үтте...
Мәҗрух Ирек,
Син аларны танып кал —
Алар — Прага язын да
Таптап үткән танклар.

Тәнендә — чылбыр эзләре —
Гүяки канлы хәтер.
Хәтерләп кал!
Хөкем сүзен
Унөч яшьлек кыз әйтер.

Хәтерләп кал! —
Ант итте ил
Унөч табут каршында.
...Балтыйк җиле ятып елый
Канлы урам ташына.

# БЕЗ — ХӘТЕР!

*Илһам Шакировка*

Бу катмарлы дөньялыкка
Без үксеп, елап килдек.
«Карурман»ны ишетмәсәк,
Без сагыш булмас идек.

Бу катмарлы дөньялыкка:
— Син нинди садә! — дидек.
Илләр имин, тату торса,
Без кайгы булмас идек.

Бу катмарлы дөнья безгә
Азмы көч, ныклык бирде!
Җирдә үлем яшәмәсә,
Без нәфрәт булмас идек.

Бу катмарлы дөнья безне,
Юк, бөгә алмас инде.
Җанда ышаныч тоймасак,
Без шатлык булмас идек.

Бу катмарлы дөнья гамен
Без көбә итеп кидек.
Шагыйрь иманы булмаса,
Без хәтер булмас идек.

Без хәтәр булмас идек.

## СҮЗ ТӘМЕ

Сүзләрнең дә үз гамьнәре була,
Үз тәмнәре — ачы, татлысы.
Иң татлысы — Ирек...
Ә ачысы?
Ә ачысын безгә татыйсы.

## БЫЛБЫЛ

Тәңре-табигать тә безнең
Ихтыярда асылда —
Талга кунып сайрар былбыл
Читлек куначасында.

Җырлыймы ул, елыймы ул —
Безгә барыбер — хозур!..

Ирекка сусаган җанның
Ләгънәте, каргышы да
шагыйранә аның.

# ӘКИЯТ

Бу халыкка Нужа бабай үзе
Биргәндер лә зиһен, акылны:
Әкият геройлары да аның
Йә бик тинтәк, йә бик акыллы.

Йә бик чибәр, йә бик котсыз була
Әкияттә никтер кызлар да.
...Шүрәленең Былтыр кыскан кулы
Ничә гасыр инде сызлана.

Хакыйкатьтәй кырыс әкиятне
Безгә Нужа үзе сөйләгән.
Газиз халкым гади урталыкны
Беркайчан да, әйе, сөймәгән...

## КАБАЛАНУ

...Такси счетчигына багып,
Йөрәкне уа-уа,
Безме ул дөнья куабыз,
Дөньямы безне куа?

Йомшак кәнәфигә чумып,
«ТУ»да, «ИЛ»да, «ЯК», «АН»да
Безме һаман ашыгабыз,
Вакытмы кабалана?

Гомер — бәйге. Узышабыз.
Кемнәрдер шөһрәт ала.
...Тукай йөгәнләгән пар ат
Шулай да тизрәк бара.

## ТАБЫШ

...Хәрабәләр арасында
Күпме баш — күпме табыш!
Кем җиңүче?
Чү, рухларын
Рәнҗетә күрмим ялгыш.

Һәммәсе дә тигез монда —
Юк башкисәр, юк каган.
...Ә кемдер шул сөякләрдән
Көл савыты ясаган.

## СУРӘТ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

*Билгесез татар рәссамына*

Гасыр әле күкрәк баласыдай
Тыпырчынган чакта бишектә,
Соңгы хәбәр йөрде мәхәлләдә,
Шакый-шакый килде ишеккә.

— Тагын теге денсез хәлфә улы
Гаурәт ясап безне хур иткән.
Ул азгынга тизрәк чара күрик,
Йа ләхәүлә,
Ул кяфер икән.

Һәм рәссамны тотып алдылар да
Кыз сурәтен утка салдылар.

Аягүрә ялкынланды учак.
Әверелде сынга — шул чакта,
Үз йөрәген алып салды рәссам
Мәгъшукасы янган учакка.

Ә бер читтә чапан, түбәтәйләр
Дога кылды: «Корсын нәсле дә!»
...Янган сурәт бик тә охшаш иде
Пикассоның мәшһүр рәсменә*.

* Рәссамның «Майорка утравында яшәүче испан кызы» картинасы күздә тотыла.

## ҺӘМ БАШКАЛАР...

*Евг. Евтушенкодан*

Кайбер доклад-чыгышларда,
гәзит-журналларда,
хроника-хәбәрләрдә
була шундый бер сүз —
бер сүз шундый әрсез:
...һәм башкалар,
...һәм башкалар...

Әй, оратор,
кемнәр алар «һәм башкалар»?
Әй, мөхәррир,
кемнәр алар «һәм башкалар»?
Әллә бер-бер гаепләре бармы,
Әллә... исемсезме алар?!

...Әй, дастаннар,
кемнәр сезне иҗат итте?
Әй, «Карурман»,
кемнәр, сине җырлый-җырлый,
илен яклап,
изге яуга китте?
Әй, «Гөлҗамал»,
кемнәр, сине көйли-көйли,
төннәр буе
сагыш-моң чикте?

Без белмибез,
без белмибез, дисездер дә,
белмәвегез гаҗәп түгел бер дә. —
Азмыни тарихта алар —
галиҗәнап «һәм башкалар»?!

Азмыни тарихта алар —
«һ. б.»га тормас патшалар?!

...Вакыт җитмәс, урын җитмәс, диеп
Курыкмагыз —
эзлә, табыгыз!
Онытмагыз! —
Кешеләрне үз исеме белән
атау фарыз!

* * *

Ирек даулап канга баткан йөрәкләрне
Мародерлар хөкем итсә,
нинди хәтәр!
Хакыйкатьне талап алыр иде алар,
Кояшкача буй-колачы җитсә әгәр.

Ватаныңны талап алыр иде алар,
Тарихыңны...
Күңелдә — шом, кара шәүлә.
Бабалары каны тамган җирне кеше
Югалтудан мәңге шулай куркыр мәллә?

Дастаннарга әверелгән бөеклеккә
Сәҗдә кылып, киләчәккә барган чакта,
Мародерлар сузыла калса иманыңа,
Күбәләккә әйлән, җаным,
моңны сакла!

Моңны сакла...

# ЛОНГ-КЕШ

*Поэма*

Я жил в самом пекле истерзанных наций.
*Пабло Неруда*

## Ялвару

Һәр көн,
Һәр таң,
Һәр төн,
Һәр иртәдә
Кыйтгалардан шомлы аваз ишетелә —
SOS авазы!
Җаннарыбыз һәлак була —
Коткарыгыз!
Нигезебез харап була —
Коткарыгыз!
Халыкларыбыз юк ителә —
Коткарыгыз!
Тарихыбыз мәсхәрәләнә —
Коткарыгыз!
Киләчәгебез кыл өстендә —
Коткарыгыз!
Коткарыгыз!!
Коткарыгыз!!!

...Кайчандыр,
Иделдә су коенганда,
бата башлаган кызчык та
нәкъ шулай ялварган иде:
— Коткарыгыз!

...Кайчандыр,
төнге буранда адашып
бүрегә юлыккан егет тә
нәкъ шулай ялварган иде:
— Коткарыгыз!

А, фаҗига теле!
Бар гавамга таныш, аңлаешлы.
Кодрәтең җитсә, шигырь яз,
Көрәшкә өндә шул телдә —
Юксыллар телендә!

Юксыллар бүген дә
баррикада,
төрмә диварлары аша
шул телдә аңлаша.

## Ирек турында җыр

Иреклe, ирекле һәм, ниһаять, ирекле.
*М.Л.Кингның кабер ташындагы язу*

...Җырларым, азатлык даулап, баррикадаларда сугышканда үзем зинданда аунадым.

Рухташларым, йодрыкларын төйнәп, залимнәргә кизәнгәндә кулларым зынҗырлы иде.

Халкымны иреккә сусап аңын җуйган әсир кебек яратканда ил-йортымнан аердылар...

*Шагыйрьнең илдәшләренә язган хатыннан*

Чынлык булган җирдә ялган да бар,
Хөрлек булган җирдә — богаулар.
Шул богауны йолкып өзәр өчен
Яралгандыр көрәш, дау-яулар.

Көннәр беләнмени —
Көрәш белән
Үлчи Вакыт Кеше гомерен.
Петропавел диварлары әйтсен
Кибальчичның
Әйтелмичә калган гозерен.

Тарих әманәтен — Ирек утын
Яшермәсен палач хет кая —
Йә Лоркалар булып кабына ул,
Йә Җәлилләр булып елмая.

Һәм көрәшкә ташлана ул кабат,
Йодрыкларын төйнәп — иң алда!
Рөхсәтсез, шакымыйча гына
Килеп керә парламентларга.

Килеп керә хөкем залларына,
Антлар эчми генә сүз ала.
Ә үзенең күкрәгеннән саркып,
Трибунага кайнар кан тама.

Хөкемченең лепкәсенә тама,
Тәхетенә тама хакимнең...
Таңгы шәфәкъ булып җәелә көн
Күк йөзенә Илнең...

## Ватан турында җыр

Илең турында уйла.
*Ф. Кәрим*

— Ватан нидән башлана?

Истә әле: өченчедә укыганда, укытучы апа безгә әнә шундый сорау биргән иде.

— Минем абыем чик буенда сакта тора. Ватан шуннан башлана, — диде җирән чәчле Рәшит.

— Ә минемчә, Ватан әлифбадагы рәсемнәрдән, иптәшләрдән, биек таулардан, урман-кырлардан башлана, — дип сүзгә кушылды почык борынлы Гүзәл.

Хәзер үземнән сорыйм: чыннан да, Ватан нидән башлана соң? Америка индеецлары, Австралия аборигеннары — дөньяның Ватан-анадан мәхрүм ителгән ятим халыклары өчен нидән башлана соң әле Ватан?!

## Инчу-чун догасы

Безне җирле халык, диләр. —
Җирлеме без? Әйт, Аллам!
Юлбашчы улыңа хәзер
Барырга кая таба?

Безне кызыл тәнле, диләр. —
Гөнаһмы шул? Әйт, Аллам!
Зәңгәр Бүре ыруыннан
Илгә-көнгә ни кала?

Безне юкка чыга, диләр. —
Хак сүзме шул? Әйт, Аллам!
Ватанын җуйган халыкны
Ни хөкем көтә алда?

Ишетәмсең нәгъръмне,
Нигә дәшмисең, Аллам?
Офыктагы Кояш нуры
Тәнемә сеңә һаман,
Тәнемә сеңә һаман...

## Нәфрәт турында җыр

Җир әйләнә барыбер, инквизитор.
*Х. Туфан*

Мәйданнарда дарга асылды ул,
Диварларга терәп атылды...
Канлы кулын юган чакта палач,
Уйлагандыр, чыкмас, дип тыны.

Тик ялгышты.
Күрми калды палач

Йодрыкларын аның —
Төйнәлгән!
Хәер, нигә фәлсәфәләр аңа,
Эш бит бара, эш бит көйләнгән.

Йомылды куз.
Ә йодрык калды.
Ә йодрык калды сугарга.
Планетага якты җитми иде,
Һава җитми иде суларга.

Ә йодрык кабат күтәрелде,
Һәм кизәнде Батырша булып.
Богау чыңы яңгырады күктә —
...Таралмады болыт.

Ә йодрык тагын күтәрелде,
Утлы йөрәгедәй титанның —
Байрон булып сукты яңагына
Леди политиканның.

Чабаталы Рәсәй булып сукты,
Үч-нәфрәте булып халыкның.
Күмәк җыры яңгырады күктә
Муромецның,
Манас,
Алыпның.

...Танк эчләрендә янды Нәфрәт,
Яшьтәш булып.
Ләгънәт ул утка!
Континентлар булып сугар йодрык —
Биш бармагы аның —
Биш кыйтга!

## Соңгы җыр

> Соңгы җырым палач балтасына
> Башны тоткан килеш язылa.
>
> *М. Җәлил*

Баш очымда Кояш түгел —
Гильотина!
Ә Вакыт — ташбака шикелле —
сытып үтерәсе килә.

...Чулпан кызым ни хәлләрдә
икән анда?
«Әттә» диеп саташамы
ул һаман да?

...Әминә дә зарыккандыр көтеп,
Беләм.
Күренәсем килми
бу кыяфәт белән.

...Илдәшләр ни уйда икән
безнең хакта?
Уйларында юкмы берәр шөбһә,
хата?

...Казан,
дуслар,
Кашшаф,
Туфан нишләп ята?

...Исән-саумы Андре? —
соңгы ышанычым!
Җырларым бит әле —
читлектәге лачын.

...Соңгы сүзем-әманәтем
сиңа, халкым!
Беркайчан да
сатмадык без
яманатың.

...Ирекле бул мәңге! —
Васыятем сиңа!
...Баш очымда Кояш түгел —
Гильотина...

## Теләктәшлек турында җыр

Россиягә ярдәм итегез!
*Б. Шоу*

Аурупаның җөйле йөзен
Кабат
Таптаганда тиран итеге,
Ил агасы дәште эфир аша:
— Россиягә ярдәм итегез!

Хәвеф иңде Пушкин ватанына,
Көн күзен көл, сөрем каплады.
Халык күңеледәй каеннарның
Күкрәгендә — үлем таплары.

Кызыл мәйдан, сабыр аналар күк,
Озатканда сыкрап улларын,
Ил агасы дәште кыйтгаларга,
Җан ачысы булып толларның.

Парламентлар!
Дар элмәге өчен
Без һәммәбез — муен.

Бертигез!
Россиягә ярдәм итегез сез,
Азатлыкка ярдәм итегез!

...Ә Азатлык һаман камалышта —
Йә крепость ул, йә тоткын әле...
Сыкрап-сыкрап чорлар кабатлана —
Ольстерда — «Канлы якшәмбе».

## Эпилог урынына

...Алар үз халкының азатлыгын яклап көрәште...

Роберт Сэндс. 66 көн ачлыктан соң 27 яшендә һәлак булды. Ә берничә көн элек кенә көрәштәш дуслары аны туган көне белән тәбрикләгәннәр иде.

Көрәшчеләр бер-бер артлы ава торды. Фрэнсис Хьюз, Раймонд Маккриш, Патрик о'Хара, Джозеф Макдоннел...

Һәм, ниһаять, унынчы корбан — 27 яшьлек Майкл Дивайн. Унынчысы, әмма соңгысы түгел.

Тукай яшендә дөньядан киткән Роберт Сэндсның төрмә көндәлегендә мондый юллар бар: «Алар мине сындыра алмас. Чөнки хөрлеккә, ирланд халкының хөрлегенә омтылыш — минем йөрәгемдә...»

## ТУЗГА ЯЗЫЛМАГАН СҮЗЛӘР

Тузга язмаганны сөйләмә, дип
Өйрәткәннәр иде әдәпкә, —
Тузга язылмаган сүзләр эзлим,
Җаным бүген шундый халәттә.

Тузга язылмаган сүзләр эзлим
Туган телем —
Туңган телемнән.
Тузга язылганны сөйли-сөйли,
Телсез кала яздык ил беләп.

Тузга язылмаган сүзләр эзлим
(Кем эзлидер шәраб, колбаса...)
Тузга язылганны укый-укый,
Томанага калдык лабаса.

Тузга язылмаган сүзләр эзлим.
Тел сәүдәсе гөрли базарда.
Тузга язылганны яза-яза
Өйрәндек ич донос язарга.

Тузга язылганны тукый-тукый
Өйрәттеләр ләса түземгә...
Тузга язылмаган һәрбер сүзне
Эзләп табу кирәк үзеңнән.

Түрә әнә түргә элеп куйды:
«Син үзеңнән башла ислахны».
Тузга язмаганны сөйләр өчен
Кайтты илгә Гаяз Исхакый.

Тузга язмаганны сөйләмә, дип
Өйрәттеләр юкса әдәпкә, —
Тузга язылмаган сүзләр эзлим —
Дөньям бүген шундый халәттә.

## КИЧӘГЕ КӨН БАТЫРЛАРЫ

Кыюлык хупланган чакта,
Һәркем чыгар алышка...
Кичәге көн батырлары
Бүген дә бил алыша.

Кичәге көн батырлары
Батыр, батыр һаман да.
Алышалар...
Кичәге көн
Әйтерсең, булмаган да.

Алышалар... Алышларның
Алымы инде үзгә.
Ятлап нотык сөйли-сөйли
Май яза алар сүздән.

Бик тә дөрес сөйли алар.
Хаталанмый ялгыш та.
Кичәге көн батырлары
Кыюлыкта алыша.

Казна караклары илнең
Күз нурын урлаганда,
Куркаклыкта бил алышу
Әйтерсең, булмаган да.

Кичәге көн батырлары
Һаман хаклык сагында.
Гаделлектә алышалар,
Тәүбә итәр чагында.

Кичәге көн батырлары
Бүген дә үз көчендә.
Һай, зур батырлыклар кирәк
Тәүбә итәр өчен дә.

Кичәге көн батырлары
Батыр бу заманда да.
Алышалар...
Кичәге көн
Әйтерсең, булмаган да...

## ЧЕРЕК КҮЛ

Черек күлгә кармак салдым,
Еллар аша үрелеп.
Айкалды күл, чайкалды күл, —
Сере китте түгелеп.

Айкалды күл, чайкалды күл,
Чайпалды күңелләрем.
Татарның күпме затлысы
Чүплеккә түгелгәнен

Уйладым да уем качты.
Текәлдем калкавычка...
Котылсын заман —
Сәяси
Капкыннан, алдавычтан.

Кешенең кадере булсын,
Кабере булсын җирдә.
Саклансын заман —
Капмасын
Кабаттан сыйнфый җимгә.

«Шагыйрьләрнең каберләрен
Эзлим», — дип язган дустым,
Киләчәккә зират аша
Синме карарга куштың?!

Күпме табут кайтты илгә,
Күпмесе — безгә кордаш...
Кай зиратта ята, димсең,
Якташың Фәтхи Бурнаш?

Кай зиратта ята, димсең,
Хөр уйлы гали җаннар —
Мирсәет Солтангалиев,
Тинчурин, Галимҗаннар?..

Шигырьгә күчәдер
Җанга
Сыймаган борчу, кайгың...
Ярый әле яд итәргә
Кабере бар Тукайның.

Кадере бар...
Шөкер әйтеп
Коенабыз данында.
Кабере бар...
Яшәсә дә
Халыклар зинданында.

Ә бит кемнәрдер синең дә
Шәхесеңә тукына.
...Черек күлдә дога кылдым
Шәһитләр рухына.

## СТАЛИНИЗМ

Үз иле зиндан булса да,
Йөрер ул ирек эзләп —
Чит халыкка ирек даулар,
Иреген ирексезләп.

## ӘФГАНСТАН-79

Хакимгә дә, хадимгә дә
Сабак-гыйбрәт алыр чак:
Ил-Ватаның кушканны да
Үтәмәү кирәк кайчак.

# САЕСКАН ҺӘМ ПРОМЕТЕЙ

Карамага кунган карт саескан,
Күзлек пыяласы аша карап
Җиргә,
Катгый хөкем сүзен әйтте:
«Прометей — карак!

Шәкүр картны ат карагы, дисез,
Прометей менә ут карагы.
Дөрес, ул да каһәрләнгән бугай,
Янып беткәч җирдә караңгы.

Рәхәт чигеп яшәр иде, бахыр,
Бер куышта —
Дөм караңгы булса.
Яшреп кенә ут тергезер иде,
Әгәр туңса.

Кешелекне уттан саклыйк, диеп
Лаф орасыз бүген, сугасыз чаң.
Адәмнәргә ут өләшеп йөрү
Ахмаклыктыр әле, уйлап баксаң».

Карамага кунган карт саескан
Шулай диде:
— Прометей — карак, бур...

Акъәбинең ачык тәрәзеннән
Кереп күзлек чәлгән иде ул...

# ТУРИСТЛАР

*Шагыйрь дустым авызыннан*

Җирне тырнап җилләр җылый,
Шомлы таң, шомлы кичләр...
Ә без менә Освенцимда
Чираттагы туристлар.

Монда Вакыт бер ноктада
Катып калган мәет күк,
Ишетелгән һәрбер аваз
Шәһитләргә бәет күк.

Таш диварлар сөйли кебек:
«Хөрлекне тоеп яшә...»
Каен яфраклары гүя
Тоткыннар булып дәшә.

Дүрт миллион йөрәк сулкылдый,
Шомлы таң, шомлы кичләр...
Мәҗрух илләр ыңгыраша,
Һәркайсында — туристлар.

* * *

Күгәрченнәр гөрләшкәнен
Гашыйклар тыңлап тора.

Ахирәтләр серләшкәнен
Гайбәтче тыңлап тора.

Рәсми затлар сөйләшкәнен
Халыклар тыңлап тора.

Әгәр Вөждан телгә килсә —
Шымчылар тыңлап тора.

...Без шау-гөр киләбез, имеш –
Шау тынлык тыңлап тора...

## «МИНЕМ ДАГЫСТАНЫМ»НЫ УКЫГАЧ

Шамилләр йөрәге тибә,
Тибә һәрбер халыкта...
Кара мантия бөркәнеп,
Кайчак чорлар калыккан.

Чор шаһитлары... шәһитләр...
Нигә шәһит? Ник әле?
Ишми ишан их кайбер
Намус сәүдәгәрләре

Печән базарында саткан,
Саткан иң асылларны.
Ыңгырашканын ишетәм
Мин гүя гасырларның.

Ыңгырашканын ишетәм
Карусыз тәте, дарның.
Гадел хөкемен ишетәм
Кичеккән хөкемдарның.

Чор шаһитлары — шәһитләр.
Ә кемнәр — ялчы, хадим...
Бөркетен җуйган кыя-тау
Барыбер үксез, ятим.

Барыбер үксез, ятим.

## КӘРЛӘ АГАЧ

Иш-кардәшләренең башы
Күкләргә тигән күптән.
Ә ул һаман кәрлә килеш... —
Гасырлар юкса үткән.

Ә ул һаман кәрлә килеш —
Синең белән бер чама...

Көн күзеннән яшерсәләр,
Ил күзеннән яшерсәләр,
Кәрлә булмый юк чараң.

## ТӘКЪЛИД

Кирәкми аңа алкышлар,
Кирәк түгел мактаулар.
Үз кодрәтен белмимени
Мәңгелек кыя-таулар.

Түбәсендә — чал болытлар.
Күкрәгендә — шоңкары.
Кемдер зурлана. Ә үзе
Чыпчык очыра бары.

Кирәкми тауга мактаулар,
Кирәкми аңа алкыш.
Ул шоңкар очыра. Ә син
Чыпчык очырма ялгыш.

## КАРА БАЗАР

Кемгә — Бальзак —
Гүя бальзам!
Кемгә — софа —
Софокл!..
Сатулаша-сатулаша
Саталармыни акыл.

Монда акылга һәркемнең
Үз бизмәне, үз хакы.
Әй, сез,
Очсызрак сатмыйсызмы
Толстой, Пастернакны?!

Очсызрак сатылмыймы
«Фауст», «Тәүге торналар»...
Сезнең хак-бәядән алар
Кыйммәтрәк торалар!

Карамагыз бөекләрнең
Милләтенә, теленә —
Күтәрегез бәяләрне
Пушкин биеклегенә!

Тукай биеклегенә...

## ТУФАН

«Мә, партия, мине», — диеп
Язган да... көткән хәбәр...
Башлары Себер китәсен
Алдан белгән пәйгамбәр.

* * *

Кабаланмый гына учак яна,
Яна мәңгелеккә килгәндәй.
Йолдызларга үрли ялкын теле,
Әйдә, минем белән, дигәндәй.

Ядрә булып йолдыз атылганда,
Сискәндереп куя ал тынлык.
Мескенлектә узган гомер төсле,
Чиксезлеккә сеңә яктылык.

## КОЯШ БАЕГАНДА КИЛГӘН УЙ

Бу җирдә бездән дә,
Бәлки, якты калыр.

Кояш ул — бер генә!

Аягүрә янган
Шәмнәренә авыр.

## АВТОБИОГРАФИЯ

Мин — Карт Буян.
Гомер кичтем
Ике тәртә арасында.
Һәрчак тугры юлдаш булдым
Адәм баласына.

Сабантуйда мәйдан тотар
Чабышкы да булыр идем, —
Болыннарда аунар чакта
Камыт кидем.

Күпме дага, арба тузды,
Заман йөген тарта-тарта.
(Ә заманнар җиңел түгел
Тулпар җанлы атка.)

Мин — Карт Буян.
Ә дөньяда
Пегаслар да яши, диләр.
...Без дә канатлылар идек —
Каерды шул ирләр.

Чыбыркылы ирләр.

# ҖЫР КИРӘК

Безнең дә бит еллар учагында
Бераз инде гомер көйрәде...
Бишегемне тибрәткәндә, әнкәй
Кайсы көйне икән көйләде?

Кай җыруны ул җырлады икән?
Хәтереңдә булса, әйт, йөрәк, —
Галәм бишегендә ятимнәр бар —
Юатырга кирәк!
Җыр кирәк!

## ИШЕТӘМ ДӘ...

Җиһандагы һәрбер җисем —
Җанлымы ул, әллә җансызмы —
Кызып сөйли миңа эч серләрен,
Шатлыкларын,
Дәгъва-таләпләрен...

Ишетәм мин басу уртасында
Ялгыз калган тургай моңлануын,
Кояш нурларының иркәләү сүзен,
Төннең көнгә сихри эндәшүен,
Башка исем кушыгыз, дип,
Шайтан таягының сүгенүен,
Мәйданнарда көрәш авазларын,
Кемнәрнеңдер гамьсез көлүләрен...

Ишетәм дә
Хөкемемә тартам.

## Ә ХАКЫЙКАТЬ АРТТА...

Чорлар буйлап яманатлар чаба,
Хөсет-мәкер чаба — көл кала...
Хакыйкатьне алкышларга чыккан
Күпме Вөждан, Намус таптала.

Ә хакыйкать — артта. Ул — ашыкмый,
Ул ашыкмый килә нигәдер.
Белә булыр: үзен раслаганчы
Булмаячак аңа чын кадер!

Тик ул килә! Тик ул якынлаша
Бруно булып, Бируни булып!
Тик ул килә еллар, чорлар аша,
Үткәннәрнең бүгене булып.

Чорлар буйлап яманатлар чаба,
Хакыйкатьтән алда, титаклап.
...Ашыкмый шул Хаклык.
Ә шулай да
Кешелекне калыр ул саклап.

# АҢЛАШАСЫ БАР

Күгәрченнәр — кошлар дәүләтенең
кешеләргә килгән илчеләре.

Шәһәр бакчасында күгәрченнәр,
Сарып алганнар да сабыйларны,
Җим чүплиләр.
Әллә кеше затны
Кандашлары диеп саныйлармы?

Ә лачыннар, тургай, сандугачлар
Ник өркәләр икән, ятсыналар?
Юкса бездә дә бит лачын рухы,
Былбыл җаны яши. Нигә алар
Һаман ераклаша бара бездән,
Ераклаша бара гамәлләре?

...Уйлап баксаң, илче кошлар белән
Чынлап аңлашасы бар әле.

# ЯЗ

Табигать, төрледән-төрле
Төсләргә мана-мана,
Язын — яшел, кышларын ак
Җырларын яза бара.

Бардыр, бәлки, җыр язуны
Танырга теләмәгән,
Дөнья өчен Мәҗнүннәрчә
Янырга теләмәгән?..

Хәер, бу Табигатьтәге
Һәрни безгә бакый күк.
Ә ул — яза. Исән чакта
Танылмаган даһи күк.

## ПОЕЗДДА

Салкын тәрәзгә елышып,
Багана саный-саный,
Бөршәйгән бабасы белән
Кунакка бара сабый.

Алҗыган. Тәкатьсез. Сорый:
— Кайчан барып җитәбез?..
Поезд чаба. Арчаларны
Җилдәй узып китәбез.

Ә сабый төпченә һаман:
— Безне көтә микән ул?..
Бабасы юата аны:
— Кил, улым, бер уйныйк әле,
Син, әйдә, Харламов бул.

Уйныйлар. Борчак чиртәләр.
Голларны саный-саный,
Үксез язмыш поездында
Кунакка бара сабый.
Әнисенә.

## ТАРИХ

...Бруноga ут салган.
Хөрлек даулаган улларын
«Фетнәче» дип атаган.

...Ә бер көн, таң алдыннан,
Акылына килер дөнья,
Айныган сәрхуш сыман.

## ҮЗГӘРЕШЛӘР КӨТӘМ

Кошлар калган туктап бер ноктада,
Син калгансың туктап кыл уртада...
Мәңге шулай булыр, дисең мәллә,
Мәңге шулай барыр, димсең, эшләр?
Үзгәрешләр көтәм,
Үзгәрешләр.

Язмышыннан берәү йөзен сыткан,
Кай гаиләдә низаг-ызгыш чыккан,
Илләр чыраена илләр суккан...
Мәңге шулай барыр, димсең, эшләр?
Үзгәрешләр көтәм,
Үзгәрешләр.

Гадәтилек сарган уйларыңны,
Юлларыңны сарган, елларыңны...
Мәңге шулай барыр, димсең, эшләр?
Үзгәрешләр көтәм,
Үзгәрешләр.

## XX ГАСЫРГА ЭНДӘШҮ

Нинди әрсез дөнья —
Гүя ямьсез хатын.
Ә син шуның белән
Бер ятакка яттың.

Бер табактан булды
Җыйган тәгам-ашың.
Бер үк газап чиктең,
Бер үк йолдыз ачтың.

Бер мунчага йөрдең,
Бер ләүкәгә мендең.
Бер табага салып
Кыздырдылар телең.

Бер үк тимер кыршау
Кыса барды башың.
Бергә гүргә иңдең,
Бергә күккә аштың.

Ә ятакта инде
Ауный яңа гасыр...
Безнең гомер, әйдә,
Бәет булып калсын.

## МОНОМАХ БҮРЕГЕ

*Марсель Галигә*

Алтын Урда!
Азмы алтыннарың
Әверелгән ятлар күркенә.
Бүркең булса, бүре баласын да
Салып йөртер идең бүркеңә.

Син курганнар кебек яланбаш шул,
Ялган баш шул безнең чорга да.
Бүрегеңдә әнә каракошлар
Ике башлы бала чыгара.

## ТАРИХНЫ КИРЕДӘН УКУ

Хаким хәкимне санлап —
Зур булган.
Хәким хакимне данлап —
Хур булган...

## КОЛ

Ае — күк катында.
Уе — Мәккәләрдә.
Иле — йөрәгендә.
Теле — мәхкәмәдә.

## ЫРЫС КАПКА

Ырыс капка — урыс капка.
Бар аерма — бер аваз.
Урыс капкалар калыккан,
Ырыс капкалар аугач.

Ырыс капка — урыс капка.
Хәзер инде... җилкапка.
Җилкапканы кага-суга,
Җил дә сөйли шул хакта.

Урыс капка — ырыс капка...

## БИЛӘРДӘ ЙӨРДЕК БИ БУЛЫП...

*Батуллага*

Каласыннан кисәү калган,
Саласы һаман Биләр.
Биләрдә йөрдек би булып —
Турая төшсен билләр.

Даланың каганы булдык,
Аллаһның булдык колы...
Кызлар тавы итәгендә
Яшәдек чатыр корып.

Ә тау башында җиде кыз
Сыктыйдыр сыман һаман:
«Сәхтиян кимәс наз идем,
Чабата тапмай барам».

«Һәр кавышмакның соңында
Аерылмак бар икән...»
Шәһит кызларның күз яше
Чишмәләр булып типкән.

Шәһитләр күз яше белән
Сусынны басыйк без дә.
Хуҗалар тавына менеп,
Күз салыйк эргәбезгә.

## ИМЛА

Чөйләп язган балчык, ташка,
Ташлар исән һаман да.
Чөйязу булып эрегән
Тояк эзе Далада.

Иманына имам иткән
Аннан Коръән имласын.
Әлиф белән күккә язган,
Күктә тапкан кыйбласын.

Үле телнең имласын да
Ят итмәгән, күрәсең, —
Яңалифчә язмак булган
Үлемсезлек сүрәсен.

Әлифләре киселгән дә,
Хәлфәләре асылган.
Ярый әле өмет исән:
Кала ташка басылган...

# ХОЛЫК

Хозыр карт та үзгәрталмас
Коллык дигән холыкны...
Кеше сөймәс монафикълар
Сөеп яшәр халыкны.

# ХАЛЫКАРА ХӘЛ ТУРЫНДА

Бар дөньясы кабатлыйдыр —
Әйтерсең лә тутый кош:
— Сепаратист...
— Виагра...
— Террор...
— Ислам...
— Путин...
— Буш...

## ТАТАР

Идел-йортның нигезенә
Субай итеп кагылган ул.
Бу дөньяга тартар булып,
Татар булып танылган ул.

Татар булып яшәүләре
Бу дөньяда кыен шуңа.
Шуңамы ул, субай килеш,
Сукбай кебек кыенсына.

Кыенсына үткәненнән,
Үз-үзеннән кыенсына.
Даруын да, агуын да
Йөрткән садак-кынысында.

Бала кебек көлемсерәп,
Дала яткан кочагында.
Ятка — дару, агасына
Агу биргән кайчагында.

Дәүләт арты дәүләт корган —
Булган шундый сәләте дә.
Төшенмәгән үзе ләкин
Дәүләт тоту сәнгатенә.

Бүленгәнне бүре ашар,
Дия-дия бүленгән ул.
Типтәр булып, башкорт булып
Исән калган үлемнән ул.

Исән калган нугай булып,
Әйләнеп йә керәшенгә.
Бүленгән ул, бүлгәләнгән,
Инде вакыт берләшергә!

Акбүз, диеп, тулпар, диеп
Атаган ул чаптарын да.
Мишәр әнә, лыкыр, дия
Безнең Казан татарын да.

Ничә гасыр шайтани рух,
Татар, диеп кыбырсына.
Бу дөньяда татар булып
Яшәүләре кыен шуңа.

## ТАРИХ БЕЗГӘ СӘЕР СЕР КАЛДЫРГАН

Кем әйткәндер, кайчан әйтелгәндер,
Кайсы чордан, кайсы еллардан
Киләдер ул сәер сүз-гыйбарә:
«Татар тугач, яһүд елаган».

Ник елаган? Ни сер посып яткан
Бу китаплы кавем кальбендә?
Кайчагында аңлау кирәктер ул
Дөнья тоткан халык хәлен дә.

Булган ансы, әйе, татарның да
Дөнья тоткан гаярь чаклары.
Дөнья түмгәгенә абынып ла
Билен сындырган шул чаптары.

Татарны да, әйе, сөргеннәргә
Сөргән баскын туган җиреннән.
Без дә, бәлки, үз-үзебезләрне
Кабат җиңәр өчен җиңелгән?

Татарның да, әйе, язмышлары
Кузлы Сагыш белән чигелгән.
Без дә, бәлки, асыл кальбемезгә
Кабат кайтыр өчен сибелгән?

Үткәннәрен эзләп табар халык
Киләчәккә кайтыр юллардан.
Тарих безгә сәер сер калдырган:
«Татар тугач, яһүд елаган».

# II БҮЛЕК





# КАНАТЛЫ СҮЗ

*Диптих*

## 1

Дөньяның фани уйларын
Уйлаудан тәмам туеп,
Урам буйлап килә идең —
Тәгәрәп китте уең.

Тәгәрәпләр китте уең,
Ялгыз дүңгәләк кебек.
Уең артыннан шаян җил
Йөгерде терек-терек...

Сикәлтәле тыкрык-юллар,
Кечке урамнар буйлап
Тәгәрәде бәйсез уең, —
Уең да бүген буйдак.

Үткән-сүткән көлеп калды:
«Ерак баралмас — бетәр...»
Иректле, бәйсез уеңны
Иснәде килеп этләр.

Иректле, бәйсез уеңны
Көпчәкләр үтте таптап.
Урам ташларына ятып
Калды тик шәүлә-таплар.

Ә син үзеңне төн буе
Юатырсың: «Бул сабыр!»
Иртән урам себерүче
Тагын сукранып алыр, —

Һәм синең бәйсез уеңны
Чүплеккә илтеп салыр.

**2**

Бәйсез уйдан Сүз ярала, —
Канатлы Сүз. Кош сыман.
Үрмәләп чыгар ул чүп-чар
Хәшәрәт арасыннан.

Әй очыныр, әй талпыныр,
Калтырар үзе. Туңар...
Ачык тәрәзәңнән кереп,
Каләмгә килеп кунар.

Кагынып куяр...
Чүп-чары
Коелыр кәгазеңә.
Мәңгелектән бер өн булып
Төн чиртер тәрәзеңә.

Тәрәз артында шаркылдар
Тук, исерек ташкала...
Сискәнеп куяр кошчыгың,
Яшең тамар ташларга.

Яшең тамар таш идәнгә,
Тамар таш йөрәкләргә.
Таш диварлар әсирлеге
Җаныңны йөдәткәндә,

Бәреләсугыла кошчык
Очып йөрер бүлмәңдә.
Мәңгелек күк гүзәл мизгел
Туктап калыр бу мәлдә.

Мәңгелек күк гүзәл мизгел
Җаныңда торыр зеңләп.
Туасы таң агып керер
Шыр ачык тәрәзеңнән.

Акшарланган таш читлегең
Яктырып китәр, балкып...
Шыр ачык тәрәз артында
Шаркылдап көләр Вакыт.

Сискәнеп куяр кошчыгың,
Сискәнеп куяр каләм...
Һәм
хәнҗәрен
батырыр
*Вакыт*
Йөрәгеңә кадәр...

# ТЫНЫЧЛАНУ

Мәхәббәттән талчыкканмы —
Хисләре калган телдән.
Ярын теле аңларга ул
Беркатлы җаны белән.

Гаугалардан арыганмы —
Кан сауган калебенә.
Чорны теле аңларга ул
Риясыз җаны белән.

Хәтерләүдән ялыкканмы —
Хәтере ауный көлдә.
Тарихны теле аңларга
Ул мәҗрух җаны белән.

Әллә үзеннән туйганмы —
Кан тама каләменнән.
...Вакытны теле аңларга
Ул фани җаны белән.

## ХӘЗЕРГЕ ХӘЛЕМЕЗГӘ КАРАТА

Әманәтләр ак буладыр,
Хыянәт — кара төстә...
Аксакаллар китеп баргач,
Шакаллар калка өскә.

## БАР ЯЗГАНЫ...

Ыспай, шома егетләргә
Дөньяда шөгыль күптер...
Ә бу — әдип...
Бар язганы —
«Чыктым аркылы күпер».

## СУКБАЙ

Син күрәсен кем дә күрмәс,
Кем дә үлмәс синең өчен.
Бу дөньяга ни сүзең бар,
Калды нинди дәгъва, үчең?

Бу дөньяга нигә килдең,
Нигә иңдең бу җиргә син?
Яшәү дигән алышларда
Җиңеләсең йә җиңәсең.

Сөлге тотып чыккан идең
Яшәү дигән алышларга.
— Хәрәмләшмә, — диде Күкләр, —
Башларыңа каргыш алма.

— Хәрәмләшмә, — диде тәкъдир, —
Хәрәм белән җиңү — язык.
Хәрәмләшмә — үзеңнән соң
Калмаса да сыңар казык.

Казыкмыни — азык кирәк
Вакыт дигән хөкемдарга.
Франсуа Вийоннарын
Чорлар һәрчак көткән дарда.

Казыкмыни — кызык кирәк
Тарих дигән тамашага.
Пиросмани җәйранын да
Алмашкан ул алашага.

Ә синең бу дөньялыкка
Ни дәгъваң бар, нинди үчең?
Син күрәсен кем дә күрмәс,
Кем дә җиңмәс синең өчен...

# М.Ә.

Безнең чорның Тукае ул, диләр,
Аккош күлендәге урманда
Юкка гына, димәк, яшәми ул,
Язган аңа, димәк, туңарга.

Гасыр башы әнә Тукайга да
Куыш таба алмый кичеккән.
Бөекләрнең бәхетсезлеге дә
Биләүдән ук килә, бишектән.

Шулай сөйли гафләт.
Аңа да бит
Бер аклану кирәк ничек тә.
Ә дөньялар матур күренәдер
Тимер ишектәге тишектән...

## МӨХӘММӘДЪЯР

Вакыт җилгәргәч, бәндә дә
Орлык йә кибәк була.

Кайчак шәхесне аңларга,
Кайчак шәхесне данларга
Биш гасыр кирәк була.

## ХЕМИНГУЭЙНЫ УЙЛАП

Буразнага тамган тамчы тирнең
Бәһасе ни, димсең, күпме тора?..
Болытларга багып уйга калган
Башаклардан сора,
Башаклардан сора.

Ир күзеннән тамган тамчы яшьнең
Бәһасе ни, димсең, күпме тора?
Бәхет тулпарыңны урлап качкан
Сөйгәнеңнән сора,
Сөйгәнеңнән сора.

Бәгыреңнән тамган тамчы канның
Бәһасе ни, димсең, күпме тора?..
Вакыт үзе келәймәсен суккан
Җырларыңнан сора,
Иманыңнан сора...

...Бер пистолет
Бер мең доллар тора...

## ДӘРВИШ

Табынганы — Күк-Тәңредер,
Очар коштыр,
Сагынганы — туган тияктер...
Бу дөньядан аңа берни кирәк түгел,
Ул дөньяга, бәлки, кирәктер.

# ҖАН СУРӘТЕ

Күбәләккә генә әверелә калса
Фани дөнья кичкән һәр бәндәнең җаны,
Нинди мәгънәсез булыр иде хәят!
Нинди мәгънәсез булыр иде дөнья!

Ә Табигать, шөкер, гадел хөкем итә,
Шөкер,Табигатьнең кануннары башка:
Кемнең җаны әверелә гөл-чәчәккә,
Кемнең җаны әверелә ташка.

Кемнең җаны әверелә утка, суга,
Кемнең җаны әверелә үрмәкүчкә,
Кемнең җаны әверелә кыя-тауга,
Очар кошка,
йомранга
йә кәлтәгә...

Мәгънәлерәк булсын дип җирдә яшәвем,
Мәгънәлерәк булсын дип җирдә үлемем,
Җан сурәте —
Илаһ Табигатькә
Сәҗдә кылам бүген.

## ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА!

*Аяз Гыйләҗевкә*

Бу дөнья сезнең дә, агай,
Иңнәрдә тора...
Фәрештәләр куәт бирсен —
Йәгез, бер дога!

Ил корабы фарватерда
Утырган комга...
Бурлак булып җигелгәнсез —
Йәгез, бер дога!

Кулларга зынҗыр салынган,
Уйларга — богау...
Зынҗырсыз җыр саулыгына —
Йәгез, бер дога!

Исәр заман дулый һаман —
Вата да кора...
Хәрабәләр рухына —
Йәгез, бер дога!

Күп яшәлде бисмилласыз —
Кичерсен Хода...
Сәҗдәгә китәр чак, агай,
Йәгез, бер дога!..

Йәгез, бер дога...

# КАЙТАВАЗ

> Һавалар тын...
> Кыеп очкан һома* юк...
> Азан ишетелсә дә,
> кыйбла-нөма юк!..
>
> *Дәрдемәнд*

Безгә дә — нәкъ җырдагыча —
Килде рәхәт заман...
Гафләт йокысыннан безне
Уятып бак, азан.

Моңың белән тула барсын
Күңелдәге бушлык...
Көн дә әнә җыр сузалар,
Алла исмен кушып.

Аллага шөкер, ди, дәһри
Фирка уллары да.
Аллага шөкер, ди, денсез
Казна бурлары да.

Төшемле эштән соң салып
Алгач саллы гына,
Күтәрәләр чәркәләрен
Ходай саулыгына.

«Безнең тирәккә дә, — диләр,—
Бәхет кошы кунсын».

...Татар бае Хаҗга киткән —
Хәерлегә булсын!..

---

* Һ о м а — бәхет кошы.

# УРМАНДА

Иду на вы.
*Кенәз Святослав*

Өркү нигә,
гөлкәйләрем? —
Чалгы тотып килмәдем.

Кошкайларым,
оягызны
туздырырга килмәдем.

Каеннарым,
себерке йә
дүркә* эзләп килмәдем.

Сөйләшик бер, серләшик бер,
Җаннарыбыз бер ләса...
Аңлашырбыз гүзәллек һәм
Язмышлар теле аша.

* Дүркә — мунча себеркесе.

* * *

Тыңла әле мине,
Җирнең бер сукбаен.
Кайсы өммәттән син,
Милләттән син, каен?

Кайсы милләттән син,
Мин үзем — татармын.
Илем күк изелдем,
Телем күк тапталдым.

Чү, яра түгелме
Синең дә тәнеңдә.
Тәнеңдә — язулар,
Тәнеңдә — тәреләр.

Тәнеңдә — язулар,
Зәхмәттер бу, зәхмәт.
«Булды монда Иван,
Булды монда Әхмәт...»

Беләм, минекеннән
Аз түгелдер кайгың...
Кайсы өммәттән син,
Милләттән син, каен?

## СӘЯСИ СОРАУ

Һәрбер ялган
Дөрес булып
Күренә генә.
Ялганга ышанмый
Халык —
Күнегә генә.

Ник ялган, алайса,
Илнең
Түренә менә?..

## КАРТЛЫК

Чишмәләр картая —
Саега, саега...

Кешеләр картая —
Сагына, сагына...

Картая төп нигез —
Күңелдә шом, сагыш.

Дәүләтләр картая —
Сәясәте сәрхуш.

## СИСКӘНҮ

Көзге ачы җилләрдә
Фетнә чыккан илләрдә.
Безнең башка ни язгандыр —
Тәрәзәмә җил бәрә.

*25 октябрь, 1997*

## ИҖАТ

Сүзләр сиңа сырхау булып килсә
Һәм бацилла булып тулса мигә,
Баш чатнаса әгәр, кысса чигә, —
Сүз махмыры сабыштырса чиргә,
Хур кызлары кертер сине игә.

Сүзләр сиңа сихәт булып иңсә,
Һәрбересе туй күлмәген кисә,
Һәрбересе, мин — синеке, дисә, —
Сүз ләззәте сабыштырса чиргә,
Мыжык корткаң кертер сине игә.

## ҖЕТЕ

Әлмисактан килгән йола
Дәвам итә һаман да —
Бүлгәлиләр адәмнәрне
Яхшыга һәм яманга.

Бүлгәлиләр адәмнәрне
Карага яки акка...
Мин дә, бәлки, гөнаһлымын —
Шәраб эчәм кайчакта.
(Җете ак, кара булудан,
Ходаем, үзең сакла!)

Мин дә, бәлки, гөнаһлымын —
Гашыйкмын сылуларга.
Эт җитәкләгән ханымның
Эте булып уларга
Ризамын хәтта.

Мин дә, бәлки, гөнаһлымын —
Көнләшәм көчлеләрдән,
Җиргә хаклык уты биргән
Прометей төслеләрдән —
Көнләшәм көчлеләрдән.

Мин дә, бәлки, гөнаһлымын —
Чаманы җуям кайчак.
Дус-ишләргә авыр сүзләр
Әйткәләп куям кайчак.
Мине дә мана кемнәрдер
Җете кара йә акка.

...Тик бүленмәс, Кешем, җаның
Җете кара йә акка —
Иман дәүләтең чигендә
Вөҗданың торыр сакта.

# БАЛА КҮҢЕЛЛЕ АГАЙ

*Миңшәех Зәбиргә*

Язмышның үксез йортында
Ул да күшеккән, туңган.
Ә үзе
        ил-көнгә
                жылы
Өләшер өчен туган.

Язмышның кара атына
Йөргән ул да атланып.
Унбиш яшьтә ат казанган
«Бунтчы» дигән ат алып.

Ул көннәрнең шом-зәхмәте
Әле дә җанда, канда...
Илең белән ачыкканда,
Фетнәче булмый кара.

Матбага, дип, матбугат, дип,
Ил белән ачыкканда,
Фетнәче булмый кара син,
Фанатик булмый кара.

Сүнмәсен, сүрелмәсен дип,
Матбугат атлы учак,
Гомерләрен чыраг итеп
Телгән ул кочак-кочак.

Матбаганың шәехе ул,
Шәех уе кальбендә.
Бу дөньядан гел яхшылык
Көтеп яши әле дә.

Олпат күңелле бала ул,
Бала күңелле агай, —
Бу дөньяның үзен дә бер
Сабый дип белә бугай...

* * *

Җир гамьнәре тулы, моңнар тулы
Җаннарыгыз гүя бизмән ул.
Кешелекне изгән авырлыкны
Күтәргән ул, әмма түзгән ул.

Вөҗданлылар һәрчак киеренке.
Тубыктан ук җиргә батса да,
Күтәрәләр, заманалар кайчак
Базарына илтеп сатса да.

Күтәрәләр... Гомерләре исә
Мәңгелеккә очып бәреләә...
Фидакярләр эше дәверләрнең
Каны булып тама бәгырьгә.

Чыраена чәчри залимнәрнең
Кайсыгызның каны? Кем каны?
Вөҗданнары барлар һәрчак шулай:
Күтәрәләр Намус кушканны.

# ТҮБӘ

*Поэма*

*Фәйләсуф төзүче*
*Марат Бибишевкә*
*багышлыйм*

## 1

Өйләр сала халык, өйләр сала —
Агачтан да сала, таштан да...
Чулман аккошыдай ап-ак калам
Җырга әверелгән, дастанга.

Өйләр сала халык,
                    өйләр сала,
Чулман гына никтер моңая.
Өйле булсын һәркем,
көйле торсын —
Заманасы көйсез болай да.

Өйле булсын һәркем...
Хыялыбыз
Аккош булып күккә ашканда,
Җисеменә лаек исем тиеш
Һәрбер җырга, һәрбер дастанга.

Кемнәр анда «төзәтмәләр» кертә
Халык язмышына, тарихка?!
Патшаларын Алла итеп чөйгән
Заманнардан гыйбрәт алыйк та

Җисеменә лаек исем кушыйк,
Лаек исем —
Җырга, кешегә.
Хакимен дә, хәкимен дә заман
Бәяләсен карап эшенә.

Ни кылсак та, әнә
Чулман шаһит,
Идел шаһит —
Алар күп күргән...
Баш очында түбән булу кирәк,
Түбән булу кирәк —
Үз түбән.

Баш очында түбән булу кирәк —
Катмарлы да яшәү, гади дә...
Йортсыз-җирсез, тома сукбайлыкта
Гомер иткән азмы галиләр?!

Ә без бүген килеп баш орабыз
Алар мирас иткән байлыкка.
Фатирлы да, хатынлы да килеш
Мөмкин әле яшәү
Сукбайлыкта.

Ни кылсак та, әнә
Чулман шаһит,
Идел шаһит —
Алар күп күргән.
Бу дөньяда түбән булу кирәк,
Лаек түбән булу —
Үз түбән!

## 2

Шагыйрьләр авылда туа,
Авылда һәркем шагыйрь:
Мәшһүр балта осталары,
Миччеләр, тимерчеләр,
Итекчеләр, көтүчеләр,
Йөкчеләр, игенчеләр...

Алармы шигырьсез яши,
Алармы шагыйрь түгел?!
...Авылга шагыйрьләр җитми,
Шагыйрьгә кытлык бүген.

...Сөрелгән зират,
        авыллар
Рәнҗеп ята, күрәсең...
Шагыйрьләр авылда туа —
Ник шәһәрдә үлә соң?!

3

Шагыйрьләр шәһәрдә үлә...
Төшендем күк мәгънәсен:
Мин дә шәһәргә елыштым,
Шигырь язам, янәсе...

Мин дә шәһәргә елыштым,
Янәсе, шулай тиеш...
Яшим әлегә фатирсыз
Һәм пропискасыз килеш.

Зарлануым түгел ансы —
Яшим һәрчак искәреп:
Иҗатта фатирлы бул син,
Иҗатта — пропискалы.

Иҗатта дәрвиш, сукбайлар
Таш йөртер куенында.
Үз калаң булсын җанында,
Калганы — уен гына...

Үз калаң булсын —
Ташкалаң!

Күңелләргә баш калаң!
...Халыкка мирас булып та
Күбрәк шул ташлар калган.
.........................................
... Ташлар иңри — Сөембикә
Кояшка сузган кулын.

Ташлар иңри —
Хан төрбәсе,
Кече манара булып.

Ташлар иңри —
Каберташлар —
Кемгә — нигез ташлары...
Булган заман: ташларның да
Кылыч кискән башларын.

Булган заман: халыкларны,
Таш бәйләп муенына,
Кол иткәннәр...
Күргән ташлар
Вәхшиләр уенын да.

Ясак түләгән халыклар
Шәһәрләтә, ташлата.
Юккамыни шагыйрьләрнең
Бавырында таш ята.

Шагыйрьләр шәһәрдә үлә...
Төшендем күк мәгънәсен.
Мин дә шәһәрләшә барам,
Шулай тиеш, янәсе...

## 4

Үз бәхетен үзе таба халык,
Бәхет көтеп ятмый Алладан...
Ел да әнә, сабантуйлар җитсә,
Авылдашлар кайта каладан.

Авылдашлар кайта сабантуйга,
Бохарадан кайта, Донбасстан.
Авылдашлар кайта...
Иңсәләрен
Биштәр түгел, гүя моң баскан.

Ә биштәрдә — кала күчтәнәче —
Әфлисуны, лимон, кавыны...
Бөтен авыл бүген кавын ашый —
Кавын тансыклаган авылым.

Авылның да үз хөрмәте, сые —
Каклаган каз, әйрән, катыгы...
Кунакларга әйрән, катык булсын —
Кирәксенмәс шуннан артыгын.

Тәмләп кенә әйрән эчә алар,
Тәме шул ук, юкса таныш тәм.
Бары бераз ачылана төшкән,
Ачылана төшкән сагыштан.

Авылым да уйчанланып калган —
Ул күнеккән инде көтәргә...
Ишегалларында, тыкрыкларда
Ешрак өрә бүген этләр дә.

Ятсынып мы өрә...
«Кунак» сүзе

Таныш түгел бугай аларга.
Ә калада этләр өрми.
Этләр
Борынчыклы була калада.

Ә калада этләр күндәм була,
Күнгән була әмер теленә.
Ә калада сукбай этләр генә
Шыңшып йөри подъезд төбендә.

Ә шуларга кемдер таш ыргыта,
Малай-шалай уза типкәләп.
И Табигать, син дә үксез мәллә —
Ник этләрең йөри типкедә?!

Ни атлары, кушаматлары юк,
Кемгә хаҗәт этләр кайгысы?
Ә авылда этләр атлы була,
Кушаматлы була һәркайсы.

Әнә Акбай...
Кунак икәнеңне
Яшерермен димә аңардан.
Шундук сөрән салыр:
— Каладашлар,
Подъезддашлар кайта каладан.

Әнә Сарбай...
Дымсу карашыңны
Яшерермен димә аңардан.
Шундук сөрән салыр:
— Шахтадашлар,
Язмышташлар кайта каладан.

...Сыздыр, тальян, «Шахта» көйләренә,
Чиләбедән, Төмән, Донбасстан

Авылдашлар кайта...
Иңсәләрен
Биштәр түгел, гүя моң баскан.

**5**

...Муенчагын өзеп этләр кача —
Этләүдәнме тели котылырга?..
Ә мин игълан укыйм «Атналык»тан:
— Эт югалды —
колли токымыннан.
Эт югалды —
гибрид шәҗәрәле!

Холкы күндәм иде, нәсле — затлы!
Эт югалды —
табышыгыз, зинһар!
Эт югалды —
Платон кушаматлы!

...Платон белән бәхәсләшми генә
Мин игъланнар укыйм «Атналык»тан:
— Гражданнар, табышыгыз, зинһар,
Гаип булды акчам, алтын алкам!

Дөнья белән бәхәсләшми генә
Мин игъланнар укыйм кырын ятып:
— Чын ир белән телим танышырга,
Бирнәм — фатир булыр, юрган, ястык.

Аңламассың —
Соңгы мода кебек
Бу дөньяның холык-фигыльләре...
Хатыннарын ташлап ирләр китә,
Шагыйрьләрне ташлап — шигырьләре.

Аңламассың —
Сальери күк иске
Бу дөньяның гайбәт, донослары...
Зынҗырларын өзеп җырлар кайта —
Сынмас Муса кебек намуслары.

Җырларның да, әйе, намусы бар —
Себер киткән башы җырларның да.
Чылбырларын өзеп чорлар кайта —
Югалганы була чорларның да.

Табу салсаң әгәр чын тарихка
(Чынлык та, һай, кайчак хәтәр әле),
Дастаннардан алыплары качар,
Кешеләрдән качар хәтерләре.

...Ә сезгә мин, ханым, бәхет телим,
Танышыгыз, сөеп кавышыгыз.
Җирдә әле шундый игъланнар бар:
— Вөҗданымны җуйдым —
Табышыгыз?!

## ӘЙТТЕЛӘР...

Йөрәгенә батман-батман
Кан сауды... калды авып.
Әйттеләр: «Бирде, — дип, — илгә
Соңгы шигырен савып».

## БИЗМӘН

Гомер дигән учакларның
Актардың күмерләрен.
Әнкәңнең бер тулгагына
Лаекмы гомерләрең?

## СОҢГЫ МИЧЧЕ

Бу дөньяда гөнаһлары булса,
Хак Тәгалә үзе кичерсен.
Соңгы юлга озаттылар бүген
Авылның иң соңгы миччесен.

Бер гөнаһсыз яшәп булса икән
Гөнаһларга баткан дөньяда.
Соңгы мичче кичте дөньялыктан,
Соңгы миче калды — өр-яңа.

Түбән очның Түрә Мочтагында
Соңгы миче калды... морҗасыз.
Өлгермәде... Ярлыкасын Хода...
Бу авылның әле моңарчы

Манарасыз, айсыз мәчет кенә
Күргәне бар иде... күмгәне...
Манарасыз мәчет түбәсендә
Инкыйлабның канлы көлмәге

Җилфердәгән иде җилфер-җилфер
Заманадай ачы җилләрдә.
Дошманны — дус, дусны дошман итеп
37 чөйде җирәбә.

Шөрепчектәй боргалады еллар
Соломонын, Әхмәт, Иванын...
Яңа иман иңдермәкче булды,
Манарасын кисеп иманның.

Манарага кунган көмеш Айдан
Дәһриләр койды айбалта.
Кемнәр — антын, кемнәр халкын сатты —
Кояшлата сатты, айлата.

...Бүген менә соңгы мичче китте,
Кайтмаска дип китте яңадан.
Җирләшергә малайлары кайтты,
Оныклары кайтты каладан.

Туган йортка кайтса, улларының
Гел җигүле булды атлары.
Миччесез дә калдык, ахири, дип
Дога кылды авыл картлары.

Кем җылытыр инде ызбаларны,
Кем җылытыр инде елларны?..
Төннәр буе җил улады тышта,
Төннәр буе мичләр елады.

Мичләрнең дә үз гомере була,
Утлы гомере...
Яна...
Ишелә...
Төннәр буе мичләр елап чыкты,
Тик моржасыз калган мич кенә

Еламады...
Хуҗа, гадәтенчә:
«Исән булсын, — диде, — баш кына».
Иртән авыл яңа төш юрады,
Юрамады ләкин яхшыга.

## МАХМЫРДАН ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬ

Айнымас сәрхуш шикелле,
Аякта торам көчкә —
Утын әрдәнәсе кебек
Ишелә көннәр өскә.

Ишелә көннәр... Егылам...
Түнә баш... Каный канат...
Яньчелә чырай...
Дөньяга
Мүкәләп чыгам кабат.

Мүкәләп чыгам дөньяга
Пүләннәр арасыннан.
Коелып төшәм Вакытның
Шелтәле карашыннан.

Ул гүя эндәшә миңа,
Үлемсез дәрвиш сыман:
«Тәкъдиреңне тәгъбир итеп
Әйтергә ашык, олан.

Сугарлар да, кагарлар да,
Куәт ал кагылудан.
Гомер дигән иҗат, олан,
Тора ул абынудан.

Абынудан тора тәкъдир —
Калалмас тотып беркем.
Ил агасы да сәфәргә
Таягын ала беркөн.

Сәфәрең көтә сине дә,
Юлыңа яткан томан.
Абынсаң, минем таякка
Абынып егыл, олан».

Шулай эндәште күк дәрвиш
Өнемдә, әллә төштә.
Ә мин болай да, сәрхуш күк,
Аякта торам көчкә.

* * *

Соңгы юлга җыенганда,
һәркемнең күңел дәрьясы
изге уйлар —
васыятьләр белән тула.

Хәтта гомер буе
гөнаһ кылган бәндә күзләрендә
кешелекле бер уй була.

Күп вакытта
иң хак сүзләр
нәкъ шул чакта әйтелә дә!

...Ә исәннәр
һәрбер сүзне җөпләп тора,
алтын тапкан малкуардай,
һәрбер сүзне
хәтеренә салып тора...

## ГАЙСӘ ЯШЕ

Ел да бер кат котлый дус-иш:
— Мең ел яшә.
Хәтәр яшькә җиттем мин дә,
Хәтәр яшькә.

Хәтәр яшькә җиттем мин дә —
Утыз өчкә.
Кара кеше ябырылып
Килә өскә.

Мин ышанмыйм аны ялгыз
Җиңәремә.
Фәрештәләр өркеп кача
Иңнәремнән.

Очып куна иңнәремә
Мәкер, ялган.
Дөньям тулы җаһил, җасус —
Азау ярган.

Күкрәгемне тишеп үтә
Кара гайбәт.
— Мең яшә, — ди дус-иш, — булыр
Барсы әйбәт.

Утыз өчтә төрле уйлар
Килә башка.
Беләм ансы, әйбәт булыр
Миннән башка.

Беләм ансы, кемдә, хәер,
Кемнең эше...
Иңнәремә кулын сала
Кара кеше.

## ГӘПТӘШЛӘР

Кичке якта,
фани борчулардан арына төшкәч,
подъезд ишеге төбендә,
агач эскәмиягә утырып,
картлар гәпләшә көн дә.

Кайсы оныгын иярткән,
кайсы — этен,
кайсы тәмәке төрә...

Картлар гәпләшә.

— Кышы бигрәк салкын иде,
игеннәр уңды микән?
— Безнең Өчиледә быел
сабантуй булды микән?

— Көтү дә кайткандыр инде...
— И кордаш, сагышланма.
Печәнгә төшкәндер халык
безнең Салагышта да.

Картлар гәпләшә.

Кичке якта,
подъезд ишеге төбендә,
агач эскәмиягә утырып,
картлар гәпләшә көн дә...

# ШАГЫЙРЬНЕҢ КАЙТУЫ

*Баллада*

Әйт әле, күбәләк...
*Г. Тукай*

Бу дөньяның һәрбер мәхлугына
Эндәште ул сөеп, олылап...
Әй шатлана иде күбәләкләр,
Нәни Апуш килсә болынга.

Сөйләшәләр, серләшәләр иде,
Аңлашалар иде җан аша.
Күктә очар өчен яралганнар
Бер аңлаша икән, аңлаша.

...Болын гүя бер мәдрәсә бүген,
Гөл таҗлары — китап. Күр, әнә,
Габдулланың иңнәренә кунып,
Дәрес тыңлый барча күбәләк.

Табигать тә ләм-мим, тынып калган,
Шук җилләр дә тартмый чабудан...
Сөйли Апуш, дәшә вәкарь белән:
— Без иректе — димәк, бертуган!

Күбәләкләр гүя шәкерт бүген,
Табигатьтә — хәйран тамаша.
Утта янар өчен яралганнар
Бер аңлаша икән, аңлаша.

...Ә бер көнне Апуш гаип булды.
Көтте аны болын, дуслары.
Алар әле белми, белми иде
Базар барын җирдә, мал барын.

Ятим калды болын, күбәләкләр,
Габдулладан көн дә хат көтте.
Саргаешты гөлләр...
Ромашкалар,
Ярын җуйган кыздай, яшь түкте.

Ә хәбәрне җилләр алып килде,
Ә хәбәрне җилләр таратты:
— Апушыбыз Шагыйрь булган ласа,
Тугры Тукай атлы!

Дустыбызның хәлен белеп кайтыйк,
Сәлам илтеп кайтыйк бергәләп.
...Клячкинның салкын тәрәзендә
Бәргәләнгән ялгыз күбәләк

Очып кунды шулчак таң нурына
Һәм эндәште Көнгә олылап:
— Саумы, Кояш!.. —
Шагыйрь җаны кабат
Хөр Ватанга кайтты, болынга.

# ӘСИРЛЕК

*Х. Т.*

Нинди гүзәл әсирлек син, Иҗат!
Мин үземне тоткын диярга
Лаек булсам әгәр, кирәк түгел
Аклаулар да, амнистия дә.

## ТАШ

*Рәшит Әхмәтҗанга*

Шагыйрь тәрәзенә таш аттылар, —
аһ, ваттылар, —
чәлпәрәмә килде тәрәз.

...Метафоралар белән
чуарланган кәгазь
телдән калды кинәт.

...Киштәдәге шигырь китаплары —
Назон,
        Лермонтов,
                Җәлил,
                        Туфан
ныграк сыендылар бер-берсенә.

...Читлектәге минор кенәриләр,
әверелеп нота-көйгә,
ташландылар ватык тәрәзәгә...

...Дивардагы кадими сәгатьнең
бөкшәйгән хаста күкесе,
сукрана-сукрана,
Вакыт тирәли йөрде очып.

...Онытма, Көн!
Бүген төнге 1дә
таш бәгырьләр
        таш аттылар
Шагыйрь тәрәзенә.

Һәм качтылар.

Сорау билгеседәй бөкрәеп,
ашыга-ашыга
кереп югалдылар
Айлы төн эченә.

# ӘТРӘК-ӘЛӘМ

*Гамил Афзалчарак*

Заманалар авыр, юллар ябык диеп,
Әй сызланган, сызган сабыр гавам,
Әнә арлы-бирле лимузинда чаба
Әтрәк-әләм.

Мөнбәрләргә менеп дөрес сүзләр сөйли,
Ә кылганы — язык, ә кылганы — хәрам.
Кәеф-сафа корып, чит илләрдә йөри
Әтрәк-әләм.

Иң кыюлар һәрчак мәйдан уртасында,
Кем кулында — балта, кем кулында — каләм.
Сул аягы белән шигырь-мигырь яза
Әтрәк-әләм.

Заманалар авыр, юллар ябык диеп
Сыза-сыза узган — аһ! — гомерләр әрәм.
Ызгыш-фетнә ясап, тәхеткә үрмәли
Әтрәк-әләм.

Һәркемгә дә, бәлки, кош булырга язган —
Һәркемне дә ләса йота беркөн галәм.
Бәхет кошын кыздырмакчы була
Әтрәк-әләм.

## ТУГАН ЙОРТТА БАЛАН ҖЫЙГАНДА

Тәлгәш-тәлгәш баланнар —
Күзге учак кузыдыр...

И гомерләр...
Туган йорттан читтә
Җылы эзләп узган гомерләр.
Дастаннардан килгән мосафирның
Башмагы күк тузган гомерләр.

И Туган йорт...
Акбүз биләвем син,
Кабык арбам,
Киндер бишегем!
Әткәм-әнкәм күңеледәй
Һәрчак
Ачык синең капка-ишегең.

Туган йортта һәр тупылга кардәш,
Һәрбер өянкегә туган мин.
Әнкәемә кайтып сыенам да
Туган йортта кабат туам мин.

Туган йортка кайтып дәваланам
Җирсү дигән сәер хастадан.
Сихәтләнгәч,
дәрвиш-мосафирдай
Ник сәфәргә кабат ясканам?

Беләм, әйе, соңгы сәфәргәчә
Җылы эзләп йөдәр күңелем...
Туган йортта
күзге учакларның
Кайнар кузын алдым үрелеп...

## КОЛ БУЛГАНЧЫ...

Кол булганчы көлгә әйлән —
Ашларсың Туган җирне.

Көл булганчы гөлгә әйлән —
Ямьләрсең Туган илне.

## КОЛ ГАЛИ СУРӘТЕНӘ КАРАП

Кол Галидән кыйсса калган,
Сурәте — фараз, гөман...
Ә бездән сурәт каласын
Төгәл беләм, фаразан.

## ДИЛЕММА

Бәндәләрдән
    мең бәлаләр
        күрә-күрә
Сулкылдый Җир —
    өянәкле
        бәгыребез.
Сөйгәннәрнең
    ирененнән
        аерылып,
Шул бәгырьне
    бер үбәргә
        әзерме без?

## КАРТ МӘЧЕ

Адаштырмакчылар иде —
Адашмады — җаен тапты:
Хуҗасының бәбәгендә
Шәүлә булып кайтты.

## ШАГЫЙРЬ

Күкрәк читлегеңдә ни пышылдый,
Нинди кош моңая?..
Канатлыга һәрбер читлек — зиндан,
Канатсызга — оя.

## ЮРАЛМАГАН ТӨШ

Рухи манараңны турайтырга
Иман кирәк,
җитми көч кенә...
Мин коточкыч бер төш күрдем бүген —
Сөембикә ауды өстемә.

# ӘТИ ПОРТРЕТЫНА ШТРИХЛАР

*Триптих*

## I

Мин туганны көткән җирдә бөтенесе
бишек
кабык арба
ата казлы урам
мин туганда
уптым
кукуруз иккән халык
мин туганда
әти
утыз яшьтә булган
мин туганда
әти
авыл тимерчесе
кыршаулаган көпчәк
дагалаган атлар
хәзер дагаламый
нәрсә дагаласын
атсыз калды авыл
ат бүлешә татар
мин туганда
әти
бик-бик сабыр булган
мин туганда
әти
сандал төйгән бушка
тавыклардан
казна
налог алган чакта
бушка эшлә диеп аңа кемнәр кушкан
мин туганда
әти

авыл тимерчесе
казна башлыкларын
белгән ләкин яттан
мин туганда
Вакыт
бик болгавыр булган
мин туганда
Сталин
Мавзолейда яткан
мин туганны көткән җирдә бөтенесе
ата казлы урам
бишек
кабык арба
мин тугач та
әти
мулла дәшкән өйгә
мин тугач та
авыл
манарасыз калган

## II

манарасыз калган
өч мәчетле авыл
өч мәхәллә буйлап
киткән имеш-мимеш
мин туганчы
әти
унбиш яшьтә булган
үгез җиккән
әти
япь-яшь малай килеш
япь-яшь малай килеш
әти
урман кискән
ниргә салышкан ул
Җиңү алласына

әти
        япь-яшь килеш
        Аллага ышанган
аллалардан үзе
        гелән алданса да
45тә
        әти
                15 яшьлек малай
авыл Советыннан
медаль
        кайткан тагып
15 яшьлек әти
таккан
шул медальдән
алла үзе имеш торган диләр багып

## III

15 яшьлек әти
            таккан шул медальне
малай чакта мин дә
            тагып йөргән идем
медальдәге
            мундир кигән алланың да
Алла түгеллеген күргән идем
Алла мундир кими
сугыш ачмый Алла
Алла
минем әти кебек
игелекле була

## КОРАБ

Шаулый диңгез, дулкыннары
Орына болытларга.
Кемнәр сынар, кемнәр җиңеп
Чыгар икән бу ярга?

Өмет шәме тотып, ярда
Торам дәһшәткә карап.
Заһир булыр кебек анда
Дәрдемәнд җибәргән кораб.

## ЧИНГАЧГУК

Бу җирләрнең алтын белән
Исәпләнгән бәясе...
Дала буйлап килә берәү.
Атсыз. Уксыз. Җәясез.

Кылганнар кыштырдавы да
Сагайтып куя аны.
Ерак түгел ишетелә
Бүреләр улаганы.

Яргаланган иреннәре
Дога пышылдый сыман...
Чү, әнә бөркет калыкты
Кыялар арасыннан.

Шул каракош урлады ич
Ыруның соңгы кызын.
Берүзе калды. Ә алда —
Юллар. Маяксыз. Озын...

...Тарих күмелгән зират бу.
Изге җир! Юк бәясе!
Дала буйлап килә берәү.
Атсыз. Уксыз. Җәясез.

## МӘҖҮСИ УЙ

Һәр хатынның килә
Ана буласы —
Бала хакына
Бер сулыгасы.

Һәр ирнең килә
Батыр буласы —
Ил хәтеренә
Атын уясы.

Һәр җырның килә
Гимн буласы —
Ил йөрәгенә
Сайрап кунасы.

Һәр уйның килә
Яхшы буласы —
Мәҗүси булып
Кабат туасы.

Һәр җанның килә
Изге буласы...

## ЮГЫЙСӘ...

*Чиләбе хатирәсе*

Яннарыңнан инде ничәнче кат
Көяз кызлар узды көлешеп.
Синең исә шаулы кала буйлап
Кунакханә эзләп йөрешең.

Төн шикелле шыксыз уйларыңны
Син телисең һаман куарга.
Кая барсын уйлар?
Аларга да
Кунакханә кирәк кунарга.

Төн шикелле шыксыз уйларыңны
Кемнәр танып өйдәш итәр соң?
Син бу җиргә кунак булып килдең,
Сукбай булып, ахры, китәрсең.

Гаҗәпләнмә — ханә хуҗалары
Сиңа бронь бездә юк, дисә.
Төн күк ямьсез уйларыңны, әнә,
Таратырга теләп җил исә.

...Бу калада син бит кунак кына,
Кунак кына идең югыйсә.

## БЕРАЗ ТОЛСТОЙЧАРАК

Дошманыңа җылы бир син,
Ятса әгәр күшегеп —
Кешенең кеше булуын
Хуп күрә бу кешелек.

Дошманыңа «дошман» диеп
Әйтә күрмә ялгыш та.
Кичер аны — баш тартмаса
Гадел бәйге, алыштан.

Һәммәсен ек! — Чын көрәшнең
Асылына төшенеп, —
Кешенең кеше булуын
Хуп күрә бу кешелек.

## Ә ШУЛАЙ ДА...

Кануннар үзгәрәк монда —
Юк сөлгеләр, юк келәм.
Көч-куәт тә исәпләнми
Бәдән ныклыгы белән.

Рухиятең саулыгы да
Керми исәпкә-санга...
Кыйныйлар — йоласы бүтән,
Кыйныйлар — егылсаң да.

Үзгәрәк монда кануннар,
Үзгәрәк монда алыш...
Билгә сөлге бәйләп менә
Иртәгә китеп барыш...

## КЕМ АҢЛАР?..

Давыл узган — имән ауган,
Ятим калган туйралар.
Кунып сайрар талы сынган —
Былбыл хәлен кем аңлар?

Яулар узган — илләр тузган,
Канга буялган таңнар.
Очар канатлары сынган
Шагыйрь хәлен кем аңлар?..

## АРХИМЕДКА ЭНДӘШҮ

Җирнең ярасына түзә алмый,
Кан-яшь тамар кебек күкләрдән.
Таянырга нокта бир син миңа —
Бар кайгысын үзем күтәрәм!

## КҮЛӘГӘЛӘР

Күлгә төшкән болытларга
Сүз кушсам, дәшсәм әгәр,
Алар телгә килә шунда:
— Без бары күләгәләр.

...Заманга иш кыланганнар
Һәрчак дәү күренәләр.
Күренәләр...
Ә үзләре
Бары тик күләгәләр.

## АВЫЛДАШ ИМӘНГӘ МӘРСИЯ

Ул ышана иде әле
Шаулап, күкрәп үсәсенә —
Яшен теле елан булып
Уралмаса кәүсәсенә.

Яшен теле елан булып
Уралды шул билләренә...
Ныклык бир, җирем, имән күк
Мәгърур, асыл ирләреңә.

Мәрхәмәтле язмыш теләп —
Күңелләр болай да китек:
Азмы яшьтәшне — имәндәй! —
Яшибез бүген яд итеп!

## МЕТАМОРФОЗА

Олы Кайгы,
күз яшенә әверелеп,
боз-кургашын булып тама.

Олы Шатлык,
күз яшенә әверелеп,
ләйсән яңгыр булып ява.

Олы Сөю,
күз яшенә әверелеп,
гөл-чәчәкләр булып тама.

Олы Сагыш,
күз яшенә әверелеп,
алтын яфрак булып ява.

Матурлык җырлары, ахры,
күз яшьләреннән ярала.

## О' ГЕНРИ

Фани дөньялыкта рәнҗетелгән җаны
Сопи* кебек күшеккәндер, туңган.

Бөекләрен барлау өчен бу Тарихка
Әйтерсең лә зиндан кирәк булган.

Әйтерсең лә кызык өчен, юри генә
Төшергән ул капкын-кабалага.
Авыр уйдан изрәп черем иткән чакта,
Тәне буйлап чапкан кандалалар.

Ә бермәлне һәммәсе дә онытыла,
Тынгы бирми бөек максат кына.
Вакыт хөкем иткән Вөҗдан әсире син,
Котылырмын димә ансат кына.

Фани дөньялыкта рәнҗетелгән җаны
Сопи кебек күшеккәндер, туңган.
Бөекләрен раслау өчен заманнарга
Катыйльләр дә гүя кирәк булган.

* Сопи — «Фиргавен һәм хорал» әсәрендәге персонаж.

# МИГЕЛЬ ЭРНАНДЕСКА, КӨТҮЧЕГӘ ҺӘМ ШАГЫЙРЬГӘ

Мигель диеп аталсам да,
мин балчык, мин туфрак.
*М. Эрнандес*

Болыныңнан кем аерды,
Кем каерды канатың?..
Тиран мушкасында бүген
Хөрлекнең тулпар аты.

«Кәҗә көтүчесенә дә
Кирәк булган, имеш, дан...»
Яраладыр шагыйрь җаны
Туган җир туфрагыннан.

Ватаның зинданда ауный,
Чиркәүләр яза деннән.
Яраладыр шагыйрь җаны
Халык нәфрәтеннән.

Илеңдә — инквизиция.
Вакыт — матадор сыман.
Яраладыр шагыйрь җаны
Халык кайгысыннан.

...Көтүеңнән кем аерды,
Кем каерды канатың?
Тиран мушкасында Шагыйрь —
Хөрлекнең тулпар аты.

## ТУКТАЛЫШЛАР

Тукталышлар арты тукталышлар...
Казанымда азмы тукталыш бар!
Декабристлар, Тукай һәм Ямашлар...
Һәркайсы да безгә таныш алар.

Мин Казаным буйлап сәфәр кылам,
Саумы, тарихларга яшьтәш калам.
Тукай мәйданында утырам да
Ирек мәйданында төшеп калам.

Тукай һәйкәленә башым иям.
Аннан җәяү атлыйм Горький буйлап.
Җәяү атлыйм...
Туктап,
Һәр халыкның
Баш иярдәй кыз-улларын уйлап.

Әйтерсең лә беренче кат күрәм —
Сокланыплар туймыйм Казаныма.
Тагын ары китәм... Бара торгач,
Килеп чыгам... Чехов базарына.

Базар кайный. Базар сату итә.
Базар кебек кайный ми, уйларым.
Әнә ике агай сатулаша —
Әйтерсең лә Чехов геройлары.

Тукталышлар арты тукталышлар...
Казанымда азмы тукталыш бар!
Лев Толстой, Сәйдәш һәм Такташлар...
Һәркайсы да җангаятыш алар.

Әмма Чехов никтер уйландырды.
Монсы никтер башка сыймый һич тә.
Чехов базарында басып торам...
Һәм баш иям Антон Павловичка.

# АЭРОПОРТ

*Ркаилгә*

Төн. Аэропорт. Хушлашам.
Мөһим түгел — кем белән.
Төпченмәгез, гайбәтчеләр —
Кемлеген үзем беләм.

Төпченмәгез! Болытларга
Орыначак ул бүген.
Җанының ксерокопиясе —
Казанның уйчан күге.

Төпченмәгез!
Чит-ят аңа
Дәрәҗә, карьера, дан.
Ул гарык булган — борча күк
Борчыган «дусларыннан».

Гарык булган — сәлам биреп
Урамдагы һәр эткә.
...Орынасы килә аның
Йолдызлы чиксезлеккә.

Ул үзе аэропорт бүген,
Җанында гүли мотор.
Күккә текәлгән күзләре —
Гүя иллюминатор.

...Төн. Аэропорт. Хушлашам.
Ә бәлки, бәхилләшәм...
Салкын неон шәүләсенә
Бакый йолдызлар дәшә.

# МУНЧАДА

Бу җирдә фәрештәнең дә
Кер кунадыр тәненә...
Мәһабәт Давыт күк ирләр
Ләүкәгә күтәрелә.

Иң изге сүз-теләкләре —
Мунча себеркесенә.
Әйтерсең лә җаннарын да
Пешеклиләр эсседә.

Ләүкәдә — карт урманчы да,
Урман кисүче ир дә.
Каен кызларына гашыйк
Пеләш башлы шагыйрь дә.

Чабыналар. Яфрак чәчри.
Ләүкәдә — шау. Пар. Томан.
Яшел яфраклар — кыз килеш
Сулган сылулар сыман.

Чабыналар. Сагыш чәчри,
Каргыш, нәфрәт, кинә...
Мәһабәт Давыт күк ирләр
Ләүкәдән төшеп килә.

## МИН ДӘ...

Урам буйлап барган чакта очратсаң
Юл аркылы чыгып барган кырмысканы,
Таптый күрмә —
(мин дә — нәни)
Таптый күрмә,
Үз-үзеңне саклагандай сакла аны.

Урман буйлап атлаганда очратсаң
Оясыннан егылып төшкән кош баласын,
Күрмәмешкә салышма син —
(мин дә — кошчык)
Кире кайтар әнкәсенә күз карасын.

Диңгезләрне кичкән чакта ишетелсә
Дельфиннарның үзәк өзгеч SOS авазы,
Ишетмәскә җай эзләмә —
(мин дә — дельфин)
Үзеңә үк кире кайтыр игелекнең
Кайтавазы.

Еллар аша барган чакта очратсаң
Югалтулар чәрдәкләгән язмышларны —
Читләп узма —
(мин дә — яра)
Табиб бул син,
Сыгып чыгар җаннан кайгы-сагышларны.

# ХӨКЕМ

*Мәшһүр үзбәк шагыйре Мәшрәбне уйлап*

Мәйдан. Базар. Ыгы-зыгы:
— Кемне? Кайчан? Нигә?
Әй, сез, казый-хөкемдарлар,
Басыгыз! Суд килә!

Хөкем карары хакында
Нинди фикердә сез?
Гаепләнүче алдында
Юкмы гаебегез?

Бу «гөнаһлы» ил картының
Гаебе соң нидә?

...Җәллад-палачлары өчен
Тәүбә итә-итә,
Чорлар җавап бирә
(Шулай туры килә):

— Шагыйрьлектә гаепләнә —
Д
а
р
г
а

а
с
а
р
г
а
!

* * *

Дөрес кенә яшәп булса икән,
Дөрес кенә — башны иеп кенә,
Һәр ишәккә сәлам биреп кенә,
Һәр ишәкне «тулпар» диеп кенә...

Дөрес кенә яшәп булса икән —
Хаталарым баса бугазыма.
Хаталанам — димәк, дөрес яшим,
Хатамда да, димәк, казыналар.

## АЛДАКЧЫ

Ул алдаша белми иде.

Алдашмаска өйрәнде ул
үлән-агачлардан,
киек җәнлекләрдән,
ел фасылларыннан,
тугры дусты Актырнактан,
бабасыннан...

Алдашмаска өйрәнде ул
яраткан китапларыннан,
кыйссалардан,
якты әкиятләрдән,
чал Кояштан...

Ахры, мәҗүси иде ул —
риясыз мәҗүси иде.

...Ә кешеләр ышанмады аңа —
һәр сүзеннән ялган эзләделәр,
һәм үзен дә сукмадылар санга.

Шәрран ачык гаҗиз җаны,
имгәтелгән нәни коштай,
әй талпынды,
әй талпынды...

...Шулчакерактан-ерактан —
кыйбласыз тарафтан
тонык кына аваз килде —
гүя үз өне иде ул,
гүя коткаручы иде:
«Бу — дөнья бу, тинтәк,

Җайлаша белергә кирәк,
җайлаша белергә кирәк!»

Ул алдаша белми иде.
Хәзер ул алдакчы инде.

...Хәзер инде кешеләр дә,
ахры, чынлап ышандылар аңа —
һәр сүзеннән хаклык таба алар,
һәм үзен дә саный алар санга...

## КУМИРЛАР ШӘҺӘРЕ

Табынучылар юк монда —
һәркем идол, асылда...
«Йолдыз»лар чират торалар
Космопорт кассасында.

## БАТЫРЛЫК

Котлау ява...
Касәләрнең
Теле ачылган мәле.
Пенсиягә озаталар
Бәләкәй бер түрәне.

Шәраб исе... Дәү түрәләр...
Дус-ишләр... Алар кемнәр?
Кеше җырын шыңшый-шыңшый
Яшәлгән ич гомерләр.

Ник моңарчы эндәшмәгән,
Әллә булмаганмы җай?
Шул мәҗлестә тәүге кат ул
Турысын әйтте бугай.

* * *

Ут төрткәннәр җәйгә —
Урман яна,
Тротуарда яна чаганнар.
Яфраклар утлы кисәү гүя —
Кызуыннан пешә табаннар.

Куркусыннан дәррәү кошлар куба —
Эмигрант кошлар! —
Бәхилләшә,
Бәхилләшә җире-суы белән,
Туган җир һәм сагыш
Гел янәшә.

Урман яна Бөек Сагыш булып —
Табигатьнең мәркәз-каласы.
Бәгыремә утлы ук кадала —
Чаганнарның шәрә карашы.

## ЯРАЛЫ КӨЗ

Сагыш исе җанны сара,
Бәгырьне әчеттерә.
Озаткан торналарым да
Шом булып төшкә керә.

Кемнең кулы җитте икән,
Табигать, әйт тизрәк —
Каршы алган торналарым
Озатканнан кимрәк.

## УЙЧАН ЕЛЛАР

...Чал Инешкә илтә юлым,
Акбай озата бармыш.
Әнә таллар... Алар миңа
Әлифба кебек таныш.

Ә үзләре, күр, танымый,
Ятсынып кала карап.
Малай чакка кайтып барам,
Иңемдә — биштәр, кармак.

Менә — Инеш. Яр читендә
Шук бакалар кызына.
Кармак салам... Их, янымда
Булса күрше кызы да,

Көн буе маймыч чүпләп тә
Ялыкмас, талмас идем.
Алтын балыкның үзен дә
Каптырмый калмас идем.

Калкавыч гүя алдавыч —
Хет илерепләр ела...
Малай чактан кайтып киләм,
Иңемдә — уйчан еллар.

Табу һәм югалтулар.

* * *

Без — тулпарның дүрт тоягы —
Йоланы бозалмыйбыз:
Егылганны таптамыйбыз,
«Баскын» дип аталмыйбыз.

Җаныбызга баскын булып
Аяк басса берегез,
Без — тулпарның дагаланган
Дүрт тоягы. Белегез!

Кушаяклап тибәрбез бер,
Шундый итеп тибәрбез!..

Сөрлегә калса замана,
Безне генә тиргәгез...

## МӘКАЛЬНЕҢ ДӘВАМЫ

Шундый заман җирдә,
Шундый вакыт, димәк:
Нотык сөйләү түгел,
Кылган гамәл кыйммәт!

Җир саулыгы өчен,
Ил саулыгы өчен —
Син хакиме Җирнең...
Һәм хадиме, кешем!

Шушы юлда Илнең
Олтаны бул, кешем! —
Илдә олтан булу —
Солтан җаннар эше.

# ӘЙ БАЛАЧАК ХЫЯЛЛАРЫ

Әй балачак хыяллары —
Татлы көньяк җимеше.
Сине ашап койдык ич без
Сабыйлыкның сөт тешен.

Тәүге адым ясау белән
Омтылдык без ирлеккә.
Агач атны энеләргә
Нәзер итеп бирдек тә,

Хыял-атта җилдердек без
Замананың каршына.
Буйлар булса да бәләкәй,
Рухи үстек аршынлап.

Кем ул анда шәрран яра,
Уйдырма, дип, хыялың?
Йолкып өзәргә маташа
Хыял-атның ак ялын.

Кем оныткан Моабитның
Чөеп атылган чагын?
...Ак хыяллар саклады бит
Вөжданны — ирләр җанын.

Хыял-атта җилдердек без
Замананың каршына.
Сабантуй күк гүли дөнья
Тояклар тавышыннан.

## САБАН ТУЕ

Мәйдан уртасында — ирләр —
Алып батыр уллары.
Көрәшче халыкныкы ул
Язгы сабан туйлары.

Бабайлардан калган йола
Бүген безне җилкетә...
Әнә мәйдан, тын да алмый,
Көрәш батырын көтә.

Йә, кем ул батыр көрәшче?
Ил йөзен акларлыкмы?
Туган җирен төрле залим
Затлардан сакларлыкмы?

Рухы ныкмы, түзәрлекме,
Әзерме зур алышка?
Ныклы дәвам булырмы ул
Халкым улы Алыпка?

Бу көрәштә беркемгә дә
Юк бернинди ташлама.
Татарның сабан туе да
Алыплардан башлана...

## ТЫҢЛАП КАРА

Ничәнче төн тынгы бирми,
Нинди моң бу? Кайдан килә?
Әбкәм сүзе: былбыл түгел,
Җил дә моңлы туган илдә.

Читкә китеп тыңлап кара:
Ишетелер сагыш кына.
Халкыңа бак! Карама син
Мәнсез затлар ялгышына.

Ни кылмас ул дальтониклар,
Зәңгәр моңнар — ни аларга?
Җирдә һәркем халкым диеп,
Тиеш ләса бер янарга.

Салкын кышта былбыл эзләп,
Туган җирен ташлаганнар
Язлар җиткәч уйлар әле,
Уйлар да һәм беркөн аңлар...

Аңлар алар җилләр моңын,
Аңлар алар шагыйрь җанын.
Җиргә кадәр иелеп тә
Сынмаганын горур талның
Аңлар алар.

...Ничәнче төн тынгы бирми,
Нинди моң бу? Кайдан килә?
Сәер хәлдер: әрнүләр дә
Шифа икән туган илдә.

# АРХЕОЛОГ

*Равил Фәхретдиновка*

...Сак кына орынды
Тарих ярасына —
Шәһәрләр калыкты
Балчык арасыннан.

Калыкты нигездән
Үксез каберташлар.
Сискәнешеп куйды
Кылыч кискән башлар.

Ә башлар киселә
Баш имәгән өчен...
...Телсез хәрабәләр —
Җиңелгәннәр үче.

## КӨЗГЕ БАКЧА. СУКМАК. АЛТЫН КЕЛӘМ

*Р-гә*

Көзге бакча. Сукмак. Алтын келәм.
Һәм мин йөрим шунда сине уйлап.
Юлларыбыз, баксаң, бер икән бит, —
Туу — Үлем маршруты буйлап.

Һәрбер юлның, яшьти, үз кануны,
Ә безнеке — нәкъ полигон кебек.
Сыналабыз... Кемнәрдәндер исә
Хөкемдарлар тора читтә көлеп.

Юк, тизлекләр үлчәнелми монда,
Үлчәнелми монда еллар саны.
...Унсигездә ауган яшьтәшләрнең
Кемгә күчкән икән нәсел каны?

Сыналабыз... Кылган гамәлләрнең
Зурлыгына карап ат алабыз.
Үткән, киләчәктән йә хуплаулы,
Йә үпкәләү тулы хат алабыз.

Ниләр генә кылынмый бу юлда:
Сөю, зина, низаг, хыянәтләр...
Шушы юлда безнең җиңүебез,
Шушы юлда тәмуг, кыямәт тә.

Көзге бакча. Сукмак. Алтын келәм.
Һәм мин йөрим, яшьти, сине уйлап.
Юлларыбыз фәкать үтсен иде
Көрәш — Җиңү маршруты буйлап.

## ЭЛЕГИЯ

Көзге урман буйлап атлыйм.
Сагыш — кая карама.
Яфраклар, йөрәктәй янып,
Өзелеп җанга тама.

Тама алар моңсу гына...
Һай, кыска ла бу Яшәү!
Әнә, тыңла: яфракларны
Мәңгелек үзенә дәшә.

## ПАРАДОКС

Шатлыктан үксегән җаннар
күбрәк кайгы-сагыш эчеп
гомер итәләр кебек.

Кайгыдан үксегән җаннар
күбрәк шатлык-сафа белән
Яшәп китәләр кебек.

## БАКЧАЧЫЛАР

Бакчачылар төбәге бу.

Бәхәс-гауга куптармыйлар
Шәхесләре тирәсендә.
Тыйнак кына яши алар
Хозурият тирмәсендә.

Тыйнак кына яши алар,
Гөл үстерә, җиләк-җимеш...
Ә кем Печән базарында
Бушлай гайбәт сата, имеш.

Бакчачылар яши монда.
Тупаслык ят телләренә.
Гөлләр ымын аңлый алар,
Сандугачлар телен белә.

Сабыр гына яши алар,
Көзләр җитсә, яфрак яга.
Өем-өем яфрак булып
Гомерләремени яна!

Бакчачылар төбәге бу.
Мал-байлыкта юк гамьнәре.
Нәсел агачын корткычтан
Саклау — бөтен гамәлләре.

## ӘКРЕН ГЕНӘ ЭРИ КАНАТЛАР

Ал битеңнән үбәм, сыйпыйм тагын,
И Кояшым, сагышларым син.
Ялгызлыктан туеп күккә ашкан
Сөйгән ярым син.

Тәкъдир шундый: без — кунаклар гына,
Син — мәңгегә монда каласы...
Икарлыктан уза алса икән,
Узса икән адәм баласы.

Мәңгелекнең магик кәккүкләре
Безгә бары гомер юраган.
Хәтта тарих кадәр үткәннәрем
Экзюпери кебек югалган.

Ал битеңнән үбәм. Ә син менә
Канат кагышларым санап бар.
Аста — упкын. Кая сыенасың? —
Әкрен генә эри канатлар...

## ХӘСӘН ТУФАНГА

Ашыкмагыз хөкем чыгарырга, —
Мин бит әле менә аягымда
Басып торам. Миңа куәт биреп,
Фидакярләр яши як-ягымда.

Фидакярләр — Тукайдашлар яши,
Саклап мине дошман укларыннан.
Сүрәнәйсә, дары өсти алар
Йөрәк җырым — атар тупларыма.

Ашыкмагыз хөкем чыгарырга,
Гадел хөкемдар — тик Вакыт үзе!
Ни ул Аңа синең тәнкыйтьләрең,
Инкяр итүләрең, юк-бар сүзең!

Гильотина башын чапканда да,
Салкын кышта бозда катканда да,
Аягүрә үлә белде татар,
Тираннардан көлә белде татар!

Ашыкмагыз хөкем чыгарырга, —
Мин бит әле менә аягымда
Басып торам. Куәт биреп миңа
Фидакярләр тора як-ягымда.

## ДЕКАБРЬ-79

Инешемнең туңган күңеле тулды,
Шатлыктанмы, әллә сагыштан?..
Ярлар тулып, көмеш яше ага, —
Яз чалымы — кышта!

— Бар табигать изрәп йоклаганда,
И инешем, җаныңмы сыза?..
— Бу — шагыйрьлек, кардәш,
Яну,
Яшәү
Кануннарсыз гына.

# ҺАМАН БЕР СОРАУ

Исә җилләр, кучә комлар,
Бетә эз.

*Дәрдемәнд*

Көннәрем ага,
Төннәрем ага, —
Һаман бер сорау:
— Сездән ни кала?

Һаман бер сорау:
— Кая табышың?.. —
Кичерәм гүя
Бабам язмышын, —

Ничә абынып,
Җанын канаткан;
Янә торырга
Куәт-көч тапкан.

Кол ыруыннан
Түгел бу дәвам!
Галиләр рухын
Саклый бу гавам!

Көннәрем ага,
Төннәрем ага...
Кан сауган җанда
Эзләр — өр-яңа.

## ЙӨЗҮ

*Равил Фәйзуллинга*

Ышанмасак та үзебез
Юк-бар имеш-мимешкә,
Алтын тарак эзләп кенә
Чумган идек инешкә...

— Йөзә беләсеңме? — диеп
Сорап тормады заман...
Бүген менә, колач салып,
Иделгә кереп барам.

Ярдан ерагайган саен
Хәвефлерәк, шомлырак.
Чигенү юк!
Хәзер инде
Кайсы ярга да ерак.

Йөзәм! Йөзәм! Юк, кирәкми
Нәтиҗәсе, азагы.
Күктән гүя котлау ява —
Акчарлаклар авазы.

Чыр-чу, гауга артта калды,
Колагымда — су шавы.
Йөзәм! Йөзәм!
Тынмасын тик
Дулкыннар алкышлавы.

## САУ БУЛ, КОЯШ, ТАҢГА ЧАКЛЫ

Сау бул, Кояш, таңга чаклы,
Сау-имин кайт әйләнеп,
Көн дә безне алкышласын
Гөл-нурларың бәйләме.

Бездә әле таң балкышы,
Без — нарасый балалар...
Җирдә кайчак кешеләр дә
Калкыр өчен баталар.

# ТАМЫР

Мең ел яшәр мәгърур имәннәрнең
бар ныклыгы —
үзәгендә,
кәүсәсендә кебек
безгә.

Алар әнә
безгә килеп җиткән...

Ерак тарих сыман
        тирән киткән
                корыч күк нык
                        тамырларсыз
бу имәннәр давылларны
кичә алыр иде микән?

# КАЗАН

Казан каласы — таш кала,
Моңлы, ямансу кала.
Кемнәргәдер яшәр урын,
Ә безгә ул — башкала.

Казан каласы — таш кала,
Сөембикәле кала.
Кыйшайса да, авар, димә —
Алыплар саклап бара.

Казан каласы — таш кала,
Яшен оныткан кала.
Һәр ташы — энҗе бөртеге,
Һәр диварында — яра.

Казан каласы — таш кала,
Җимерелмәс, нык кала,
Таңга таба китеп бара.
...Кемнәр озатып кала?..

## МИН — ЯЗНЫКЫ

Бөтен рухым белән язныкы мин,
Хәтта җәйгә үтеп барганда,
Күңелемнең кара кайгысын да,
Сагышын да мандым язларга.

Яз турында тәүге җырымны да
Яздым манып яшел карага.

Тик кайчакта шомлы кара уклар
Җырларыма килеп кадала.

Бөреләрнең хәл-язмышы ничек,
Ачылмады микән телләре?
Ә күңелдә инде юеш җиргә
Саргаешып төшәр көннәре.

И яшел моң!
Һәрбер яфрак җырлый,
Кайсы таныш, кайсы чит аның...
Бөтен рухым белән язныкы мин,
Яз төсендә хәтта моңнарым.

## ҮЛЧӘҮ

Шагыйрь бул син, әйдә,
Шагыйрь бул син,
Йолдызларны үрелеп үпсәнә, —
Ил-йортыңда синең олылыгың
Рухи байлык белән үлчәнә.

Шагыйрь бул син, әйдә,
Шагыйрь бул син,
Гөл-чәчәктән сүзләр үрсәнә, —
Бу тарихта халкың бөеклеге
Рухи байлык белән үлчәнә.

# III БҮЛЕК





## ТӨНГЕ ӘВЕРЕЛЕШ

Икәү яккан учакмыни —
Чатыр-чотыр төн яна.
«Кемнәр ярын кемнәр сөймәс
Бу вафасыз дөньяда», —
Дип җырлаган җилле чаклар
Бар иде бит безнең дә...

Бүген менә кискәдә күк
Ята башым тезеңдә.

Керфекләрең йомылганда
Дертләп куям, сискәнеп.
Сулышыңнан ишетелә
Җилбәзәк җил искәне.

Күкрәкләрең гүя гөрзи,
Кулың гүя айбалта.
Шүрәледәй шәрә шәүләң
Йөри дивар буйлата.

Таш диварга сеңә бара,
Сыза бара сурәтең.
Икәү яккан учак кебек
Шыпырт кына сүнә төн.

Карашыңда — таң салкыны,
Өши барам, өшәнә...
Һәрчак шулай: шом баса, әй,
Яшьлек искә төшә дә.

Җилле чаклар, тиле чаклар
Бар иде бит безнең дә.
Бүген менә кискәдә күк
Ята башым тезеңдә...

## СЫНЧЫБАГАР

Үз бәясен ул бик яхшы белә,
Шуңа да ул алиһә күк тыныч.
Сокланырга хәтта хәтәр аңа,
Сокланырга хәтта куркыныч.

Карашларың белән орынсаң да,
Әверелер кебек таш сынга ул.
Юк, юк, сынчы карашыннан түгел —
Гарип дөньялыктан ятсына ул.

Юк, юк, сынчы карашыннан түгел —
Үз-үзеннән яшерә ул тәнен.
Мәңгелеккә күчәчәк бу мизгел! —
Гүзәллеккә сабырлык бир, Тәңрем.

Сабырлык бир, Тәңрем, бу мизгелгә —
Фәрештәңә сынчың куя канат.
Иреннәрең белән орынсаң да,
Алиһәгә әйләнер сын кабат.

Сынчы китәр...
Остаханәсендә
Хуҗа булып калыр бер үкенеч:
Яратырга хәтта хәтәр аны,
Яратырга хәтта куркыныч.

## МӘҢГЕЛЕК ҮКЕНЕЧ

Күпме ярлар үкенечкә калды,
Уйлыйлардыр инде — пешмәгән.
Сискәнепләр кайчак уянасың
Аягүрә күргән төшләрдән.

Күпме ярлар сөелмичә калды,
Калды, әйе, үбелмичә дә.
Юкса күктән йолдыз өзеп бирер
Чаклар иде — үрелмичә дә.

Күпме ярлар безгә болдырлардан,
Балконнардан калды кул изәп.
Без хан булалмадык.
Кай ханнарга
Булды икән алар кәнизәк?

Күпме ярлар перроннарда калды,
Ә без, имеш, дөнья куганбыз.
Бер кайтырбыз, дидек.
Ә үзебез
Кайтмаска дип киткән булганбыз.

Күпме ярлар калды ятлар белән,
Күпме ярлар калды... сазап та.
Ә үз ярың гел ят була барды,
Әверелде яшәү газапка.

Күпме ярлар йөрәкләрдә калды,
Исемнәрен куштык җырларга.
Бездән соң да, бәлки, яшәр алар
Без юксынып көткән чорларда.

Күпме ярлар сөелмичә калды,
Калды, әйе, үбелмичә дә.
Юкса күктән йолдыз өзеп бирер
Чаклар иде —
Үрелмичә дә.

## ЯЛГЫЗЛЫК ИСЕМЛЕ КЫЗ

Эзләмәгез мине бүген,
Мин юк бүген дөньягызда.
Күңелнең сыңар ачкычы
Ялгызлык исемле кызда.

Ул кыз мине тоткын итте,
Сарылды да иңнәремә.
Тәмәкемнең күк төтене
Кочып алды билләреннән.

Ул кыз мине гашыйк итте,
Таратты да толымнарын,
Пышылдады... Ишеттем мин
Күзләр күзгә орынганын.

Тезләр тезгә орынганын
Ишеттем мин, ишеттем мин.
Сыңар ачкычын күңелнең
Сорарга, аһ, кичектем мин,
Кичектем мин.

Ялгызлык атлы кыз белән
Калырмын күк мин мәңгегә.
Ул кыз миңа шундый якын —
Сеңә барам пакь тәненә.

Ул кыз миңа шундый якын —
Гүя хатын — мин ялгызга.
Эзләмәгез мине бүген —
Мин юк бүген дөньягызда.

# 9

## БӘЛА

Бәла, әйе, аяк астында ул,
Олтыракка йөри тагылып.
Һушсыз калдым менә —
Бер сылуның
Бозлы карашына абынып.

## ӘЙТЕШ

— Нинди якты күзләр!
Нинди матур тезләр!

— Егет булсаң —
Тезлән!

— Иреннәрең — кершән,
Җиләк булып пешкән.

— Җебек булсаң —
Өзмә!

# АҢЛАШУ

Синнән, ахры, китә алмамдыр.

Теләмим —
ут алмаган тәрәзәңнең
өметсез карашын текәп
озатып калуларын.

Теләмим —
шәүләм белән хыянәтнең
янәшә баруларын.

Теләмим —
миңа гашыйк яшьлегеңнең
үкенечле
яшь булып тамуларын.

Теләмим —
бер нәни нарасый бәгырьнең
берекмәвен бәгъребезгә.

Сөю-әсирлектән
Котылу юк безгә!

## КУНАК АШЫ

Кунак ашы кара-каршы була —
Күп чөмердең кунак ашларын.
Ят ярларның итәк асларыннан
Тәгәрәпләр чыкты башларың.

Әйләнбәйлән бәйрәм итмәк идең
Аулак бүлмәләрдә, йортларда.
Ятлар белән туры килде ләкин
Ялгызлыкны кочып йокларга.

Шампан булып яшең күбекләнде
Бәллүр күкрәгендә ятларның.
Акбүз белән капламакчы булдың
Хыянәтнең кара ятагын.

Акбүз белән капламакчы булдың
Ят ярларның оят, гаурәтен.
Намуслата сатты алар җанын,
Намуслата сатты дәүләтен.

Оят качкан җанга иблис хуҗа,
Иблис хуҗа тәкъдир, язмышка.
Һәрбер хатаң дөрес була барды,
Әверелде дөрес — ялгышка.

Кунак ашы, хәер, кара-каршы,
Кунак ашы — һәрбер капканың...
Шампан булып, аһ, эреде яшең
Бәллүр күкрәгендә ятларның.

## КҮҢЕЛНЕҢ БЕР КӨНЕ

Гаҗиз булып ташкаланың
Тынчу, таш карашыннан,
Йөрим кайчак урамнарда,
Адашкан мәче сыман.

Килеп чыгам вокзалларга,
Нинди уй белән — белмим.
Һәр юлаучыга кул изәп,
Хәерле сәфәр телим.

Килеп чыгам мәйданнарга,
Мәйданнарда — шау, халык.
Хөрлекнең яшел чыраен
Ерактан киләм танып.

Килеп керәм кибетләргә,
Чиратка басам. Көтәм.
Без бәхет көткән чиратлар
Үткән шул инде күптән.

Килеп керәм фатирыңа,
Каршылый мине ишек.
Ишектә — язу: «Чит-ятка
Керү тыела!»—
Ничек?!

Килеп керсәм күңелеңә,
Каршылар кебек ятлар.
«Чит-ятлар керү тыела!»—
Бу — синнән соңгы ядкәр.

«Чит-ятлар керү тыела!»
Утырган күңел, тынган.
Чыгып киләм подъездыңнан,
Адашкан мәче сыман.

Ары китәм.
Аэропортка.
Нинди уй белән — белмим.
Канатлылар кавеменә
Хәерле очыш телим.

* * *

Мин әкият кебек дөрес идем,
Дөрес иде яшәү, гамәлем.
Бер гүзәлнең матур тезләренә
Төртелде дә сынды каләмем.

Мин бу чынлык кебек ялган идем,
Ялган идем үзем, сүзләрем.
Ә мин хәзер әкият тә түгел,
Хикәят тә түгел —
Үзгәрдем.

## КАРТ ОТЕЛЛО

Ул ireккә чыккан бүген генә,
Кичә генә тоткын булган ул.
Яшьлегендә — ят ятакка яткан
Үз хатынын тотып буган ул.

Ул иреккә чыккан бүген генә,
Бүген генә килгән мунчага.
Минем гөнаһларны юарга, ди,
Җитмәс хәтта бер пот мунчалаң.

Парлы ләүкә аңа тәхет бүген —
Тәхетләрең торсын бер читтә.
Хатын-кызлар белән сак кылан, ди,
Хатын-кыздан саклан ничек тә.

Хатын-кызга суксаң, беттем, диген,
Зинданда да көн юк андыйга.
«Пахан»нардан серең яшермә дә —
Кемлегеңне шундук таныйлар.

Кешегә дә чутламыйлар анда,
Хупламыйлар безнең ишене.
Хатын кыйнап, таш капчыкта яту,
Әйт, энекәш, ирләр эшеме?!

Беләсеңме, ничә ел утырдым
Хатын хыянәте өчен мин?
Дөньясы да зиндан кебек аның —
Мин зинданда шуңа төшендем.

Зинданы да зина кебек аның —
Дөньяда мин шуны аңладым.
Һәрбер хыянәтнең — хыянәткә,
Кыяматкә илтә барганын.

Һәр хыянәт кыяматкә илтә, —
Хаксызмы мин, йә, әйт, хаклымы?..
...Ышкый-ышкый юды карт Отелло
Тәнендәге шәрә хатынны.

Ул ирекка чыккан бүген генә,
Бүген генә килгән мунчага...
Минем гөнаһларны юарга, ди,
Җитмәс хәтта бер пот мунчалаң.

## ИДИЛЛИЯ. КҮКЕЛЕ СӘГАТЬ

Тын бүлмәмә төн иңде дә
син килдең
һәм сагаеп ятагыма иелдең
сагайма
сине искәреп
бары күке кычкыра
һәм почмакта мыгырдана
суыткыч кына

## ЯЛГЫЗЛЫК

Бүлмәмә килеп кердең дә
Имәнеп китте бүлмәм.
«Ул килде» дип, пышын гына
Сукранып алды күгән.

«Ул килде» дип, серле генә
Кеткелдәп куйды ишек.
«Ул килде» дип, баш очымда
Тирбәлде үксез бишек.

Килгәнсең икән — уз, әйдә,
Йөрәгемдә юк бигем.
Сагайма да — бишегемдә
Хәтер ул ауный минем.

Тартынма, чишен, кил миңа,
Юк уемда азгынлык.
Кем башыннан узмаган ул, —
Түремнән уз... ялгызлык.

## ЯРАТЫРГА ТЕЛИМ

*Тәкълид*

Бу дөньяда, бу гөнаһлы Җирдә,
Йә, әйтегез, кем мин?
Әйдә, мине яратмасын беркем —
Яратырга телим.

Кочагыңны аччы, и Сылукай,
Бер юаныйм, эрим.
Син дә әллә яратмыйсың?! —
Ә мин
Яратырга телим.

Синең өчен, бәлки, чыклы иртә,
Бәлки, шыксыз төн мин.
Күкләреңдә тик йолдызлар янсын —
Яратырга телим.

Бу дөньяда, бу гөнаһлы җирдә
Ник яшәлгән — белмим.
Яратырга телим.

## ПЕЧӘН ӨСТЕ

Болында
җиде карт
ун карчык
    печәнгә төшкәннәр
    болынга

дүрт кәҗә
биш сарык
өч бәрән
    йөриләр чемченеп
    болында

болында
покослар
покослар
    ястык күк покослар
    болында

җиде карт
ун карчык
утырып
ял итә
покослар өстендә

кайчандыр
тәгәри-тәгәри
кочышкан
үбешкән
сөешкән
покослар өстендә

юкса шул ук Кояш
чалгылар йөзендә
юкса шул ук Кояш
картлар күзендә

* * *

Ник чыкмадың каршысына
Гөлләр тотып син аның?
Белеп, күреп тордың ласа
Яшьлегеңнең узганын.

Ак күлмәктән, яланаяк —
Әллә адашкан, димме,
Асфальт тротуар буйлап
Сагаеп килә иде.

Әллә фатирыңны шулай
Эзләде ул имәнеп,
Табалмады...

Урам-чатлар әйтерсең лә
Язмышлар күк төйнәлеп
Ята иде...

Кешеләр дә сәерсенеп,
Читсетеп бакты аңа.
Ә ул — горур, китеп барды
Аэропортка таба.

Ник килмәдең озатырга
Гөлләр тотып син аны?
Белеп, күреп тордың ласа
Яшьлегеңнең узганын.

## СӨЮ АТЛЫ ЧАПТАРГА АЛДАН ЯЗЫЛГАН МӘРСИЯ

Дөнья бит — синең дә
Гөнаһлар булгандыр.
Гөнаһлы бу дөнья
Сиңа да тугандыр.

Булгандыр синең дә
Чыгымчы чакларың.
Сөю атлы чая
Ак яллы чаптарың

Аранда күптәннән,
Күптәннән — яралы.
Камытлы кайгыдан
Каралды яллары.

Канатлы иде ул —
Кистеләр канатын.
Яралы җаныннан
Кан акты... кан акты...

Аннары ыңгырчак
Салдылар биленә.
Чыбыркы чыжлады
Сыртында: «Тибенмә».

Колынлы иде ул —
Чалдылар колынын.
Төшендә күрә тик
Колынлы болынын.

Төшендә күрә тик
Ак яллы чакларын.
Җанара, тәнара
Бәйгедә чапканын.

Бәхетле иде ул —
Тапты да... югалтты...
Көнчеләр җанына
Хөсетле ук атты.

Ирекле иде ул —
Ә хәзер — йөгәнле...
Бигайбә — ярылса
Йөгәнсез йөрәге.
Бигайбә...

## ЭМАНСИПАЦИЯ

Табигатьтә һәрни камил,
Табигатьтә юк хата.
Хатын-кызда сер калмаса,
Җирдә тол-ятим арта.

# ОЛЫГАЮ

Кызлар биегәнен хәзер
Читтән генә багабыз.
Олыгаеп барабыз шул,
Олыгаеп барабыз.

Өебездә чыр-чу килеп
Уйный бала-чагабыз.
Олыгаеп барабыз шул,
Олыгаеп барабыз.

Әрнеп-әрнеп тирәнәя
Сөю дигән ярабыз...
Олыгаеп барабыз шул,
Олыгаеп барабыз.

...Якыная бара һаман
Туфрак белән арабыз.

* * *

Әллә сөеп горур булдык,
Башларны имәдек без.
Өрмәгән урындыкларга
Утыртмам, димәдек без.

Тормыш кебек кырыс идек,
Әйттеләр: «Таш бәгырьле...»
Кадер эзләп киткән ярлар
Булды микән кадерле?

Бәхетләре тулы микән,
Уңдылар микән ирдән?
Яшәмиме икән алар
Яшьлекне каргап-тиргәп?

Сөйдек. Нәфрәтләндек.
Ләкин
Башларны имәдек шул.
Өрмәгән урындыкларга
Утыртмам, димәдек шул.

Бүген менә сулык-сулык
Үксетәбез бәгырьне.
Кадер эзләп килгән ярлар
Чынлап микән кадерле?!

# ЭЛЕГИЯ

Син җәйләрдә калдың...
Ә мин менә
Синсез генә китеп адаштым.
Һәрчак тугры юлдаш булды миңа
Бәхетсезлек атлы адашым.

Син җәйләрдә калдың...
Арабызда
Упкын булып инде көз ята.
Күңелләрең нигә бикле һаман,
Күңелләрең нигә йозакта?

Юк, шакымыйм ишек-тәрәзәңне,
Ачмасыңны беләм болай да.
Арабызда — упкын.
Ике ярда
Сак-Сок булып Сөю моңая.

Син җәйләрдә калдың.
Ник соң әле
Тәрәзәңне синең боз сарган?
Кем ул анда бозлы тәрәзәңә
Безнең сөю рәсмен ясаган?

Кемдер безне, бәлки, кызганадыр,
Кем телидер, бәлки, көләргә.
Мине көтеп күшеккәннәр гүя
Тәрәз төбеңдәге гөлләр дә.

Куеныма алып җылытсам да,
Эремәс күк бозлы карашың.
Тәүбә итү кирәк —
Үткән чакта
Сөю белән Нәфрәт арасын.

Ятим калган Сөю каршысында
Тәүбә итү кирәк безгә дә...
Тапканыңны җуя күрмә икән,
Ә җуйгансың икән —
Эзләмә.

* * *

Былбыллар читлектә елый,
Аранда елый атлар.
Күк-Тәңре аранында
Җилләр елый, болытлар...

Аранны ачар чара юк, —
Җанга эленгән келә.
Кочагымда син елыйсың...
Шунысы гаҗәп менә.

## ЯЛГЫЗ КАРТ

Узды гомер, сызды гомер,
Сызланып үтте еллар.
Тәгәрәпләр елар идең,
Яшь кипкән, булмый елап.

Бәхетле дә булалмадык,
Булмадык тәхетле дә.
Белмим, туган булганбыздыр
Кемнәрнең бәхетенә?

## СОЛЬ МАЖОР

Мин хәтерлим әле ул чакларны:
Тирәкле инеш буйларын,
Бакалар прелюдиясен,
Сандугачлар рапсодиясен,
Чикерткәләр кантатасын,
Яфраклар сонатасын,
Бәгыремнең ноктюрнын,
Мәхәббәтнең матәм маршын
...һәм шәрә күләгәңне.

## БЕЗ АДАШТЫК БУГАЙ...

*Ф.Д.*

Адаштык та өнсез калдык,
Өнсез калды төн, урман.
Бу төн, ахры, безне кабат
Кавыштырмаска туган.

Тыпырчына җанда —
Мәңге
Әйтелми калыр сүзләр.
Ябалдашлар арасыннан
Йолдызлар тора күзләп.

Керфегеңә кунган Ай да
Бармак яный күк безгә.
Төнге күбәләкләр генә
Оча үз күгебездә.

Көн күзеннән яшеренеп,
Каптык төн тозагына.
Ә мизгелләр кабатланмый,
Мизгелләр уза гына.

Ә гомерләр уза безнең
Тыелган бәхет эзләп.
Бәхетсез бәхетлеләр без,
Бәхетле бәхетсезләр.

Йөрибез төнге урманда
Ике җан — качкын кебек.
Артыбыздан пар күләгә
Шаркылдап кала көлеп.

## Ә МИН СИНЕ ЯРАТМАСКА БУЛДЫМ

...Ә мин сине яратмаска булдым,
Яңартмаска булдым үткәнне.
Мәңге әрнер яраң булып калсын
Күзләреңнән сөеп үпкәнем.

Мәңге әрнер яраң булып калсын
Иренемә тамган яшьләрең.
Син үзеңчә дөрес сөеп кара,
Мин үземчә дөрес яшәрмен.

Мине көтеп тик ялгыша күрмә,
Йөрәгеңнән ыргыт чыгарып.
Ходай сиңа сабырлыклар бирсен
Сак-Сок сагышына чыдарлык.

Мин дә сине сагынмаска булдым,
Табынмаска булдым мәңгегә...
Сөюгә мин ясин чыктым бүген,
Кем озата барыр кабергә?

Озатучы, беләм, табылачак,
Кемябышыр, беләм, көрәккә.
Тик мин сине борчымаска булдым,
Мин Сөюне күмдем йөрәккә.

## ТАЛАК

Әгәр сөю сараена
Керсә угры-карак,
Хуҗа шундук сөрән салган:
— Талак.

Ә без кычкыра алмыйбыз,
Китсәләр дә талап.

Ә без кычкыра алмыйбыз,
Тик торабыз карап.

Сөюебез — үзебез күк,
Сараебыз — бардак.

Ә бит кемдер миргә беркөн
Кычкырачак кабат...

Тик аңарчы коллыгыңнан
Качу кирәк:
— Талак!..

# УРАМ КЫЗЫ

*Антишигырь*

Урам кызы узды төнге урам буйлап,
Нидер уйлап узды кебек, нидер уйлап.
Кайнар кочакларда ул бүген дә туңар,
Тагын капшар тәнен йөнтәс куллар.

Үрмәкүчтәй үрмәләр кул иңнәреннән,
Пәрәвезен үрер күкрәк, билләренә.
Мыгырданып куяр ятак: «Бу Ходайның
Биргәненә шөкер, биргәненә».

Мыгырданып куяр күлмәк төймәләре:
«Син сабыр ит бераз, миңа тимә әле,
Ашыгасың кая, төштең мәллә Айдан,
Саграк кылан, өзәсең бит, хайван».

Мыгырданып куяр күкрәкчәсе аннан:
«Ни эзлисең шунда кармаланып һаман,
Оҗмах бакчасының капка-ишекләрен
Шулай ачалармы, ишәк тәре».
.................................................
Оҗмах ишекләре тора ачылырга,
Ә кызыйга кирәк бик тә ашыгырга, —
Көтеп калды аны өйдә нәни улы,
Сагыз көтеп калды... мәэюс булып.

Урам кызы узды төнге урам буйлап,
Нидер уйлап узды, нидер уйлап...

# СӘРХУШ ХАТЫН

*Антишигырь*

...Кем чәйнәлә анда,
Мирдән калган, имеш.
Әй, син, эт сыңары,
Миңа күпме тиеш?

Кем лыгырдый анда,
Кәгә дә, дип, тая.
Әй, син, алкаш, давай,
Минем өлеш кая?

Аңламыйсыз хәлне,
Әйдә, җырлыйк әле:
«Ни уңмадым ирдән,
Ни уңмадым мирдән».

Ә син, мокыт күсәк,
Хет бер сугып күрсәт.
Синең кебек иргә
Хәрәм безнең чир дә.

Ә син, алаканат,
Нәрсә каттың карап?
Йә син министр бул,
Йә бул ата карак.

Ә син, зәңгәр, бүген
Нигә кызыл түгел?
Ә син мине, ишәк,
Яратмыйсың нишләп?

Нигә эчәм, имеш,
Сусаганга эчәм!
Чәркәң тулы торсын,
Буш булса да кесәң.

Аңламыйсыз хәлне,
Әйдә җырлыйк әле:
«Ни уңмадым ирдән,
Ни уңмадым мирдән. Их...»

## 31 ДЕКАБРЬ-76

*Көндәлектән*

Күчәреннән ычкынды Җир
Һәм упкынга очты.
Уйга кадалды —
Мезазой
Сөңгесенең очы.

Сөрем каплады Кояшны,
Ут ялмады карны...
Ә бит үзе пышын гына:
«Сөймим», — диде бары.

## МИНЕ ШАГЫЙРЬ ИТКӘН КЫЗГА

Коймаларга акбур белән язып
Тутырдылар безнең исемне.
Сабый идек... Канат очларыбыз
Сабый чакта ук шул киселде.

Сабый гына идек...
Ә аннары
Өстебезгә тормыш ишелде.
Ак кәгазьгә бүген каным белән
Язып куйдым синең исемне.

Исемеңне кабат яд иткәнгә
Үпкәләрсең, бәлки, каргарсың,
Тик барыбер син җырыма минем
Тугзак ана булып каласың.

* * *

Күзләреңнән серле мәгънә эзләп,
Күккә аштым. Бактым биектән.
— Фәрештәм, — дип, ничә дәштем сиңа,
Ә син күптән канатсыз икән.

Ә син күптән җирдә икәнсең лә,
Җирдә икән язың, күзләрең.
Хыялларым ята тыпырчынып...
...Ә мин сине күктән эзләдем.

## ЯЛВАРУ

Тезләнергә әзер мәлем алларыңа,
Агарырга телим кабат, агарырга.
Яшер мине сөю дигән араныңа.
Тезләнергә әзер мәлем алларыңа.

Агарырга телим кабат, агарырга,
Ак калырга кирәк безгә, ак калырга.
Ауныймчы бер сәгадәтнең ак карында.
Агарырга телим кабат, агарырга.

Яшер мине сөю дигән араныңа,
Мин teләмим яңабаштан таланырга,
Мин теләмим яңабаштан каралырга.
Яшер мине сөю дигән араныңа.

Ак калырга кирәк безгә, ак калырга...

# БЕЗ ЯРАТКАН ЯРЛАР

Төрле хәлләр булды безнең урамда да
безнең урамга да яуды кызыл карлар
безнең урамнан да узды алар узды
ятлар белән узды без яраткан ярлар

безнең урамга да туйлар керде туйлар
без яраткан ярлар узды урам буйлап
безнең тәрәзләргә бакмады да алар
гөрләвекләр булып акты кызыл карлар

безнең урамга да бәйрәм килер дидек
һәр сылуга туктап горур башны идек
башны ия-ия узды-китте яшьлек
әй син безнең яшьлек ник күзләрең яшьле

без яраткан ярлар әни булды күптән
безнең урамда да җәйләр димәк үткән
безнең урамга да кышлар киләсе бар
кызыл карлар гына яумас инде бүтән

без яр иткән ярлар шәрә калыр беркөн
һәм ак җәймә иңәр өстебезгә күктән

# ЭКСТАЗ

*Акрошигырь*

Лыкынганчы эчеп сөю шәрабын,
Әшкарә булды бугай ла бу башым.
Йолдызларга хөрмә дип үрелгәнмен,
Ләйлә Айга эндәшкәнмен: «Туташым,
Әллә син дә ут йоттыңмы минем күк,
Исәнгерәп ятам мин дә бушлыкта.
Ләзиз мизгел яшен булып яшьнидер,
Әман, туташ, сыена төш ышыкка.
Миңа сыен, сыена төш, тарсынма,
Әлмисактан килә ләса йоласы.
Җәннәт багларында гөл-чәчкә булыйк,
Ни чараң бар — барыбер коеласы.
Үкси-үкси үтеп бара үксез төн,
Ни чараң бар — барыбер боегасы...»

# ҖАН ЭРЕТКЕЧ ЛӘЙСӘН ЯВА

Качма син ышыкка,
аклыктан, пакьлектән —
үзеңнән качма син.

Әйдә, чыланмаган
җегең дә калмасын,
сылансын күлмәгең...
Җаным сихерләнеп
эресен,
эресен...

Гүзәллек кешегә
син булып күренсен.

* * *

Елмай, сеңлем —
Кояш булу
бик килешер сиңа.

Җырла, сеңлем —
Бәхет булу
бик килешер сиңа.

Җыла, сеңлем —
Сабый булу
бик килешер сиңа.

Ярат, сеңлем —
Әни булу
бик килешер сиңа...

## ТӨНГЕ ЭТЮД

Күл уртасында — Зөһрә кыз,
Ярымай гүя көймә.
Салмак кына ишә сылу,
Ямансу бер көй көйләп.

Ишетәм аның сагышын,
Ишетәм чорлар аша.

...Бер-берсенә күз кысышып,
Йолдызлар пышылдаша.

Көмеш балкыш чыңы күктә,
Җәй шавы — тирә-якта...
Төнге тынлык төнбоекны
Йокысыннан уята.

## БЕР ТӘЭССОРАТ

Кочагымда бөгәрләнеп
Төн йокыга талган.
Тузгыган толымнарына
Айның
Күз яшьләре тама.

Ә бишектә — нәни улым...
А, мәҗүси халәт!..
Вакыт кеткелди диварда —
Чылбырлы сәгать.

## МАНЗАРА

...Гашыйк парлар узып китте
Йолдызларга орынып.

Бабасының каберенә
Чәчкә куйды оныгы.

Орышлардан арып-талып,
Дөнья талды йокыга.

Йөкле хатын кереп китте
Бәби табу йортына.

## ДҮРТ МИЗГЕЛ

Кичкә авышты көннәр.
Көн шәүләсенә абынып
Егылыр тагын кемнәр?

Төнгә авышты кичләр.
Бәхетлеләр гыйшык уйнар,
Бәхетсезләр соң нишләр?

Таңга авышты төннәр.
Төннең сөю ятагында
Аунап калыр ал гөлләр.

Көнгә авышты таңнар.
Кояшка узган Зөһрә кыз
Тузгыган чәчен тарар...

## ӘЛЛӘ...

Әллә мин сиңа гашыйкмы,
Әллә син миңа гашыйк...
Икәү генә белгән җырны,
Йә, булмаса, башлыйк.

Әллә син телсез калгансың,
Әллә мин өнсез инде...
Икәү генә белгән серне
Күккә күмдем, тиле...

## ӘЙ, КЫЗЫЙ

Әй, кызый,
көн күкрәгенә капланып,
ник әле моңаясың?

Әй, кызый,
төн кочагына сыенып,
ник әле сагаясың?

Әй, кызый,
яшьлекнең кыл уртасында
ник әле саргаясың?

* * *

Тел очымда тора
Сиңа әйтер сүзем,
Әйтелмичә тора
Тыелган сүз кебек.

Күз яшьләрем тамган
Оялчан күкрәгең
Сөелүдән изрәп
Йомылган күз кебек.

## КӨЗГЕ ЭТЮД

Сынчыбагар сылу сыман
Шәрә калган һәр агач.
Ә бакчада — күз алдында
Бала таба алмагач.

Табигать тә гаурәтле,
Табигать тә ояла...
Күлмәген алышканда тик
Бераз хисләнеп ала.

## ХӘТЕРНЕҢ АК ДИВАРЫ

Хатирәләр хәтеремне
Алалар телеп-телеп.
Сагынган да кебек булам,
Сагынмаган да кебек.

Хәтернең ак диварында
Сурәтең тора көлеп.
Яраткан да кебек булам,
Яратмаган да кебек.

Сурәтеңне ак диварга
Мин үзем куйдым элеп.
Табынган да кебек булам,
Табынмаган да кебек.

Кавышканнар сирәк була —
Сөйлиләр бик тә белеп.
Яшәгән дә кебек үзем,
Яшәмәгән дә кебек.

Хәтернең ак диварында
Сурәтең тора көлеп.

## ХӘТЕРДӘ КАЛГАН СУРӘТ

Укылган китап күк ханым,
Кырын ятып ятагына,
Китап укый. Мәче белән
Эте ауный як-ягында.

Китапта — яшьлеге аның,
Үз яшьлеге — узмаганы, —
Үз бәхете, үз тәхете,
Үз базары, үз заманы...

Дөнья инде йоклый күптән,
Тик йокысы килми аның.
Таушалган бестселлер кебек,
Ятагында ауный ханым...

## ҮГЕЗ ЕЛЫ

*Шәраб алды сүзе*

Үгез елы — мөгез елы.
Көзгегә бер багарсың да
Үгез булып җигелерсең
Үкенечләр арбасына.

Үгез елы — мөгез елы.
Багарсың да заманыңа,
Үгез булып өстерәрсең
Көенечләр сабанын да.

Үгез елы — мөгез елы, —
Сүзем мөгез хакында да, —
Ир-атларга мөгез үссә,
Кызык булыр хатыннарга.

# НӘТИҖӘ

Урман биргән
аңа матурлыгын,
күлләр саф суларын
сипкәннәр.

*Һ.Такташ. «Урман кызы»*

Зиләйлүкләр,
Гөлҗамаллар булып
Ул җырларда яши һаман да...
Табигатьтә урман кызы иде,
Урам кызы итте замана.

## ЯМЬСЕЗ ХАТЫН

Ул үзен ямьсезгә саный,
Ямьсезгә саный күптән.
Булмады аны сөйгәннәр,
Булмады кочкан-үпкән.

Инде менә берьялгызы
Кереп бара көзенә.
Кемдер аңа еллар аша
Эндәшә күк:
— Түз генә,
Бу дөньяда сөешмәгән,
Кавышмаган без генә.

...Ничә еллар инде аның
Бакканы юк көзгегә.

## ҮЗЕҢ БЕЛ

Бу күзләрем яратылган —
Табынып өчен.
Бу кулларым яратылган —
Кагынып өчен.

Бу йөрәгем яратылган —
Сагынып өчен.
Аякларым яратылган —
Абынып өчен.

Иреннәрем яратылган —
Үбәргә сине...
Үзем ник яралган?
Ансын
Үзең бел инде...

## ЭЛЕГИЯ

Сөмсере коелган күкнең,
Көннең кәефсез чагы.
Козгыннар каркылдый.
Кемгә
Ясин чыгалар тагы?

Кара шәлен бөркәнгән көн,
Кулында — төн гөлләре...
Дулкыннар көлә шаркылдап —
Йоткан диңгез кемнәрне?

Пәрәнҗәле күк сулкылдый —
Сынган кемнең канаты?..
Чү, офыкта Тәңре кызы
Толымнарын таратты.

Һәм чишенде... оялчан гына
Кереп китте диңгезгә.
Йөзеп китте... Офык-ярда
Чәчелеп калды эзләр.

Чәчелеп калган эзләргә
Көн сипте төн гөлләрен.
Офыкта Тәңре кызының
Ишетелде көлгәне...

# МӘРХӘМӘТ

Ялгызым болынга бардым,
Чәчкәләр серен алдым.

— Әй, егет, ни сагышың бар,
Сиңа җандашың дәшә.
Телимсең, сөйгәнең булам, —
Диде шаян миләүшә.

— Әй, егет, ни хәсрәтең бар,
Ни кайгың — баштан ашкан?
Гомер юлдашың булыйммы? —
Диде горур ромашка.

— Әй, егет, кемеңне җуйдың,
Өнеңне күрдем төштә.
Телимсең, энкәең булам, —
Диде уйчан мәтрүшкә.

Ялгызым болынга бардым,
Чәчкәләр серен алдым.

## СИНЕ УЙЛАДЫМ БҮГЕН ДӘ...

Сине югалтканыма да
Күпме гомерләр үткән.
Син инде мине, мөгаен,
Сагынмыйсыңдыр күптән.

Син инде мине күптәннән
Оныткансыңдыр. Беләм.
Яшисеңдер затлы йортта
Затлы гына ир белән.

Көн дә эшкә барасыңдыр,
Кершән ягып ирнеңә.
...Кершәнсез дә иреннәрең
Тәмле, татлы иде лә.

Көн дә чират торасыңдыр
Син дә, әвәрә килеп.
...Ә без сөю алмасына
Чират тормаган идек.

Ә без сөю алмаларын
Ашадык өзеп кенә.
Шул көннәргә кайтасы ла...
Тик юллар өзек менә.

Сиңа илтер юлларымны
Зилзилә-вакыт күмә...
Мине онытсаң да,
Берүк
Бәхетсез була күрмә.

## ХАТЫҢНЫ АЛГАЧ

...Мин һаман да бөек сәрхуш әле,
Шушы җиһан — минем кабагым.
Мин дөньяга шигырь белән тулы
Бәллүр касә аша карадым.

Үкенәсең...
«Сагыш эчәм», — дисең,
Ә мин менә... шатлык кичерәм.
Кабакларда Кояш нуры эчеп,
Яфрак шавы тыңлап исерәм.

Үкенәсең...
«Үткәннәргә, — дисең, —
Кайтсак әгәр тик бер минутка,
Кочагыңда тамыр җәя-җәя
Күтәрелер идем болытка».

...Үкенмә дә, сагынма да мине,
Мин кичерәм сине, кичерәм.
Элеккечә Кояш нуры эчеп,
Яфрак шавы тыңлап исерәм.

Нигә үкенергә?

* * *

Мәхәббәткә нәфрәт җырлаганнар
Бармы җирнең берәр төшендә?..

...Кайчак шулай куркып уянам мин,
Тол шагыйрьләр күреп төшемдә.

## СИНЕ КАРШЫЛАГАНДА

Һәрчак шулай:
      Трапка аяк басуга,
            гел бер курку били мине:
                әгәр, вәгъдә биреп тә,
                      каршыларга килми калсаң,
                         алдаласаң...

Беркатлы уй, садәлегем
Шуңа капылт сүнәдер.
Шуңа һәммә каршылаучы
Син булып күренәдер...

# КЫШКЫ ТӨНДӘ ЯЗГЫ БЕР УЙ

...Диогеннар, хакыйкать дип,
Баш ватадыр бүген дә.
Ә миндә тал бөреләнә
Салкын тәрәз төбемдә.

Ул да язны көтә ләса,
Ул да назга сусаган.
Әй, яңа көн, ишетәсеңме,
Таллар язга сусаган,
Җаннар назга сусаган.

Кил, яңа көн, кил тизрәк,
Яктым булып кил миңа.
...Әнә офык күкрәгеннән
Җиргә ак җәймә иңә.

Кешелектә дә гамь күптер,
Юкка дуламый буран.
...Мин ялгызым тар бүлмәмдә
Сиңа сусап утырам.

## АЭРОПОРТТА КӨЗ

Аэропорт гүя дәрья.

Канатларын салмак җилпеп,
Аккошлар күтәреләә.

Ярга басып саубуллашам:
— Хәерле очыш сезгә!
Хәерле очыш сезгә!..

...Озату да сәер сине
Бу ямансу көздә.

## АЙНУ

Ул чакта син талпындың да:
— Канатым бул, — дигән идең.
Сөешүдән башларыбыз,
Әй, күкләргә тигән иде.

Ап-ак болыт иде безгә
Чатыры да, түшәге дә...
Бүген менә сүзсез калдык
Текәлдек тә түшәмеңә.
Акшарланган түшәмеңә...

## ТИМЕРЧЕ

Авылга бер тимерче ул,
Тимерче — гомер буе.
Сандалына салып чүки
Дөньяның фани уен.

Сандалына салып чүки
Сагышын, кайгыларын...
Һәм, догасын укый-укый,
Сагына тәүге ярын.

Авылда бер сылу иде,
Ятларга пар булды шул.
Үз карчыгыннан да, хәер,
Шөкерана, уңды ул.

Икесе дә гүрдә инде...
Каберләре — янәшә.
Пар чардуган, пар көмеш ай
Гүя үзенә дәшә.

Гүя телгә килә алар:
— Без бәхил синнән, бәхил.
Тиң күрдең икебезне дә,
Без бәхил синнән, бәхил.
...Тик сагыш түгел,
Син безгә
Гөлчәчәкләр алып кил.

...Күккә бакты карт.
Җанында
Гүя яшен яшьнәде.
Гөл-очкын булып кабынды
Сандалда күз яшьләре.

## САГАЙМАГЫЗ, ЯРЛАР!..

Без дә күнегәбез бугай
Заман тизлегенә —
Тамырларда ага Вакыт
Космик тизлек белән.

Йөрәкләр гүя Байконур!
Сагаймагыз, ярлар.
Бер кайтмасак, бер кайтырбыз —
Саргаймагыз, ярлар.

...Феденикс хәбәрен көтә
Бездән
Марсияннар.

* * *

Җирем адәми затларсыз
Мәгарә булса әгәр,
Син алиһә булыр идең,
Ә мин берәр пәйгамбәр.

Ваклыклардан азат булып,
Мәңге балкыр идек без.
...Югыйсә, шушы ак җирне
Агартырга килдек без.

Күпме күз төбәлгән безгә
Туар таңнар түреннән.
...Мәҗнүннәрне эзли шулай
Заман — бездән, бүгеннән.

* * *

Сөюең, елап, кул болгап,
Томан эчендә калса,
Күңелләрне генә түгел,
Язны да сагыш баса.

Кире йөгерәсе килә
Кышка — гөнаһсыз чакка.
Уй-хыяллар дәрьясында
Гомерләр аккан якка.

Бәлки, барып та җитмәмен.
Азмы җитә алмаган?!
...Яшәсен Сафлык — кышларда
Гөрләвекләр даулаган.

## СӨЙМӘ

Мине сөймә син,
Сөймә син мине.
Мин төнлә туган
Бер бала инде.

Гап-гади йөзем,
Гап-гади сүзем,
Гап-гади үзем...
Мине сөймә син,
Ташла... диңгезгә...
Ялвару дигән
Хисләр ят безгә.

Үзең тын ярда
Яшә дә яшә.
Теләсәң пыскы,
Теләсәң яшьнә...

Тик мине сөймә,
Сөймә син мине —
Мин төнлә туган
Бер бала инде.

## ЯТИМ КӨННӘР

Көйсез көннәр килде,
Көйсез көннәр.
Үксез сабый кебек
Туңа гөлләр.

Болыт-читлек аша
Бага Кояш.
Сүрән нур тамчысы —
Әйтерсең яшь.

Язгы гөлләр белән
Мин дә туңам.
Чытык көн шикелле
Күңлем тула.

Парсыз калган җаным
Ачыйм кемгә?!
Көйсез көннәр килде,
Синсез көннәр...

## ЛАНДЫШ

Юктан гына югалтканмын сине,
һәм син мине югалткансың ялгыш.
Чиксезлектән гүя дәшә кемдер:
— Язмыш...
язмыш...
язмыш...

...Төнге вокзаллардан эзлим сине,
чыклы сукмаклардан, парклардан.
Эзлим сине неон яктысында —
аэропортлардан.

Юк!
Мин сине табалмасам иде,
йә кочагыма ташланырсың ялгыш.
Һәм минем дә соңгы юанычым
кайнар күкрәгеңә башын куеп
җан бирәчәк, җан бирәчәк,
Ландыш...

И Ландыш...

## ТРИПТИХ

### Я ш ь  к ә л ә ш.

Нигә бик тиз күтәрелә әле
Төннең кара бәрхет пәрдәсе?..

### Т о л  х а т ы н.

Аһ, бу төннең озынлыгы!..
Кочагына ала да ул мине,
Таләп итә башлый күз яшемне.
Мин карышам.
Тик ни кылыйм?
Соң, ни кылыйм инде?!

### Я л г ы з  к а р ч ы к.

Шөкер,
Көннәр тагын озынайды.
Тәнемнең сызланулары,
Төрле шөбһә, йокысызлык
Кими,
Бетә барган кебек.
Их, гомер дә озынайса...

## СИН

Горурлыгым. Мескенлегем.
Таянычым. Абынуым.
Тугрылыгым. Хыянәтем.
Ихтыярым. Табынуым.

Бергәлегем. Ялгызлыгым.
Нәфрәтем. Мәхәббәтем.
Әсирлегем. Хөрриятем.
Яшәешем. Һәлакәтем.

## ХӘЕРЛЕ ЮЛ ТЕЛӘ

Йолдызларга ашам бүген…
Тик син гамьсез көлмә!
Күзләремне үбеп, ихластан
Хәерле юл телә.

Кайтмаска дип китеп барам…
Бәгыремне телмә!
Соңгы кабат үбеп, ихластан
Хәерле юл телә.

## СИН ВӘ МИН

Син ул — гүзәл!
Син ул — нәфис!
Миндә һаман элеккечә:
йөгәнләнгән
уй-хис.

Син ул — камил!
Син ул — матур!
Миндә һаман
элеккечә:
хөкем итә
салкын акыл.

Нигә әле күңелемдә
уянмаган уй соң?..
Ә бит синдә
күрер күзгә
искитәрлек
буй-сын...

# ЧАКЫРУ

...Әллә мәҗүси булуның
Төшендемме серенә? —
Куштым синең исемеңне
Күкнең һәр җисеменә.

Күзем кысам йолдызларга,
Айның сыйпыйм битеннән.
Тыңлап кояш-йөрәгеңне,
Языңа наз китерәм.

Хәтта яңгыр-күз яшьләрең
Энҗе бөртеге миңа.
Тик шатлыктан тама алар,
Рәхәтлек биреп сиңа.

...Кичер ләкин сине узып
Күккә менгәнем өчен.
Хисемне чәчеп, барсын да
«Син» дип сөйгәнем өчен.

Кем генә омтылмый күккә,
Сусап зәңгәр сафлыкка.
...Үзең мен әле яныма,
Тотын да ак офыкка.

# Ә СИН ТӨННЕ ЯРЫП ПЫШЫЛДЫЙСЫҢ

Тәнем буйлап тагын төн шуыша,
Бизгәк тота гүя уйларымны.
Ә син төнне ярып пышылдыйсың:
— Йолдызларны үбеп туймадыңмы?

Ә син төнне ярып пышылдыйсың:
— Күктән иңгән бәхтең мин ул! Мин ул!
Кочагыңа алып җылыт мине,
Йөрәкле бул, җанкай, йөрәкле бул!

...Сынга әверелгән горурлыкны
Эретерлек, терелтерлек сүзләр!
Тәкъдиреңә язылганны сызып,
Син һаман да хыялдагын эзлә...

## САГЫШЛЫ ЙОЛДЫЗЛАР

Баш очымда учма-учма йолдыз —
Миләш тәлгәшләре.
Ялгызлыгым, әйдә, бергә-бергә
Хозурланыйк әле.

Табигать тә өнсез тора бүген,
Көзнең үз эшләре...
Баш очымда учма-учма йолдыз —
Сагыш тәлгәшләре.

## СӘНГАТЬ

Милосская күк сылу ханым
Стриптиз бии кабакта...

Мона Лиза кебек серле ханым
Тәнен сата әнә аулакта...

Матурлыкның эталоны бүтән.
Серле караш — мираж гына бары.

Бөек сере миңа бу җиһанның —
Кояш эчкән
Уйчан ханымнары.

## ӘГӘР...

Алиһәм булсаң —
Табыныр идем.
Ал гөлләр булып
Кабыныр идем.

Еракта булсаң —
Сагыныр идем.
Хискә уралып
Абыныр идем.

Бергә булырга
Безгә соң инде.
Гөл-серебезгә
Кыраулар тиде...

## СӨЮНЕҢ АЛ ТИРМӘСЕ

Сөешмәскә сүз куешып
Саубуллашкан идек без.
Сөюнең ал тирмәсенә
Нигә кабат килдек без?

Карашларың — сер ташкыны.
Хисләрем иләс-миләс.
Сагыштан исергән башка
Нинди уй, ният килмәс.

Капылт кына сорармын күк:
Сөюне кая куйдың?
Хуҗасыз тирмәдә ялгыз
Яшәргә мәллә уең?

Мәхәббәттә җинаятькә
Ни җәза юк, ни хөкем.
Тирмәңә ут салсалар да,
Килеп карамас беркем.

Килеп карамас беркем дә...
Ә син кабат киләсең.
Күкрәкләрдә дөрләп яна
Сөюнең ал тирмәсе...

## САГЫНМЫЙМ ДА, ЮКСЫНМЫЙМ ДА

Сагынмыйм да, юксынмыйм да —
Бу җанымда ни халәт?
Акылгамы әллә күбрәк
Биреп куйдым вәкаләт.

Очрашу да көтмим хәзер,
Җанымның минор мәле.
Ялгызлык белән серләшәм,
Әллә дәрвишләнәмме?

Үзем көнлим, урам-чатта
Үбешкән парны күреп.
Алар никтер бер-берсен
Миннән нык сөя кебек,
Синнән нык сөя кебек.

Көнлим, әгәр беркөн килеп
Күңелеңә чиртсәләр,
Газаплы көн-төннәреңне
Тоташ бәйрәм итсәләр.

Мәңгелекнең кай төше бу?
Кышмы? Җәйме? Кайсы ай?
Мин сагыштан сырхауланып,
Саташып ятам бугай.

## ГЕЛ ЯМАНГА ЮРАДЫЛАР

Яңгыр тамчылары булып
Керфегеңә тамган идем —
Күз яшьләре, диделәр.

Исемеңне җырга салып
Җырлаган идем ачынып —
Кешеләр йөгереп килделәр.
(Сәрхуш түгелме, имеш.)

Ә бер кичне, уты сүнгәч,
Тәрәзәңә килеп чирттем —
Карак диеп белделәр.

Гел яманга юрадылар,
Ә безнең соң ни хата?!
...Гомерлек яр буласыңны
Белмәдем шул ул чакта.

# КАРТ ҺӘМ АЛТЫН БАЛЫК ТУРЫНДА ЯНӘ БЕР ШИГЫРЬ

Таңгы Идел. Акчарлаклар
Бәртәс чүпли кинәнеп.
Яр читендә утыра карт,
Калкавычка инәлеп.

Бер ташбаш капкан иде дә,
Кире җибәрде никтер.
Карчык тагын дулар инде:
— Әй, карт тиле, тизрәк,— дияр, —
Алтынын табып китер.

Тагын җәнҗал кубар инде...
Үзалдына сөйләнеп,
Яр читендә утыра карт,
Язмышына инәлеп.

## УЛ КЫЗ

Төшләремә кереп уята да,
Күзләремне үбеп саубуллаша.
...Гүзәлләр дә төсен җуя, диләр,
Карап баксаң җыр һәм идеал аша.

Ул кыз гына элеккечә кала,
Элеккечә кала бар гадәте.
...Эзләгәнне җирдә таба алсаң,
Шул — яшәүнең бөек сәгадәте.

## КАРТАЕЛА, АХРЫ

Күрәчәкне инде күткә түгел,
Күккә карап ешрак багабыз.
Кызлар кызыклана барган саен,
Кызыксызга чыга барабыз.

## КӨЯНТӘ ЯСАУЧЫ ЗАРЫ

Чишмә сукмагына чирәм үсте,
Көянтәләр менде чормага.
Заманы шул: каласы да хәзер,
Саласы да эчә торбадан.

Кыз-кыркыннар көянтәсез үсә,
Болай ыспай, сылу үзләре.
Дөнья йөге иңнәренә баскач,
Иңсәләре генә түзәрме?

Көянтәләр аунап ята хәзер
Урак, бишек белән янәшә...
Зөһрә кыз да, әнә, Таһир белән
Чишмә хозурында ярәшкән.

Чишмә сукмагында кавышканнар...
Шундый булган йола, гадәте.
Кайчан әле кыйбла иттек соң без
Әдәпсезлек дигән әдәпне?

Әдәпсезлек дигән әдәптәндер
Әверелә Сөю каргышка.
Азмы гашыйк су юлында түгел,
Суд юлында йөреп кавыша.

Бу әдәпнең чишмә башы кайда,
Агып килә кайсы чорлардан?..
Зөһрә кызның көянтәсен, әйдә,
Эзләп табыйк, энем, чормадан.

## ТАНЫШ ТҮГЕЛ БЕР СЫЛУГА

Төз аяклар,
Төз муен.
Таралып китте
Уем.

Иңнәрендә
Пар толым.
Уем гүяки
Болын.

Келәм булыйм
Юлында.
Чәчкә булыйм
Кулында.

Йөресен бәхет чигеп,
Хиссият илен гизеп.

Ә ул китте —
Уемны
Үкчәсе белән изеп...

# КАРА ХАТЫН

Друг мой, друг мой,
Я очень, очень болен.
*С. Есенин*

Мин яратмыйм сине!
Ә син — әрсез, горурлыгың җуеп,
сагалыйсың һәрбер адымымны;
очрашканда, күз карашың
нидер даулый,
нидер таләп итә.

Япа-ялгыз төнге тынлык белән
хозурланып янган-көйгән чакта,
Матурлыкка башым игән чакта,
син керәсең килеп арабызга.

Син — гүя шәүлә!
Син — гүя хәвеф!

Йөрәгенә бөтен җиһан сыйган
Шагыйрь һәлакәте яшәгәндә,
Син — нәфрәтем минем!..

## ШАХТЕР АГАЙ ҖЫРУЫ

Үтте гомер күмер чабып,
Чабалмадык атларда.
Газиз башлар читтә йөрде,
Ярлар калды ятларга.

Үтте гомер... бәхет эзләп,
Калды... өмет... аз гына.
Безнең бәхетне таш басты
Кара Дию базында.

Үтте гомер...
Тын кысыла,
Читләрдә ят һава да.
Әй, җил,
Туган җир һавасын
Алып килче дәвага.

Әй, җил, безнең сәламнәрне
Илтче Туган илләргә.
Сызгырып уз аулыбыздан
«Шахта» дигән көйләргә.

Сыздырып уз...
Сызуларның
Үз сихәте бар аның.
Исләренә төшмәбезме
Ятка калган ярларның...

## ТӨНГЕ ИДИЛЛИЯ

Төн — гүяки арфа...
Һәрбер кылы
Ай нурыннан аның үрелгән.
Тынлык сонатасы аһәңенең
Шавы килә галәм түреннән.

Галәм түрләрендә шытып чыккан
Чәчкәләре җәннәт багының.
Без ауныйбыз шунда...
Арабызга
Тын соната керә агылып.

Җәннәт чәчкәләре безне күзли,
Диләр бугай: менә тамаша!
Синең гүзәллекне көйгә салып
Уйный арфа...
Күзләр камаша.

## АЧЧЫ, ТУТАШ, ИШЕГЕҢНЕ...

*Заманча вариация*

— Аччы, туташ, ишегеңне, мин керәем.
Керфегеңә кунып бер эрәем.
Сөю сүрәсенең аять-шәмаилен
Күңел түрләреңә бер эләем.

Аччы, туташ, кочагыңны, мин керәем,
Җиләк иренеңнән бер үбәем.
Башым куеп ак күбектәй күкрәгеңә,
Кочагыңда килеш бер үләем.

— Әллә йолкыш шагыйрьме син, абзый кеше,
Әҗерен, дим, күпме түләең?..

## НӘРКИЗ...

Кем өчендер син дә ханбикәдер,
Кем өчендер мин дә кол, мөрит...

Хисләремнән алтын таҗ кой, әйдә,
Йөрәгемне тәхет-көрси ит.

...Үз-үзеңә гашыйк булып кына
Гомерләрең юкса үтә бит...

## АҢЛАСА...

Ут күзенә кереп барган
Күбәләктәй без һаман.
Канатыбыз канатка, дим,
Орынырмы берзаман?!

Аңласа, ут кына аңлар
Безнең йөрәк хәлләрен.
Гөлгә кунган күбәләктән
Корбан чалыр мәлләрем...

## СИНЕ САГЫНГАНДА...

Сурәтеңне ясап куяр идем,
Күз нурымны манып төсләргә.
Унсигез яз сеңгән карашыңа
Төсләр җитмәс сыман өстәргә.

Гаурәтеңне ясап куяр идем,
Чыкмый гына китап сүзеннән.
Унсигез яз үпкән күкрәгеңә
Күз тидерермен күк үзем дә.

# IV БҮЛЕК



## БӨЕКЛӘРГӘ ТАЯНАБЫЗ...

...Бөекләргә таянабыз.
Тормыш белән бәхәс чыгып,
үзебезне яклаганда,
        аклаганда,
        яман сүздән саклаганда...

Бөекләргә таянабыз.
Алардагы
        сәер холык-фигыльләрне
        үзебездә табабыз да
                юанабыз.

Бөекләргә таянабыз.
Табынабыз.
Сөрлегәбез.
Абынабыз.

Алардан без гаять тә
        күпне алабыз.
...Үзебезне тапкач кына
үзебез булып калабыз.

## БӘЕТ

*Фәиз Зөлкарнәй рухына*

Бәетләргә бәет чыгарырлык
Чорсыз чорлар килгән чагында
Мин дә бәет чыгармакчы булдым,
Сыктамакчы булдым тагын да.

Мин дә бәет чыгармакчы булдым
Күккә ашкан кардәш хакында.
Ай күрде дә Кояш алды аны
Үз янына,Тәңре катына.

Мин дә бәет чыгармакчы булдым
Бер юламан егет турында.
Еллар түгел — юллар илтә икән
Кайтып булмый торган урынга.

Еллар түгел — юллар өзә икән
Юламанның соңгы сәфәрен.
Соңгы сәфәр...
Фәрештәләр мәллә
Буташтырган гамәл дәфтәрен?

Еллар түгел — юллар кисә икән
Соңгы өметне дә...
Шуңарга
Юл газабы — гүр газабы, диеп
Калды хәзер авыр суларга.

Чәкештергән идек чәркәләрне
Шигырь саулыгына икәү без.
Үзебезнең исәнлекне генә
Истән чыгарганбыз икәнбез.

Чәкештергән идек чәркәләрне
Болай гына... Күңел өчен дә.
Офык аръягында чал Вакыт та
Керәдер күк шәфәкъ төсенә.

Чәкештергән идек чәркәләрне
Дөнья белән...
Булдык... казалы...
Юламанны соңгы сәфәренә
Озатадыр Киек Каз Юлы.

Мин дә бәет чыгармакчы идем,
Сыктамакчы идем тагын да,
Бәетләргә бәет чыгарырлык
Чорсыз чорлар килгән чагында.

Мин дә бәет чыгармакчы идем...

## СӘРХУШ

Ике кояш бата көн дә
Аның күгендә генә.
Ике ай йөзә төн буе
Аның күлендә генә.

Ике тәхет, ике ханча —
Аның түрендә генә.
...Чәркә аша чәчбие дә
Чибәр күренә менә.

Айныр иде...
Кайтыр иде
Мәгарәи мәленә.
Ул айныса, сәрхуш дөнья
Айнымас күк мәңгегә.

## ЭПИТАФИЯ

Фәрештәнең канат җиле
Тынына капты мәллә?..
Үлемсезлек каян килсен,
Фани булмаса бәндә...

## ТИПКЕ

Мин — кешеләр арасында
Адашып йөргән малай —
Җитәкләп киләм уемны,
Уем гүяки маэмай.

Әле алга ыргыла ул,
Әле борыла артка.
Әле өрә, әле ырлый,
Әле чабудан тарта.

Әле җиргә ятып ауный,
Әле текәлә күккә.
Һаулый башласа, башына
Кешеләр тибеп үтә.

Юатам үзен: сабыр бул,
Каударланма, дим, алай.
Кешене исеннән түгел,
Хисеннән таны, маэмай.

Эт типкесендә йөрсәң дә,
Илеңә илермә син.
Кешеләр, тотып, үзеңә
Борынчык кидермәсен.

Ил типкесендә йөрсәң дә,
Тибәреп булмый илне.
Ул үзе дә — нәкъ синең күк —
Муенчак кигән инде.

Мин үзем дә — нәкъ синең күк,
Типкедә йөргән малай —
Илемне уйлап килешем,
Уем гүяки маэмай.

## ОСТАНЫҢ КИТҮЕ

Йомычка кебек кыела,
Чәер күк эри көннәр...
Вакытның тәрәз йөзлеген
Иртәгә ясар кемнәр?

Тәрәз уемы шикелле
Уелган безнең чикләр.
Иртәгә туфан калыкса,
Нух көймәсен кем сипләр?

## НИГЕЗ

Сыркыдыда сыктап торганым бар
Хәйрүш әзи Такташ нигезендә.
Шайтан таяклары шыбырдашты:
— Бу нигездә калдык тик без генә.

Казанымда кузлар йотканым бар
Күктән сөрелгәннәр эргәсендә.
Шагыйрь булып ташлар ыңгырашты:
— Без һаман да тәкъдир төрмәсендә.

Тәкъдир булып туфрак пышылдады:
— Язмышыннан узмас берегез дә.
Нигезеңне саклап калыйм дисәң,
Күкләр белән кирәк берегергә.

# ДӘРДЕМӘНД КАБЕРЕ

Сүнеп, вәйран булып мәгъмуртияләр,
Җир астында тезелде ку сөякләр!..

*Дәрдемәнд*

Кара йөзләр кабат ил өстенә
Кызыл бурзайларын өстергән.
Империя дигән каток узган
Бакый йортның таптап өстеннән.

Җилләр генә түгел —
Зилзиләләр
Юган эзне... юган хәтерне.
Ярый әле Вакыт отып калган
Шигърендәге һәр юл-сәтырны.

Комнар гына түгел —
Кубарылып
Ташлар күчкән... кабер ташлары.
Ку сөякләр түшәп ил багына,
Илгәсәрләр җирне ашлады.

Илдә калган Гариб...
Байгыш Сагыш
Тоткандыр шул... илдә туңса да.
Шагыйрьләрнең язмышлары уртак —
Бай булса да, гидай булса да.

## ИНТЕРНЕТ

Санаклыны гына санлый дөнья,
Таный дөнья, аңлый... аңлаша.
Кырын ятып илләр чөкердәшә,
Безгә — кызык, безгә — тамаша.

Ил-халыклар лөгать-тел алмаша,
Аңлашканга иңә бәрәкәт...
Дөнья белән тынышырга була,
Ут-күршеләр белән — мәрәкә...

## ЙӨЗЬЯШӘР КАРТ СҮЗЕ

Бу дөньяда яши-яши
Мин тик шуны аңладым:
Кешедән көшел коела,
Ком коела аннары.

## СИН ХАКЛЫДЫР...

*Р.М.*

Буең озын, уең кыска,
Алдашасың хәйран оста.
Бар булмышың белән лаек
Бу илдә син һәрбер постка.

Шуңа да син бик күрсенмә,
Утыра бир көрсиеңдә, —
Дөрес булыр ялганың да,
Үрчи торыр яраның да.

Син хаклыдыр: йә, бу илгә
Хак сөйләгән тинтәк нигә?

Син хаклыдыр: илдә, димәк,
Ишәйгәндер синдәй имгәк...

* * *

Кошлар китә кәрван-кәрван —
Агачлар елап кала.
Без китәбез берәм-берәм —
Уйланып еллар кала.

# КАРАКЛАР

*Монологлар*

## 1. Кесә карагы

Дөньяга баш булыйм, дисәң,
Кесәң булсын кимендә.
Бер кесәсез хет кемсәң дә,
Тормый сукыр тиен дә.

Кесә кирәк, абзыкаем,
Бөләсеңне белсәң дә...
Бармагымны җил тырнады —
Ник җил исә кесәңдә?

Заман җиле исә мәллә,
Кесәң төбен кисәме?..
Онытмыйча әйт бичәңә —
Типчеп куйсын кесәңне...

## 2. Казна карагы

Казна малы — казалы, дип,
Кем әйткәндер алдан...
Бу ил үзе караклардан,
Казаклардан азган.

Илбасарлар изге монда,
Юлбасарлар — батыр.
Бу ил үзе илләр талап
Илле булган, бахыр.

Имансыз да имам монда,
Казна буры — казый...
Казна, диеп казаланма —
Умырып кал, абзый.

Казна, диеп мазаланма,
Ул бит синең казнаң...
Бу ил үзе дә угры-бур,
Караклардан азган.

### 3.Китап карагы

Әллә ил иләс-миләсме,
Әллә үзебез таман...
Кансызлык турында укып,
Азындык бугай тәмам.

Кан саркый мәҗрух гасырның
Җәнҗаллы кыйссасыннан.
Кыйссадан чыгып, башкисәр
Башыңны кисәр сыман.

Кыйссадан туры җаныңа
Төзәр күк җәллад-мәргән.
Кан исе килсә китаптан,
Бүрегә охшар бәндәң.

Гасырның канлы кыйссасын
Саталар һәрбер чатта...
Бүреләр үләттән саклый,
Димәк ки, без дә сакта.

### 4. Ат карагы

Көнем чая чаптар иде,
Тулпар иде төнем...
Атказанган ат карагың
Атсыз калды, энем.

Чаптарларны күрәм бүген
Тамашада гына.
Араннарда күшәп тора
Алашалар гына.

Шыр яланда утлап йөри
Тышауланган атлар.
Безнең атны күптән инде
Йөгәнләгән ятлар.

Ат биеткән чаклар булды
Җил сызгырган көйгә.
Җилләр күмде тояк эзен,
Йөгән тора чөйдә...

### 5. Йорт карагы

Таш куышта — тимер ишек,
Ишек саен тишек.
Әй, сез, мөлкәт мөритләре,
Хәлләрегез ничек?

Хәләлегез кайтамы гел
Вакытында өйгә?
Затлы туныгызга, димен,
Төшмәгәнме күя?

Йөзек сорап йөдәтмиме
Төн дә хатыныгыз?
Кай сандыкка яшерелгән
Көмеш, алтыныгыз?

Хәрамын да югалтудан,
Беләм, шүрли бәндә.
Бәллүр бәхетегез, димен,
Кайсы шүрлекләрдә?

Безне дә, дим, таш капчыкта
Саклый тимер ишек...
Әй, сез, мөлкәт мәхбүсләре,
Хәлләрегез ничек?!

# ДИПТИХ

## 1.Картлар йорты

Дөнья кадәр сагыш сыйган монда,
Дөнья кадәр кайгы сыенган.
Дөньялыкта сый-тәгамең калса,
Шөкер, Ходай өзми сыеннан.

Дөнья көтеп арган карт-корының
Исе китми монда юк-барга.
Сагыш эчеп, сусауларын баса,
Кайгы йотып ята йокларга.

Ә балалар
        дөнья
                куып
                        уйный
Дөнья дигән сары йортларда.

## 2. Җиһангирлар кәрт суга

— Сезгә дә булсын тамаша,
Безгә дә булсын кызык, —
Чыңгызхан белән Бонапарт
Кәрт суга кызып-кызып.

— Ә син, Леонид Ильич,
Торма кызыкны бозып.

— Бөек җиһангир кылычын
Бик җиңел димсең әллә?

— Тузны да каплый алмагач,
Король түгел син, кәрлә!

— Ә син, Гайсә, чәпчемә,
Үзең дә безнең хәлдә.

— Дөньясына баш булгач та
Ник баса икән нужа?

— Олуг казый әйтеп бирсен:
Кем бу җиһанда хуҗа?

— Башөсте, Корыч бабай,
Хөкемең чыгар, давай...

## ИРЕКЛЕ ШИГЫРЬ ТУРЫНДА

Ак, ирекле җыр суздык.
Иш
Булалмадык тургайга.
Без җыруның көй-аһәңен
Боздык кына бугай ла.

Кош шикелле хөр ул Шигырь,
Болыттай ак болай да.

# КАРТ ҺӘМ ЧАБАК

Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кабан күлдәй кадим каегында
Йокымсырап ялгыз карт утыра.

Каек төбендәге күлдәвектә
Чәбәләнеп ята сыңар чабак.
Сыңар чабак — гүя соңгы өмет,
Сыңар чабак — гүя соңгы чара.

Чабак чаклы гына соңгы өмет
Бәргәләнеп ята күлдәвектә.
Казан казнасының алтыннарын
Юкка гына күлгә күммәдек лә?!

Хан йөзеген йоткан картлач чуртан
Капмый калмас кебек кармагына.
Су кызлары табып бирер төсле
Ханбикәнең алтын тарагын да.

Сөйрәп чыгарыр күк албастылар
Казаланган Казан байлыгын да...
Йокымсырап утыра карт шулай
Кабан күлдәй кадим каегында.

Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кала чыр-чуына оеп, ярда,
Чабак көтеп, әнчек эт утыра.

## КӨПЧӘК МӘСЬӘЛӘСЕ

Тирмәсеннән чыгып кичә генә,
Имла таный башлап көчкә генә,
Тәгәрмәчне уйлап тапкан кавем
Патент даулар Тарих көпчәгенә.

## ИЯСЕЗ ИЯЛӘР

Күңелләргә ят ияләр
Ияләште, димсез.
Тел иясе телсез калган,
Ил иясе — илсез.

Уйлар бетте уйсызланып,
Уйлар, димсез, котсыз.
Йорт иясе йортсыз калган,
Ут иясе — утсыз.

Каннар, димсез, кансызланды,
Җаннар, димсез, җансыз.
Моң иясе моңсыз калган,
Аң иясе — аңсыз.

Кальбемезгә ят ияләр
Ияләшкән, димәк, —
Төп Нигездә, тәүбә кылып,
Коръән чыгу кирәк.

## АНТИСЕМИТ

Дөнья, бәлки, денгә керер иде,
Талмуд дигәннәре Күктән иңсә.
Альберт Эйнштейн — эскрипкәче,
Карл Маркс шагыйрь булып китсә...

## ДИН ТУРЫНДА

Мине игелекле мөселман дип
санавыгызны үтенәм.

*Лев Толстой*

Вөҗүдеңә тузан кунса,
Язык, гөнаһ тузаны,
Атакайга зарый кылма,
Күккә сыгын, туганым.

## КАУДАРЛАНМА, КАЛӘМ...

Дөньяныкы дөньялыкта кала,
Каударланма, каләм, кабаланма.
Кадерен бел Сүзнең...
Болай да бит
Гомеркәйләр — тоташ каралама.

## ДӘГЪВАЧЫ

Әле заманны сүгә ул,
Әле каганны данлый.
Бер канатлы сүз әйтмәгән,
Халык буләген даулый...

## СЮРРЕАЛИСТ

Ул дөньяны сүзе белән сулый,
Күзе белән уйлый, төш күрә.
Кашы белән космик дулкын тота
Һәм колагы белән төчкерә.

Ул вакытны эчә кушуч белән,
Чәче белән күккә үрелә.
Теле белән уй сурәтен ясый
Һәм борыны белән сүгенә.

## ТОТАЛИТАРИЗМ

Чал Парнасның итәгендә
Канатлы ат утлап йөри.

Аягында — тышау...

## ЯҢА ЭРА ТАРИХЫ

Кайда мәгърип, кайда мәшрикъ —
Беткән дөнья буталып.

Хач сәфәре көндәлеген
Хәтерләтә бу тарих.

Һәр битендә канлы язу,
Сөңге белән язылган.

...Тик барыбер калка Кояш,
Калка кыйбла ягыннан.

## ТӘҮБӘ

Кача-поса берәү
Ят күзләрдән үбә.
Һәм исенә килеп
Әйтә:
— Тәүбә,
тәүбә.

Кешелеген җуеп,
Кемдер була түрә.
Ә вөҗданы беркөн
Шыңшый, имеш:
— Тәүбә.

Йөрәге ярылып,
Бөек җаннар үлә.
Чорлар ыңгыраша:
— Тәүбә...
тәүбә...
тәүбә...

Фәрештә җаннар да,
Бәлки, тәүбә кыла.
Дөрес яши, имеш,
Җирдә җасус кына...

## МОҢСУ ШИГЫРЬ

*М. Әгъләмгә*

Аһ, гомерләр яна көйрәп.
Янсын...
                кагып төшер көлен.
Гомер сызар...
Вөҗүдеңне
Били барыр төшенкелек.

Гомер сызар...
Күзләреңә
Төтен булып керер Вакыт.
Вөҗүдеңнән кандала күк,
Коелышып төшәр ваклык.

Коелышып төшәр акча,
Сөяркәләр,
                низаг-гауга...
Шәхесең тирәли көн-төн
Әнчек этләр йөрер һаулап.

Шәхесеңне талар алар,
Бәхетеңне һәм үзеңне.
Таландыңмы, —
                йокысызлык
Били барыр вөҗүдеңне.

Йоклау язык —
Туган йортта
Нигезләрең таралганда.
Йоклау язык —
                Анаң телен
Әнчек этләр талаганда.

Йоклау язык —
Ил-йортыңа
Бурычың бар, бирәчәгең.
Этләр талар...
Вөҗүдеңне
Били барыр киләчәгең.

Өстәлеңә иелер дә
Күз текәр ул гамәлеңә.
Һәм син кабат сыктап-сыктап
Үрелерсең каләмеңә.

## БУ ЯНУЛАР...

Бу янулар яну түгел әле,
Фатихасыз булсаң картлардан...
— Минем хакта шигырь чыгар, — диеп
Сөйләмиләр безнең якларда.

Гәзит ертып, махра төрә-төрә
Гәп куертып яткан чакларда,
Әйтеп куя бабай: «Бу нигезне
Сезгә инде, улым, сакларга...

Нигезебез — халык рухы безнең,
Халык моңы, халык аһәңе.
Шул аһәңнәр белән горурлан син,
Белеп яшә олы бәһаңне».

...Гәзит ертып, махра төрә-төрә
Гәп куертып яткан чакларда,
— Минем хакта шигырь чыгар, —диеп
Сөйләмиләр безнең якларда.

Әлмәндәрдәй бөек бабайларның
Өмет күзе — бездә, яшьләрдә...
Безгә язсын җыр язмышы булып,
Моң язмышы булып яшәргә.

## ӘЙТӘ ИДЕМ

«Гөлҗамал»ны көйләп, әбкәм
Җеп эрләгән чакта,
Әйтә идем:
— Әбекәем,
Күзләреңне сакла.

Уразага кереп, әбкәм
Хәлсезләнгән чакта,
Әйтә идем:
— Әбекәем,
Саулыгыңны сакла.

Тыңламады.

Үз дигәнчә яшәде ул,
Күпме иза чикте.
Тарих күк серле карашын
Безгә төбәп китте.

# МИН КИТКӘНДӘ...

*Сабакташым Рәиснең*
*якты истәлегенә*

Мин киткәндә еламагыз,
Елап калмагыз берүк.

Китүләрсез кайтып булмый —
Мин дә кайтырмын бер көн.

Кыр казы булып кайтырмын,
Ахры, кыр казы булып...

Танырсыз, дим, авылыбыз
Турысына җиткәч тә.

Бер кыр казы, аерылып,
Берьялгызы очып үтәр
Туркай тавы өстеннән.

Китүләрсез кайтып булмый —
Елап калмагыз берүк.

Кыр казы булып кайтырмын,
Кыр казы булып...

## ЯЛГЫЗЛЫК

Сез дуслардин айрылсам да,
Кинә тотма берүк, яшьти.
Рәнҗемә дә...
Мин картайдым.
Хатирәләр белән яшим.

Рәнҗемә, дус.
Мин картайдым,
Бәбәкләрем шуңа яшьле.
Ничә айлар, еллар инде
Хатирәләр белән яшим.

Син сорама яшемне дә —
Утыздадыр, бәлки, яшем.
Син сорама хәлемне дә —
Хатирәләр белән яшим.

Теткәләнгән хәтеремнең
Әләмнәре яшел...
яшел...
Ничә гасырлар ялгыз мин.
Хатирәләр белән яшим.

...Сез дуслардин айрылсам да,
Кинә тотма берүк, яшьти.

## ҖӘЛИЛ ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНДА

Дөнья тора кыл өстендә.
Ә күктә — кошлар җыры...
Омтылышыннан шагыйрьнең
Өзелер күк зынҗыры.

## ГЫЙБРӘТ

Аз яшәп тә җирдә
күп гыйбрәтләр алдым.
Бала чакта ук мин
ил картының
үлем алды сүзен тыңладым.

## ШИКАЯТЬЧЕ

Шикаять яздың утырып,
Ак кәгазьне тутырып.
Күрәм, тагын кубаргансың
Вөҗданыңның кутырын.

Азапланма!
Юк барыбер
Үз-үзеңнән котылу —
Кемгә шагыйрь булу язган,
Кемгә — ишмиче булу.

## АЗАН

Азан вакыты.
Үз моңы,
Үз зары бар азанның.
Тәңре белән серләшер,
Берләшер чагы җанның.

Азан вакыты.
Күкләрдән
Коела төннең көле.
Халкым минем дога кылып
Каршылаган һәр көнне.

Ни кылса да, халкым эшне
Бисмилладан башлаган.
Шуңа исән чыккандыр ул
Әҗәл дигән басмадан.

Азан вакыты.
Намазга
Дәшә Таң, дәшә Иман.
... Бабамны азан уяткан,
Мине уята гимн.

Азан вакыты.
Заманга
Иман иңдерер чаклар!
Ак намазлык өсләренә
Башың идерер чаклар!

Ә бит булган шундый заман —
Сүндереп Ай, Кояшны,
Ак намазлык өсләрендә
Уйнаганнар уйнашлы.

Тәмугка олактырганнар
Абыстаен, мулласын...
Кемнәр, димәк, унҗидедә
Әйтергә бисмилласын
Оныткан булган.
Шуңадыр
Гөнаһлар —
        ашкан баштан.
Диктатураның холкы бер:
Көчләгән, кискән, аскан...

Диктатураның холкы бер,
Бер үк — кай заманда да...
Казанда азан вакыты, —
Дәшә мәзин намазга.

Азан вакыты.
Үз моңы,
Үз зары бар азанның.
Дөньялык белән бергә-бер
Аңлашыр чагы җанның.

## ХАЛЫК ХӘСТӘРЕ

Йоласы шундый:
кышка — печәнсез,
җәйгә әйрәнсез
керми ул халык.

Шундый гадәте:
энәдән алып дастанынача
барлый ул халык.

...Киләчәгенә
телсез, лөгатьсез
бармый ул халык.

## КЫШ. «БОЛГАР» ЧАТЫНДА

Үткәннәрем күңелемдә
Җырлар булып яңара...
Гаҗәпмени — чын шагыйрьләр
Яралардан ярала.

Гаҗәпме: халкың гамьнәрен
Киләчәккә илтүе?
Дөньяның бар күз яшьләрен
Үзеңнеке итүе?
Гаҗәпме?

Ялган бәхет хозурында
Яшәп ятса рәхәт, җай,
Бугазларга төер булып
Утырмас иде Тукай*.

Ташта үскән гөлләр кебек,
Тетрәтмәс иде җыры.

Туңган песнәкне кызганып,
Син җыр яздың, хозурланып...
Ә бүлмәңдә — җып-җылы.

* С. Хәким шигыренә ишарә.

## ЭЛЕГИЯ

Хыял булып инде җиргә,
Хыялый булып туды.
Агач башларына менеп,
Йолдыз чүпләмәк булды.

Айга дәште...
Зөһрә кызга
Әллә сөю аңлатты.
«Явыз» димәде беркемгә —
Ул бары тик яратты.

Таш белән бәргәннәрне дә
Аш белән сыйлый белде.
Шатлыктан да, кайгыдан да
Сабый күк елый белде.

Хыял булып яшәде ул,
Хаклык булып яшьнәде.
...Сынган канатларын аның
Юа хәзер Ай кызының
Сагышы... күз яшьләре...

## ЙОРТ КАЗЛАРЫ

Кыр казлары, кыр казлары оча —
Кай илләргә икән юллары.
Болыт-күлгә кунаргамы теләп,
Күтәрелгән алар югары.

Юк, санамыйм санын, исәбен дә,
Йә чылбыры китәр өзелеп.
...Ә җир өсләп, тау ягына табан,
Йорт казлары бара тезелеп.

— Кыйгак-кыйгак, булмый күтәрелеп,
(Их, күкне бер иңләп кочарга!)
— Кыйгак-кыйгак, ә үзебез әзер
Кыр казлары белән очарга.

Кыйгак-кыйгак...
Кыр казлары оча,
Кай илләргә икән юллары?
Бездән сискәнепме әллә шулай
Күтәрелгән алар югары.

## АЮДАГ

*Кырым истәлеге*

Аютауга менеп барам,
Сак кына баса-баса.
Акчарлаклар азан суза,
Диңгез чыр-чуы — аста.

Йоклый аю...
Ниләр генә
Керә икән төшенә.
Уятырга теләп, ахры,
Дулкын кага түшенә.

Дулкын кага...
Дулкыннар да
Исәптә, уйдадыр күк.
Туган телдә дәшсәм, таулар
Сискәнеп уяныр күк.

* * *

Гамьнәр таләп иткән җаның
Кире уйлый калса,
Ташка ятып үксе!

Үксе ятып!.. Җаныңны бер
Үле ташка тидер —
Ташта гөлләр үссен!

* * *

Теләсә дә —
хан башмагы
Булалмас киез ката...
Илдә хуҗалар ишәйсә,
Хуҗасыз этләр арта.

## НИ ӘЙТИМ

Һәр чатта шигырь сүгәләр,
Мин аларга ни әйтим...
Шигырь, димәк, үксез калган,
Хәкимсез калган, ятим.

# ЯРАН

*Нивх язучысы*
*Владимир Сангига*

Көнне күрми яткан таҗга
Ал нурларын сипкән —
Җирдә гөлләр үссен өчен
Бер Кояш та җиткән.

Гөлләр өскә үрли һәрчак,
Гел яктыга табан.
...Сокландырмыймыни безне
Булмәдәге яран?!

Юкса аңа Кояш та бит
Карый алмый туры.
Ә ул — гүзәл, һәрдаимдә
Камиллеккә юлы.

## АРАН. МӘХБҮС АТ

Бер көн сугым сараена
Китәсенме тоя —
Канатлы ат, ауный-ауный,
Каурыйларын коя.

## КЫСКА ШИГЫРЬ ТУРЫНДА

...Озын сүзнең кыскасы шул
(Хаклыгына юк шигем):
Кысалар кысылган саен,
Кыскара бара шигырь.

## ЗӘВЫК

Берәүнең дә кулы җитмәс
Йолдызлар ошый миңа.

Берәүне дә гашыйк итмәс
Буй кызлар ошый миңа.

Һичберәү дә хаталанмас
Хаталар ошый миңа.

Һичкемгә дә охшамаган
Кешеләр ошый миңа.

# МЕТАМОРФОЗА

*Триптих*

**1**

бәбәгемә агып керә тыкрыклар урамнар
агып керә машиналар чаганнар һәм кешеләр
агып керә бәбәгемә матур тезле хатыннар
бүген оҗмахтан сөрелгән Хәва ханым төслеләр

керфегемә тиеп үтә тулышкан күкрәкләре
күзләремнең алмасы ла яньчелә аһ яньчелә
бәбәгемә агып керә буйга узган хатыннар
...бәбәгемнән агып чыга
яшь кенә

**2**

колагыма очып керә канаты сынган сүзләр
очып керә анекдотлар гайбәтләр һәм талашлар
очып керә колагыма бәхилләшкән авазлар
әнә сугым сараена кереп бара карт алаша

колак яфракларым лепердәшә ачы җилләрдә
көзен саргаер алар да саргаер дим аз гына
колагыма очып керә саргаешкан авазлар
...колагымнан очып чыга
кайтаваз гына

**3**

бугазыма шуып керә формулалар төркеме
шуып керә икмәк һава һәм тәмәке төтене
шуып керә бугазыма улым сулыйсы һава
улым сулыйсы һавадан тончыгып гөлләр ава

катлам-катлам сөрем ята бугазыма үпкәмә
гомер учагым шым гына сүрелә аһ сүрелә
бугазыма шуып керә икмәк һава һәм шәраб
бугазымнан шуып чыга
сүз генә

## ЗАЯГА УЗГАН КӨН

Көнем булып ауды шәүләм ятагыма.
Ауды шәүләм —
    әллә сәрхуш, әллә аек...
Ауды шәүләм —
    шәфәкъ сеңгән бәбәгендә
Эт кояшы бара иде баеп.

Ауды шәүләм...
    Соңгы сынык тәмәкесен
Кабызды да калтырана-калтырана,
Одеялга үрелде ул...
«Туңа җаным,
Бәгырь, — диде, — бәгырь катылана».

Ауды шәүләм...
    Яньчек табак чыраенда
Түшәмгәчә сикерешә пар куләгә.
Томаланган тәрәз, бикле ишекләрдән
Төн агылып керде тар бүлмәгә.

Төн агылып керде
    сырхау уйларына,
Кесәсенә,
    шәфәкъ сеңгән бәбәгенә...
Ятагымда көнме, төнме пышылдады:
«Бәндә генә шул син, бәндә генә...»

Ятагымда көнме, төнме шаркылдады:
«Көләң генә калды, бәндәм, көләң генә...»
Ауды шәүләм...
    Соңгы сынык тәмәкесе
Пыскып ята иде
Көллегендә.

* * *

Таң каршында басып торам, —
Җиһан — канга манчылган күк.

Көн каршында басып торам, —
Дөнья — тоташ сурәт кенә!

Төн каршында басып торам, —
Шомлы тынлык. Син. Йолдызлар.

...Гомер каршысына басып,
Мизгел эзлим дөньялыктан.

## КӨЗ. КОШЛАР ӨНЕ

Кешеләр
ышаналар һәм ышанмыйлар
ялгышалар һәм ялгышмыйлар
Ә без менә очабыз гына

Кешеләр
кавышалар һәм аерылышалар
очалар һәм шуышалар
Ә без менә
хушлашабыз гына

* * *

*Ркаилгә*

Кемнәр, әйдә, хөсетләнсен,
Кемнәр, әйдә, җыласын —
Уең барда — уйдырып сал,
Җырың барда — җырла син.

Ни кылсаң да —
кылганнарың
Бер көн үзеңә кайта.
Моңлы һәр җыру
халкыңның
Гомерен озынайта.

## ТӨРЛЕ СҮЗЛӘР ЙӨРИ

Төрле сүзләр йөри шагыйрьләр хакында,
тере һәм дә мәрхүм
шагыйрьләр хакында:
берәве ач-фәкыйрь яшәгән, янәсе,
берәве уңмаган хатыннан.

Бер шагыйрь көн иткән, ди, сукбайлыкта,
өстен булам, дип, даннан, байлыктан.
Бер шагыйрь, янәсе, сыра бик яраткан,
бер шагыйрь фәкать «Мальборо» тарткан.

Ә бер шагыйрь гашыйк булган
чит бер хатынга.
Ләкин ни хикмәт —
шигырьләр хакында түгел сүз,
шагыйрьләр хакында?!

* * *

*...га*

Алкышларны аз эчмәде яшьлегендә.
Яшьлек үтте, чәчләр бетте коелып...
Көн итә ул хәзер
　　кичәге данының
Юынтык
　　суларында
　　　　коенып.

## ПУШКИННЫ УЙЛАП

Беркайчан да бөекләргә
Сан булмаган бу илдә...
Чын шагыйрь дуэльдә үлә,
Әйе, фәкать дуэльдә.

## ЯШИЛӘР...

Яшиләр Ватанда
Сүздән май язып та.
Яшиләр Ватанда
Шикаять язып та.

Яшиләр Ватанда
Акылдан язып та.
Яшиләр — үлемсез
Шигырьләр язып та.

* * *

Бөекләр хакында илдә
Юк бәхәснең тынганы:
Бөекләрнең башын ашый
Хәмер йә хатыннары.

# ШАГЫЙРЬ АВЫЛЫ

*Рөстәм абыйга*

Бу тарихта кыйтгалар да
Кергән анысы гүргә.
Ә бүген бер авыл вафат —
Басыгыз аягүрә.

Ә бүген бер авыл вафат,
Шагыйрь авылы — Йолдыз.
Беләм, Мингалим, авылсыз
Мәңгелек ятим, тол без.

Яшәп буладыр ялгыз да,
Яшәп буладыр — беләм.
Космик ялгызлык сагышын
Сеңдергән күзләреңнән.

Таныйм синең авылыңны,
Таныйм да... тынып калам.
Әнә кызлар суга төшә
Чирәмле тыкрыклардан.

Әнә әнкәң көтү куа,
Әнә син... малай чагың.
Белә микән ул төп йортта
Мәңгегә калачагын.

Белә микән ул —
Үлемсез
Җырга әвереләсен.
Әйе, безгә бу дөньяда
Һәрчак авыр, беләсең.

Әремле нигез өстендә
Җилләр укый җеназа.
Шагыйрьнең авылы вафат —
Тын калыгыз беразга.

* * *

*...ка*

Һәркем үзенчә тәхетле,
Һәркем үзенчә шаһ ир...
Патшалар да шагыйрь була,
Тик патша булмый шагыйрь.

## ЯНӘШӘЛЕК

Һәрбер чатта ир яманлап
Яшәгән хатыннар бар.
Һәрбер чорда патша мактап
Яшьнәгән акыннар бар.

## ХАЛЫК ОСТАЛАРЫ

*Гаян ага Әхмәтшинга*

Остазның да остазлары була,
Останың да була остарагы.
Бу дөньяга ишек-тәрәз уйган
Галиҗәнап халык осталары.

Балта сораганга шөшле биреп,
Шаярса да язмыш дигәннәре,
Ил сурәтен ясап түргә элгән
Галиҗәнап халык ирәннәре.

Моң сурәтен бизәк итеп уйган
Идел-йортның тәрәз йөзлегенә.
Шуңадыр без үзебез дә моңсу,
Өйләр дә гел моңсу йөзле генә.

Моңсуланырсың да...
Сәрхуш дөнья
Ишек-тәрәзәне бутаганда,
Намус тәрәзәдән йөргән чакта,
Бурзай яткан чакта бусагада.

Моңсуланырсың да...
Җан сурәтен
Шау тимердән койган чакта заман.
Ярый әле хәлфә Акмулладай
Халык осталары исән-аман.

Балта сораганга шөшле биреп,
Шаярса да язмыш дигәннәре,
Бу дөньяга ишек-тәрәз уйган
Галиҗәнап халык ирәннәре.

## ПЕДАНТ

*Н.Х.*

Баш вәзирдәй вәкарь белән сөйләр,
Вәкарьләнеп сөйләр чак кына.
Чин теледәй безгә читтер дә ул,
Чин теледәй безгә якын да.

Һәрбер сүзе кысаланган булыр,
Ә кысасы булыр... алтыннан.
Латин теле кебек олпат та ул,
Латин теле кебек салкын да.

Алтын кысалы шул сүзе белән
Кертмәк булыр безне ул игә.
Ана теле кебек газиз дә ул,
Ана теле кебек үги дә...

## СӨЛӘЙМАН ПАТША СҮЗЕ

Пакь булса хатыны,
Ире дә ирәер.
Низаглы нигездә
Ятимнәр игәлер.

Хак булса патшасы,
Халкы да исәер.
Гаугалы дәүләттә
Түрәләр ишәер...

## ИҢ ЯМАНЫ...

Дус-ишләрнең иң яманы, диләр,
Астыртыны — астан чакканы.

Хатыннарның иң яманы, диләр,
Ир йөзенә кара якканы.

Ир-атларның иң яманы, диләр,
Ата-баба нигезен сатканы.

Бу дөньяда иң яманы, диләр,
Сызып-сызып гомер акканы...

## ҮРМӘЛӘҮ

Үзән үргә үрмәләр,
Түрә түргә үрмәләр,
Нәфес малга үрмәләр,
Гарьсез данга үрмәләр.

Иблис җанга үрмәләр.

## ТАТАРЧА ЯЗУ

Яугир ирләр тарих яза —
Дәүләт кора.
        Төзи кала.
Әтрәк-әләм әләк яза —
Хәрабәләр
        аунап
            кала...

## КИТАП БАЗАРЫ

Кил ки, зарым!
Юк язарым.
Чөн кабул итми базар.
*Дәрдемәнд*

Маркиз де Сад, Сю, Жид... —
йә, рәхим ит,
Җанкаеңа ятыш кайсысы?
Базар агайлары китап сата,
Аларда да тамак кайгысы.

Базар агайлары китап сата,
Китап, әйе, дөнья тоткасы.
Син алардан сора кемлегеңне,
Кулларыңа каләм тотканчы.

Базар агайлары китап сата,
Ә син, имеш, акыл сатасың.
Татар акыллары төштән соң ла...
Акылыңны җилгә аткар син.

Базар агайлары китап сата,
Мажаралы кыйсса, кәмитләр...
Бүген әнә китап бастырырга
Акча эзләп чаба әдипләр.

Кай тарафка ага бу замана? —
Әһле каләм әһел-түрәдән
Хәер эстәп йөри...
Ә Тукайга
Байлар әнә үзе түләгән.

Базар көләр, бәлки: «Сезгәме соң
Тукай кебек язу, кит әле!..»
Базарларда түгел — базада шул
Аунап ятты татар китабы.

Чормаларда, архивларда ятты,
Посып ятты сандык төбендә.
Вәхши яккан учакларда янды —
Без ялдык китап көленнән.

Гаҗәпләнмә, туган, базарларда
Безнең әфтиякне тапмасаң.
Базар агайлары китап сата:
Кафка, Камю, Ги де Мопассан.

* * *

*Габделнур Сәлимгә*

Шәһәр ташларына башың куеп,
Ауный-ауный, их, бер көләргә.
Бер көлүең җавап булыр иде
Сине танымаган көннәргә.

Туган нигезеңә башың куеп,
Ауный-ауный, их, бер еларга.
Бер елавың савап булыр иде
Сине аңлар, данлар елларга.

## ХӘТӘР

«Татар барда хәтәр бар»дан
Калган инде шом гына...
Хәтереннән яза татар...
Бөтен хәтәр — шул гына.

* * *

*Р.Н.*

Сәхнәдә чынлап яшәде,
Ә тормышта — уйнады.
Бу дөньяда яшәүне ул
Уен диеп уйлады.

Бу дөнья аңа тамчы да
Кертмәде бугай акыл.
Сәнгатькә корбан кирәккәч,
Үз башын куйды, бахыр.

Бөек иде... Тиле диеп
Сөйләделәр ахырдан.
Илдә олтан булды... Читләр
Һәйкәл куйды алтыннан.

## КҮРӘЗӘЧЕ КАРЧЫК ӘЙТТЕ МИҢА

Күрәзәче карчык әйтте миңа:
— Син бәхетле булалмассың, улым,
Син бәхетле булалмассың, улым,
Шигырь яза белгән чакта кулың.

Күрәзәче карчык әйтте миңа:
— Дусларыңнан саклан, дусларыңнан.
Дусларыңны укыйм күзләреңнән,
Дошманыңны укыйм учларыңнан.

Күрәзәче карчык әйтте миңа:
— Хатын-кыздан читтәрәк йөр, читтә.
Сагыз булып сыланыр ул сиңа,
Чаян булып чагар ахыр чиктә.

Күрәзәче карчык әйтте миңа:
— Йөрәгеңдә күрәм кара ярчык.
Кара ярчык — киләчәгеңме ул,
Үткәнеңме әллә — калган качып.

Күрәзәче карчык әйтте миңа:
— Беркемгә дә, улым, тотма кинә.
Алдыйм, диеп, кемнәр алданмаган,
Килә ул көн, һәркемгә дә килә.

Алдыйм, диеп, кемнәр алданмаган,
Мең кат әле алданырсың, улым,
Мең кат әле абынырсың, улым,
Каләм тота алган чакта кулың.

Күрәзәче карчык әйтте миңа...

# ЯЗМЫШ

*Фәннур Сафин ядкәре*

Күзләреңә черки булып кергән,
Бөҗәк булып төшкән үзәгеңә.
Күзләрең дә, үзәгең дә түзгән,
Тик вөҗданың ничек түзгән менә?

Вөҗданыңны келәм итеп җәйгән,
Зина кылган келәм өсләреңдә.
Ә син — сабый, сыенгансың килеп
Табигатьнең өстен көчләренә.

Яшеннәргә килеп сыенгансың,
Ни уй булган, белмим, башларыңда.
Фәрештәләр саклагандыр сине,
Калган чакта көпчәк асларында.

Язмыш дигән көпчәк асларында
Исән калган идең тапталып та.
Әҗәлләрең җитсә, булмый икән,
Калып булмый икән акланып та.

Хәер, әле нигә акланулар,
Калды ласа синнән аклык кына.
Ак җаныңны, юк, каралта алмас
Дөньядагы юк-бар ваклык кына.

Шул ваклыклар юкса бөҗәк булып
Үрмәләгән синең өсләреңә.
Ә син — сабый, сыенгансың һаман
Табигатьнең өстен көчләренә.

## ЮК

*Тукайны уйлап*

Йортың да юк синең, хатының да,
Акчаң да юк, көмеш, алтының да.
Очар кошка әверелим, дисәң,
Сикерергә — биек балконың да.

Күзең дә юк синең, язларың да,
Үзең дә юк, беткән язарың да.
Гайбәтчеләр гайбәтеңне сата
Учлап-учлап Печән базарында.

Гайбәтчеләр гайбәтеңне сата,
Намусыңны сата гаярьләре.
Намус бәяләре төшкән саен,
Үсә бара донос бәяләре.

Ир өстеннән ирләр донос яза,
Ил өстеннән илләр...
Качкан оят.
Җасус ирләр ирлекләрен гүя
Иннек-кершән белән куйган буяп.

Ир өстеннән ирләр донос яза,
Кулларында — гөрзи, җәяләре...
Кеше бәяләре төшкән саен,
Үсә бара көчек бәяләре.

Ә көчекләр өреп кала сиңа
Өркегәннән — шундый хәйләләре...
Ватан бәяләре төшкән саен,
Күтәрелә алтын бәяләре.

Ә синең юк илең-Ватаның да,
Акчаң да юк, көмеш-алтының да.
Очар кошка әверелим, дисәң,
Сикерергә — биек балконың да...

## СУКБАЙ ЭТ

Этләр дәүләтендә беркөн
Хан булыр бу йә вәзир...
Кем сөяк ыргытса,
Шуның
Эте булырга әзер...

## НИЗАГ

Хатыннар ызгыша —
үз туксанын хаклап.

Ир-атлар сугыша —
горурлыгын саклап.

Дәүләтләр кырыша —
мәнфәгатен яклап.

...Ә яшь ике этәч,
кара канга батып,
мәхәллә бүлешә...
Торам шаккатып.

## КӨЙ ЧАКЫРУ

*Шәүкәткә*

Кучем ханның күченнән ул,
Төмән дигән тияктән.
Бу Казанга тик адашып
Килеп чыккан киектәй,

Гел сагаеп яшидер күк,
Гел сагынып яшидер.
Шуңа һәр кош ахир аңа,
Һәрбер җәнлек яшьтидер.

Һәр киекнең көен белә,
Көе китсә — көенә.
Ул юксынып яшидер күк
Себернең черкиен дә.

Җанында ау комарлыгы
Алса әгәр уянып,
Чөй язуын укыгандай
Укый эзен куянның.

Кошлар эзен укый күктән,
Укый үлән ымын да.
Бер мәҗүси шаман сыман,
Көй чакыра ырымлап.

Көй чакыра... Әле кем дә
Көйләмәгән үзгә көй...
Күзе буйлап ялгыз болан
Чабып узды гүяки...

## ФАТИР КӨТӘ ИРЛӘР

...Алар
гомер иткән
йортның нигрәләре
черек булган, диләр, —
фатир көтә ирләр.

Фатир көтә ирләр —
гаиләсенә,
балигъ булган улларына,
кызларына,
фатир көтә оныкларына...

Алар гомер иткән йортта хәзер
бичуралар яшәп ята, диләр, —
әзергә-бәзер.

Алар гомер иткән йортны тиздән
ишеп төшерәчәкләр, диләр,
Төп Нигездән.

Төп Нигезне хәвеф-гарасаттан
саклап калыр,
яклап калыр ирләр
фатир көтә.

Тезелешеп басканнар да
гомер озынлыгы чиратларга,
фатир көтә ирләр.

Алар
гомер кичкән
йортның
нигрәләре
черек булган, диләр...

# Ә СӘРХУШЛЕК БЕЗНЕҢ — ЯЗМЫШ, АХРЫ...

*Ләбибкә*

Төрле тарафлардан килә хәбәр,
Безнең, яшьти, яман икән хәлләр.
Бар ул бездә ансы кимчелекләр:
Исерек без, әйе, исерекләр.

Исерәбез затлы хатыннардан,
Кыска итәк, озын балтырлардан.
Булмый кайчак айнып өлгереп тә —
Исерәбез хәмер чөмереп тә.

Исерәбез сылу күкрәгенә
Ялгыш кына орынса да куллар.
Ә сәрхушлек безнең — ялгыш, ахры,
Язмыш, ахры — айнып булмый шуңар.

Ә сәрхушлек безнең — язмыш, ахры,
Без — исерек кораб җилкәннәре.
Без күп күрдек төнге палубада
Кемнәр ничек уйнаш иткәннәрен.

Айкалды да, чайкалды да кораб,
Таң атуга посты кайсы кая.
Әверелде кайсы карт монахка,
Әверелде кайсы абыстайга.

Дөрес, ансы, без дә изге түгел,
Бездә дә бар ансы кимчелекләр.
Шуңа, әйдә, тәкъваланмыйк, яшьти,
Исерек без, әйе, исерекләр.

## ЭЧКЕ ДИАЛОГ

Әйтәсе иде:
— Ни уйлый кеше хакында
үлән-агачлар,
җәнлек-җанварлар,
очар кошлар?..

— Ни уйлый үзе хакында
кесә каракларьı,
урам көчекләре,
куштан-әләкчеләр,
доносчылар
һ.б.

— Ни уйлый иле хакында
иленнән мәхрүм халыклар,
ыру-кабиләләр?..

Әйтәсе иде:
— Нигә йолдызларны үтермәкче тиран?
— Нигә мылтык төзи бәндә аккошка да?
— Нигә шагыйрьләрнең гомерләре кыска?

Әйтәсе иде:
— Нигә кайчак акыллы да
Яза соң акылдан?

Әйтәсе иде:
— Ни уйда икән кешеләр
Үзләре хакында?..

## КУРЧАК ТЕАТРЫНДА

Биредә
курчаклар нәкъ кешеләр инде:
        берәүләре — явыз, икейөзле,
        берәүләре — кешелекле, изге.

Баксаң —
        үзләре җансыз бер җисем,
        сабыйларның юанычы бары.

Ләкин
курчаклар булып та
        кешеләр уйный шул,
        кешеләр уйлый...

## АВТОПОРТРЕТ

Минем хакта хак булганны
Сөйләмәсеннәр бозып.
Мин — мәзәк шикелле кыска,
Әкият кебек озын...

# СӘЕР КЕШЕГӘ
# ИХЛАСТАН ЯЗЫЛГАН МӘРСИЯ

Гомер буе кешеләрдән көлде.
«Гавам» диеп көлде, бармак төртеп.
Безнең ише сары томшыкларны
Тормады ул хәтта чутка кертеп.

Гомер буе шигырь калыплады.
Хәмер эчте. Дон-Жуанлык итте.
Мәҗлесләрдә аек сүзләр сөйләп,
Күпме иза, күпме газап чикте.

Гомер буе дәрвиш булып йөрде.
Ыспай түгел иде килбәте дә.
Акча-малга кызыкмады...
Тәки
Төшенмәде яшәү рәтенә.

Яклаучысыз гомер кичте, бахыр,
Ә дуслары болай күп иде дә...
Китүе дә булды сәер генә:
Күңелендә яман чир, диделәр...

# ЮЛ ЧАТЫНДАГЫ КИБЕТ

...Бу кибеттә чиратлар юк.
Теләсә кем сатучы
йә сатылучы бу кибеттә.

Витриналарда — манекеннар түгел,
көяз кызлар тора ымсындырып;
үтә күренмәле күлмәкләре
биһуш итә һәрбер узгынчыны.

Үтә күренмәле узгынчылар
сер алырга керә бу кибеткә,
телсезләр тел сатырга килә,
шигырьчеләр — илһам...

Акылсызлар акыл сата монда,
акыллылар — акылсызлык...

Алдакчылар хаклык белән сәүдә итә,
сугымчылар гомер сата ваклап-ваклап.

(Бу кибеттә
тауарларның төгәл хак-бәясен
тик риясыз яшәгәннәр белә.)

Бу кибеттә
бәхет кошының
итен
саталар —
әшнәләргә генә...

## ТАЛЧУК

Азык эзлим, имеш, мин дә язарыма —
йөрим гүя дөнья базарында.

Кемнәр генә,
ниләр генә юк биредә!

Үз-үзеннән кыйммәт хакка
кайсы әнә чүәк сата,
кайсы әнә күлмәк сата,
кайсы әнә гайбәт сата —
үзен сата
үз-үзеннән кыйммәт хакка.

Мәгънәсез сатулашу-гаугалардан,
оятсыз каргану-сүгенүләрдән,
чибәр кызларга әйтелгән
очсыз комплиментлардан
саранча күчедәй гөжли башым.

...Кинәт базар телсез-өнсез калды —
Димәк, базар шаккатыргыч хәбәр алды:
— Бәхет сатам! Бәхет сатам
үз иясенә!
— Бәхет сатам! — диде бер карт, —
үз бәясенә!

(Кулына тутык дага тоткан
бөкре бер карт иде ул,
бөкре бер карт иде...)

Шулчак
«Адидас» сатып торучылар да,
тиен санаучы алкашлар да,

көяз урам кызлары да
дәррәү ябырылды картка —
бастылар чиратка.

...Ә бүген, төн уртасында,
йокы аралаш, пышылдап:
— Мин бәхетле, — диде ярым.

Сискәнеп киттем.

## МИН РИЗА

Һәр гашыйк кавыша алса —
шыксыз төн булырга да;

Һәр кеше көләч яшәсә —
бәхетсез булырга да;

Ил-халыклар туганлашса —
...сәясәт булырга да
мин риза.

## ЧИРАТ

Чират тора кешеләр
машинага, дачага,
билетка йә акчага.
Фатирга чират тора,
маникюрга, сырага.
Кемнәр әдәп саклый,
ә кем
чиратсыз гына ала.

Кешеләр чират тора,
бәхеткә чират тора,
тәхеткә чират тора,
җәннәткә чират тора...

Олы Хәтер җанында
яд ителеп калырга,
киләчәккә барырга,
гаугалашып, даулашып,
язмышлар чират тора,
язмышлар чират тора.

# БОРЫНГЫ ШӘҺӘРДӘ ЯЗ

Кошлар кайта — сизмибез дә,
Бозлар китә — юк яме.
Кайда монда умырзая,
Кайда гөрләвекләре?

Күңелдәме гөрләвекләр —
Ымсынган, алгысынган?..
Күккә ашкан манаралар
Яфрак ярыр сыман.

Күңелдәме умырзая —
Шагыйрьләр кебек туңган?..
Соры чиркәү түбәсенә
Кара каргалар кунган.

# АТОМ-КИРМӘН

*Поэма*

## I

Кама Аланында — котлованнар,
Өем-өем туфрак-катламнар...
Җылы кирәк илгә!
Якты кирәк! —
Баш очында Кояш та, димәк!

Атомны да тәртә арасына
Кертә халык —
тормый аптырап.

Җылы кирәк илгә,
Якты кирәк —
Җылы булсын еллар, яктырак.

Җылы булсын еллар —
димәк, җырлы!
Халкым минем борын-борыннан
Икмәксез дә хикмәт эзләгән гел —
Икмәк тәме килә моңыннан.

Якты булсын еллар,
димәк, хаклы!
Хаксызлыкны халкым күп күргән.
Ничә кабат сиратларны кичкән
Галиләре салган күпердән.

Идегәе булып Идел кичкән,
Тукай булып туңган илендә.
Һәм Туфаны булып Себер киткән,
Ил язмышын салып иңенә.

Якты булсын еллар!
Якты җырлар
Җырлый-җырлый язсын яшәргә.
Ил күгендә Хаклык уты сүнсә,
Әверелә Яшәү мәхшәргә.

Якты булсын еллар!
Әле анда,
Әле монда — канлы вакыйга...
Ил күгендә Ирек уты сүнсә,
Әверелә тиран «даһи»га.

Якты булсын еллар!
Хаклык утын
Тарих үзе биргән халкыма.
Без яшибез бүген —
Күңелара
Бөек аңлашулар хакына.

Якты булсын еллар!
Караларын
Газиз халкым, юк, онытмады...
Ә ник әле Атом-кирмән төзи
Алып оныклары?!

## II

Җир тарихы... Җир дә тора
Тарихи катламнардан...
Легендага күчеп яши
Монда таш кантарлар да.

Легендага күчеп яши
Кашаны, Биләрләре...
Хәрабәләр ханлыгы бу —
Болгар биләмәләре.

Әнә Сувар... Ага-Базар...
Ташлардан гыйбрәт алыйк.
Монда — китапларга түгел,
Ташка басылган тарих.

Әнә Нөкрәт... Шайтан кала... —
Юлыккан ни казага?
Ташка әверелгән монда
Чуен койган казан да.

Ташка әверелгән монда
Яшәеш тә, үлем дә...

Экскаватор кулы әнә
Тарихыма үрелә.

Замананың тимер кулы
Тарихымны актара.
Чын тарихны актарсаң да,
Язык түгел — аклана.

Җир тарихы... Катлам-катлам
Тарихыма сөялеп,
Торам менә...
Кулларымда —
Бабамның баш сөяге.

## III

Җир әйләнә,
кошлар оча иде —
Җырдагыча! —
заман тизлегендә!..
Баш сөяге телгә килде кинәт:
— Ни күмдегез кирмән нигезенә?

Баш сөяге телгә килде кинәт,
Телгә килде гүя телсез тарих:

— Кирмән ватып күңел ачты җирдә
Күпме башкисәр җан, күпме кабих.

Мәйданнарда изге китап ягып,
Мәгърифәтче булды күпме тинтәк.
Оныклары аннан тарих язды,
Үзләренчә сипләп.

Һәм туктаусыз тукыдылар башка:
— Уйлау — язык, өйрән уйламаска!
Хөкем ителәчәк һәр уй, ният!
Ни кылса да безләр — тәрәккыят!

Тукыдылар башка:
— Уйламаска!
Ачы шәраб акты мичкәләрдән.
Әмер булды кабат:
— Айнымаска!
Тәгәрәде уйлар кискәләрдән —
Мәңгелеккә лаек,
аек уйлар!..

Ачы язмыш, каргыш махмырыннан
Мәмләкәтләр язды һушларыннан.
...Бу тарихта кайчак халыклар да
Әверелде халык дошманына.

...Җир әйләнә,
кошлар оча иде —
Җырдагыча! —
заман тизлегендә!
Баш сөяге телгә килде кинәт:
— Ни күмдегез кирмән нигезенә?

Баш сөяге телгә килде кинәт:
— Ни күмсәгез — шуны табачаксыз.
Эт күммәгез берүк —
Эт көненә
Үзегез дә беркөн калачаксыз.

Кардәшләрем минем, эргәдәшләр,
Нык берексен җиргә тамырыгыз.
Нык берексен! —
Кирмән нигезенә
Якты өмет салып калдырыгыз.

Җирдә якты җиңә барган саен,
Арта барыр илдә кадерегез.
Кардәшләрем!
Кирмән нигезенә
Гүзәл гамьнәр салып калдырыгыз.

Тармакланып,
        нык берексен җиргә
Рухи тамырыгыз.

## IV

Экскаватор кулы гүя
Хәтеремне соса.
...Шайтан кала эргәсендә
Чуен койган Оста.

Әйткән хаким: «Бу калага
Узалмасын кош та».
Мәшригында, мәгърибендә
Ул бердәнбер Оста.

Эңгер төшсә, күкне иңләп,
Каракошлар оча.
Оста кирәк һәр хакимгә —
Шул бердәнбер Оста.

Оста аулау хакимнәрнең
Биләп алган уен.
...Ядрә булып кирмән ваткан
Төрән булыр чуен.

Бөек Сердән легенда һәм...
Кисәү калган бары...
Шайтан кала эргәсендә —
Шайтан таяклары...

* * *

— Кайда гына орлык сибеп,
Үсмибез кайда гына.
Шуңамы әллә кадер юк
Без — шайтан таягына.

Үзебезчә без дә чәчәк,
Без дә җиргә береккән.
Тарих безне «татарник» дип
Атый элек-электән.

Үзебезчә без дә чәчәк.
Яшәрәбез. Сулабыз.
Җилләр кыйный, силләр кыйный —
Чәнечкеле шуңа без.

Гөл-чәчәкләр ыруында
Үзгә чәчәк, үзгә без.
Җилләр кыйный, силләр кыйный,
Ә без — сабыр. Түзәбез.

... Кайда гына шытсак та без,
Үссәк тә кайда гына,
Чәчкәләр, дип эндәшегез
Без — шайтан таягына.

Үзебезчә без дә чәчәк.
Күзләр җитсә, сулабыз.
Хаҗи-Морат карашыдай
Кырыс, уйчан шуңа без.

V

...Ә ул көнне илдә бәйрәм иде.
Вәйран җанны ефәк-укага
Төрми генә шигырь укыдык без
Ирек мәйданында — Тукайга.

Ә ул көнне Тукай 100дә иде, —
Кем бозарга базсын бәйрәмне?!
Дөнья читлекләрен тарсынган Кош
Үз янына безне әйдәде.

Дөнья читлекләрен тарсынган Кош
Очып йөрде Апрель күгендә.
Заманалар кыршау кидергәндә
Һәрбер кошка, һәрбер күңелгә,

Ярсып-ярсып шигырь укыдык без,
Ә кемнәрдер, беләм, тукынды —
Җыр өстеннән донос юллады
һәм
Тәре үбеп ясин укыды.

...Ә ул көнне илдә хәвеф булган.
Дөнья черем иткән арада,
Кыршауларын, тышауларын өзеп,
Шашкан АТом качкан араннан.

Ирек мәйданында ирек даулап,
Тышауланган халык-илләргә,
Репрессияләнгән дастаннарга,
Идегәйдәй алып ирләргә —

Телгә килгән чакта ирексезлек,
Шашкан АТом качкан ирекка.
Ут-яллары күкне өтәләгән,
Тояклары җирне эреткән.

Сабыйлардай,
        мич артына кереп,
Яшеренгән сыман яшеннән,
Поскан Вакыт үлән арасына —
Баш сөяге Көннең яньчелгән.

Типкән АТом, кушаяклап типкән, —
Җиргә иңгән Тәңре, Алласы...
Припятьтә кармак салган картның
Күккә сеңеп калган карашы.

Кыйтгаларга барып ишетелгән
Кара АТның кешнәп көлгәне.
Припятьтә кер чайкаган кызның
Диңгезләргә аккан керләре.

Припятьтә кер чайкаган кызның
Көмеш сулар юган эзләрен.
Көмеш суда йөзгеч-канат булып
Бәргәләнгән көмеш тезләре.

...Ә ул көнне илдә бәйрәм иде,
Кем бозарга базсын бәйрәмне?!
Дөнья читлекләрен тарсынган Кош
Үз янына безне әйдәде.

## VI

...Стенамда — «Помпейның соңгы көне».
Тереклекнең һәлакәтеннән бер мизгел...

Бөек рәссам рухы безне
соңгы кабат кисәтә күк...
Ә үлем лабораторияләрендә кеше үтерүнең
яңарак, камилрәк
ысуллары өйрәнелә...

...Җир, мәҗрух җанвар сыман,
ыңгырашып куйды.
Кояш, куркып, сискәнепме,
яктылыгын җуя барды,
җуя барды... җуйды...

Чал кыялар телгә килде:
— Без — яралы.
Гөл-агачлар пышылдашты:
— Без — янабыз.
Киек кошлар һава ярды:
— Кая очыйк?
Сак җәнлекләр аваз салды:
— Кая посыйк?

Җир дәшмәде...
Ә кешеләр, аквариумда
бәргәләнгән балыклар күк,
һәммәсен дә сизеп торды,
белеп торды,
күреп торды...

* * *

P.S. АЭСның беренче реактор котлованын казыганда, экскаватор чүмече полеозой казналыгыннан мамонтның казык тешен суырып чыгара. Табылдык хәзер музейда саклана...

## VII

... Еллар шәмдәлендә — шәмнәр,
        шәмнәр...
Сүнә... берәм-берәм.
Үлчи Вакыт
        кылган гамәлеңне
Бишьеллыклар белән.

Минем чорым —
        бишьеллыклар чоры,
Мин шул чорда туган.
Әмма минем үз бишьеллыгым ул,
Үземнеке, туган.

Минем бишьеллыкта
        милли керем
Үлчәнә Тел белән. —
Әрәмтамак булып җан асрый
Ваз кичкән теленнән.

Минем бишьеллыкта
        прораб — Иман! —
Өмет, җыры барга
Сметада акча каралмаган
Хәрби чыгымнарга.

Минем бишьеллыкта —
        тик тел-лөгать,
Җыр алмаша илләр.

Тарих өсләп өмет җыры оча,
Киләчәкне иңләп.

...Хатын-кызлар таңда бәби таба,
Иген игә ирләр.

* * *

Мин каладан кайткан кеше —
Имештер, күбрәк беләм —
Дөнья хәлләрен сораша
Карт-коры, күрше-күлән.

Кала җирендә, янәсе,
Йөрмиме халык эчеп?
Әфганстанда ниләр бар,
Ливанда хәлләр ничек?

Белгәнемне әйткән булам,
Юк ич яшерен сере.
Сорап куя шулчак берсе:
— Ат җигә беләсеңме?

Ат җигә белергә тиеш
Һәркем! —
Син шуны аңла!
Әнә Лев Толстой күк карттан
Гыйбрәт алсын замана.

Алар — атлы, алар — хаклы,
Җирдә тереклек барда.
Сез аларга сүз бирегез
Сенат, парламентларда.

Алар — атлы... Алар — хаклы —
Якты, димәк, киләчәк.
Хет президентка да алар
Шул сорауны бирәчәк:
— Ат җигә беләсеңме?
— Ат җигә беләсеңме?

## АТЛАР

*Төнге хатирә*

Без дә атлар саклап үстек
Балачак яланында.
Булмагандыр ул чагында
Җанның бер ямавы да.

Карт Буян пошкырса да, без
Кушылып көлә идек.
Ай күзеннән яшереп кенә
Тәмәке төрә идек.

Атлар саклап үстек.
Шуңа
Бераз ат холкы бездә.
Кашканың уйчан карашын
Сеңдергән күзебездә

Булса гамь, мәрхәмәт нуры,
Бурычлы без атка да...
Нәни улым Чыңгыз, әнә,
Агач атка атлана.

## КАРТ СӘГАТЬ

Мизгелләрне саный-саный
Тузган, искергән сәгать.
Ник туктамый, ник хәл алмый —
Туктарга бар ич сәбәп.

Йөрмәс иде, туктар иде —
Карт кызганыч, карт жәл шул.
Вакытсыз калса,
Өендә
Берьялгызы нишләр ул?!

## КАЗАН. ЧЕРЕК КҮЛ БУЕНДА

...Балыкчылар кармак салмый монда,
Төнбоеклар ачмый кочагын.
Казан инде хәтерләмидер дә
Күлнең сихри, көләч, сау чагын.

Күк читенә яңа Ай элengән.
Тып-тын. Гүя кабер тынлыгы.
Шундый чакта онытыла хәтта
Гомер дигән тормыш чынлыгы.

Тып-тын шәһәр. Эт тә өрми никтер,
Шакучы юк ишек-капканы.
Чү!.. Ерактан әнә тонык кына
Ишетелә ал таң атканы.

## МОҢСУ ШАТЛЫК

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Сусау-назларны басып.
Җибәрик әле күңелнең
Тәрәзәләрен ачып.

Коенсын аклык-пакьлеккә
Гөл йөрәк, әрем җан да...
...Күз явын алып, бер мизгел
Күктә яшен-ут яна.

Күк гөмбәзен яра-яра
Аннан Җиргә тоташа.
Ярсыган аю шикелле,
Болытлар ыңгыраша.

## КӨЗГӘ МӘДХИЯ

Әбиләр чуагы җитте,
Гүзәл җәем, карышма...
Туган җирнең алтын көзен
Алтынга да алышмам.

Көз — фикерләр өлгергән чак,
Уйчан, моңсу, сагышлы.
Көзге кичтә тоябыз без
Гомерләрнең агышын.

Кыр казларының чылбыры
Ул — шигъри сурәт кенә.
...Югалту, сагыш ачысын —
Татыган йөрәк белә.

Кемдер, бәлки, каеннарның
Сөймидер шәрәлеген.
Аңламас бер җан ул, димәк,
Сер, илаһилык телен.

Көз кебек гамьле булырга
Кирәктер әле безгә.
...Әнә күктә торналар да
Рәхмәт укыйлар көзгә.

## КАЙТУ

Туган йортка кайтып киләм.
Кыр капкадан керү белән,
чабуыма әнчек этләр сикерә,
үрсәләнеп,
казлар тайпыла читкә,
урамымның тупыллары
ятсына хәтта.

Юлда очрап,
исәнлек алышкан картлар
сынап кына сорый хәзер:
— Кем оланы?
— Кунаккамы?

Өнсез калам.

...Һәм нигезем телгә килә:
— Миңа сыен,
миңа сыен,
балам...

## МИНСЕЗ ГЕНӘ...

Яши-яши шактый атынылган,
Күккә элеп бишек, таганны.
Үтеп киткән гомер минсез генә,
Ә мин сабый килеш калганмын.

# ЧИЧӘННӘР КАЙТАВАЗЫН КЕМНӘР КӨЧӘЙТӘ

Күктән иңгән кебек тоелучы талант ияләре дә гадәти үсеш баскычы буйлап күтәрелергә мәҗбүр. Дәвамчанлык күренешенә бәйле мондый заруriят, әлбәттә, теләсә кайсы сәнгать төренә кагыла. Шул исәптән шигърияткә дә. Шуңа күрә элгәрләре тәэсиренә бирелмәгән шагыйрь чынлыкта бөтенләй була алмыйдыр. Ә йогынты көче зурайган саен, шигърият үзе дә олпатлана бара. Бу җәһәттән безгә шөкрана кылырга кирәк: алыс гасырлардан ук килгән затлы әдәбиятыбызның кабатланмас мирасханәсе япь-яшь дәвамчылар үрнәк алырлык язу рәвешләренә аеруча бай.

Әле чагыштырмача яшьрәк буын вәкилләреннән саналган Газинур Моратның иҗатын тулаем күзаллаганнан соң, мин аерым күренекле шагыйрьләребез барлыкка китергән тел-өслүп мәктәпләрен берәм-берәм хәтер аша үткәрдем. Төрлелеккә исең китәрлек! Нәкъ менә шундый яхшы нигездәге күпьяклылык шигъриятебезнең гомуми культура дәрәҗәсен билгели дә инде. Табигый ки, алма агачыннан ерак төшмәгән кебек, Газинур да традицияләребез җирлегендә калган. Әмма теге яки бу йогынтыга бирелгән очракта да ул остазлары алдында таләпчән шәкертлек холкын күрсәтә алган, һәрхәлдә, минем үземә шулай тоела.

Чын шигърияткә тугры хезмәт итүнең мәҗбүри үтәлергә тиешле шартлары бар. Шуларның берсе, әлбәттә, яңалыкка омтылу. Гәрчә беренче карашка гади булып күренсә дә, бу фаразлык әле үзе дә байтак таләпләр куя. Әмма иҗатта яңалыкка ирешү барыбер үз сүзеңне әйтүгә, бихисап кайтавазлар илендә үз тавышыңны яңгыратуга кайтып каладыр. Яхшы хәтерлим, сиксәненче еллар башында әдәбият мәйданына ныклап аяк баскан Газинур Морат кулга шагыйрьлек каләмен алу җаваплылыгын тирәнтен аңлар дәрәҗәдә әзерлекле иде. Иҗат яшьләрендә сирәк очрый торган мондый өлгергәнлек аның беренче җыентыгында да шактый ачык тоемлана («Җир хәтере». Татарстан китап нәшрияты, 1985). Шигырьне ритмик сүз тезмәсе итеп кенә аңлаучы беркат-

лылар биредә үзләренең ялгыш күзаллавын аклардай мисаллар таба алмастыр. Нык кул белән язылган әсәрләрдән үзенчәлекле шагыйранә рух бөркелеп тора. Киң фикри офыкларны колачлаган, тирәнлек түренә юнәлтелгән рух... Менә шундый рух иҗатчыга тормыш күренешләрен эчтән яктыртып күрсәтергә, хисапсыз яшәеш хикмәтләренең асыл үзәгенә үтеп керергә ярдәм итә. Тылсым көченә ия шушы рух белән ул предметның табигатендәге матурлыкны эзләп таба. (Матурлыкны үзе уйлап чыгармый.) Шагыйрьнең дөнья белән мөнәсәбәте исә үзара ышанулы ихласлык нигезенә корылган: «Җиһандагы һәрбер җисем — җанлымы ул, әллә җансызмы — кызып сөйли миңа эч серләрен, шатлыкларын, дәгъва-таләпләрен...»

Беркадәр яшьләрчә хиссият белән белдерелсә дә, бу сүзләрдә шагыйрьнең холык-фигыле дә чалымлана. Чыннан да, Газинур Моратның шигырьләре шәхси уй-хисләрне белдергән монологлар кимәлендә түгел, киресенчә, җанлы әңгәмәдәш белән ихлас ачылып сөйләшү рәвешендә кабул ителә. «Аңлашырбыз гүзәллек һәм язмышлар теле аша» кебек искәртүдә исә сөйләшүнең шактый катлаулы темалар турында баруына ишарә ясала. Шигырьләр бер-берсен тулыландыра. Иҗат тәҗрибәсе отыры баеган саен, шигъри характер даимилек ала бара. Шул ук вакытта шагыйрь элгәрләр рухына тугрылыгын, уй-гамьнәренең җитдилеген дә үзенчә тикшергәләп куя кебек:

Чәчән бабайларның кайтавазы
Яңгырыймы бүген безнең җанда?..
*(«Җир хәтере»)*

Әдәбият белеме классиклары бердәм рәвештә искәрткәнчә, фикер ягыннан үсеш кичермәүче шагыйрьнең иҗаты тулаем зур әһәмияткә ия була алмый. Дөрестән дә, әгәр каләм әһеле образлар белән эш итә икән, ул шушы образлар аша ниндидер фикер үткәрергә тиеш. Элек-электән халык мәхәббәтен казанган шагыйрьне тикмәгә генә акыл иясенә тиңләмәгәннәрдер. Вәләкин мондый биеклеккә күтәрелү өчен

гаять мөһим шартларны үтәргә кирәк: бер үк вакытта тирән итеп фикер йөртү, һәрчак ташырга торган хисләреңбелән оста идарә итү һәм шуларны үз шигыреңдә мөкәммәл дәрәҗәдә гәүдәләндерү, ягъни бердәй югарылыктагы акыл, күңел һәм зәвыкка ия булу. Асылда, һәрбер иҗатның сәнгатьчә камиллек дәрәҗәсен менә шундый гармониялелек билгели дә инде. Аерым башлангычка чама белән өстенлек бирү исә соңгы исәптә язу рәвешләрен яхшы төрлелеккә китерәдер.

Әсәрләренең табигатеннән күренгәнчә, шигъри иҗатның мондый серләрен Газинур Морат эчке сиземләү белән аңлый. Хәер, акыл, күңел һәм зәвык берлегенә ирешү аның талантына ук салынгандыр кебек тоела. Өстәвенә җитмешенче еллар көндәлек матбугатында барган кайнар бәхәсләр дә әдәбиятка килергә карар кылган егеткә йогынты ясамыйча калмагандыр. Хәтерлисездер, шигъри фикер белән хискә карата төрле карашлар булу каләм ияләрен үзеннән-үзе зур сөйләшүгә тартып кертте. Дөресен әйткәндә, мондый бәхәс өчен җирлек тә бар иде. Эчтәлек һәм шәкел мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендәге эзләнүләрнең көчәюе, аерым алганда, фикергә беркадәр микъдарда өстенлек бирелгән шигырьләрнең күбәюенә китерде. Ә уйның хистән ераклашуы шигърриятлелек билгесе була алмый... Ерак чорлар үрнәге — әле бер хәл. Замандаш шагыйрьләр йогынтысы чагыштырмача көчлерәк булучан. Фикер ягына ныграк басым ясалган әсәрләр, әлбәттә, Газинур Моратның башлангыч иҗатында да очраштыра. Әнә бит кайбер очракта ул үзе дә икеләнеп калган: «Акылгамы әллә күбрәк Биреп куйдым вәкаләт?..» Үзеннән-үзе «акыллылык»ка авышучан ирекле шигырьдә дә көчен сынап карый яшь шагыйрь. Әмма аның мондый шәкелгә күңеле никтер ятып бетмәгән — беренче китабында урын алган «ак шигырь»ләр биш-алтыдан артмый. Аннан соң чыгып килгән яңа җыентыкларында да мондый тәҗрибә үрнәкләре күзгә бәрелеп тормый. Үзенең шагыйрьлек вөҗүде өчен ул гадәти өслүпне кулайрак күрә. Серле шигърриятнең табигый асылына тәңгәлрәк кил-

гән, гасырлар буена камилләшкән, бинихая мөмкинлеге булган классик алымны сайлый. Әмма шигъри сүзнең ирекле яшәешенә, каләменең хөрлегенә барыбер тугры кала.

Иҗатка интеллектуаль әзерлек белән килгән каләм иясе үзеннән өлкәнрәк шагыйрьләрнең язганына таләпчәнрәк карарга тиештер. Сер түгел, әдәби хәрәкәтне җанландырып җибәргән көчле буынның да уңышлары артында тырпаеп торган җитешсезлекләре була. Минемчә, Газинур Морат йогынтылы элгәрләренең әнә шундый «зәгыйфь яклар»ын вакытында күрә алды һәм аларның ялгышларын мөмкин кадәр кабатламаска омтылган хәлдә, үзенчә язу рәвешен булдырды. Шагыйрьнең лирасы шактый нәзакәтле. Моның сере нидә? Бу хакта минем озак уйланганым бар. Фаразлавымча, әлеге дә баягы «фикер, хис һәм зәвык» формуласындагы гармонияне саклап, ул күпләргә җитенкерәмәгән тел камиллегенә ныграк игътибар бирәдер кебек тоела. Үзенең шагыйрьлек холкын билгеләүче төп үзенчәлекләрдән саналган бу хасиятне Газинур Морат «Каударланма, каләм...» исемле шигырендә дә сиздереп куя.

Дөньяныкы дөньялыкта кала,
Каударланма, каләм, кабаланма;
Кадерен бел Сүзнең...
Болай да бит
Гомеркәйләр — тоташ каралама.

Кызганыч, язганнарын югары сәнгать таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәгә җиткермичә, ягъни каралама хәлендә укучыларга тәкъдим итүчеләр хәттин ашкан. Бу заманда бигрәк тә... Ә бит күпме генә бәхәс кылсак та, һәрбер каләм әһеленең иҗаты ахыр чиктә шәхси стиль белән билгеләнә. Ә стиль үзе барыннан да элек телгә барып тоташа, һәм әдәби иҗат техникасы да, нигездә, тел өйрәнүгә кайтып кала. Бездә «тел-өслүп»нең парлы сүз рәвешендә язылуы да нәкъ менә шушы хакыйкатьне раслый булса кирәк. «Шагыйрь бул син, әйдә, шагыйрь бул син, Гөл-чәчәктән сүзләр үрсәнә» дип, яшьли үз-үзенә эндәшкән Газинур Морат, әлбәттә, кирәкле сүзнең кирәкле урында торуыннан гына яхшы стиль бар-

лыкка килүенә беренче шигырьләрен язган чакта ук төшенгәндер. Бүген аның чын мәгънәсендә тел остасы булуын яшьтәшләре белән бергә өлкән каләмдәшләре дә таный. Шагыйрьнең стилистлык сәләте күптөрле мәкаләләрендә дә, чәчмә белән язылган юмор-сатира әсәрләрендә дә, шулай ук мөхәррирлек эшчәнлегендә дә ачык күренә... Без инде беләбез, турыдан-туры сүз белән эш итүчеләргә, бигрәк тә шагыйрьләргә, барысыннан да өстен бурыч йөкләнгән: телне яшәтүнең иң югары формасы булган сәнгатькә үзеңнең бөтен осталыгыңны багышлап, тугры хезмәт итү. Ә Газинур Моратка килгәндә, безгә бик кирәкле мөкатдәс бурыч, минемчә, аның шагыйрьлек тәкъдиренә үк язып куелган.

Нәкъ менә күп катмарлы тел җәһәтеннән чыгып караганда, шагыйрьнең стиле кайсы яклары белән аерылып тора соң? Беренче чиратта аның шактый ачык, ягъни аңлаешлы булуы күзгә ташлана. «Иң яхшы тәртиптәге иң яхшы сүзләр...» Аеруча әйбәт шигырьләрне укыган чакта, менә шушы билгеләмә хәтергә килә. Сизелә ки, Газинур Морат әдәби телебезнең чиксез зур байлыгыннан оста файдалана, нигәдер онытыла төшкән аңлаешлы матур сүзләребезне дә уңышлы куллана. Әйтик, «вөҗүд», «ырыс», «иләт», «тияк», «батман» кебек сүзләр шигырь тукымасында бөтенләй яңа яктан ачылып китә. Аның «сынчыбагар» (натурщик) неологизмын уйлап чыгаруы да тел хәзинәбезне баету теләгеннән киләдер дип уйлыйм. Шагыйрь аерым сүз-бизәкләргә басым ясаган чакта, сүз һәм мәгънә гармониясенә ирешергә омтыла. Моның өчен әүвәл төгәл сүзләр сайлый. Заманында татар әдәбиятына остазлык кылган Максим Горький үзенең бер чыгышында хаклы рәвештә искәртеп үткәнчә, телнең чын мәгънәсендәге матурлыгы сүзләрнең төгәл, ачык, яңгыравык булуы белән тудырыла. Ә сүзнең төгәллеге стиль яисә югары зәвык таләбе генә түгел, иң беренче чиратта мәгънә таләбеннән килеп чыга торган зарурият ул. Сүзләрнең төгәллеге исә, табигый рәвештә, тыгыз кыскалыкка китерә. Гомумән, фикри-хисси тыгызлыктан башка сәнгатьлелек була алмыйдыр. Әгәр тирәнлеге чамалы икән, шигырь дә озын-

га сузыла. Иҗатында тыгызлык принцибына тугры булуын Газинур Морат үзе дә яшерми:

Озын сүзнең кыскасы шул
(Хаклыгына юк шигем):
Кысалар кысылган саен,
Кыскара бара шигырь...

*(«Кыска шигырь турында»)*

Шигъри әсәрләрнең һәрбер төрендә дә шагыйрь азсүзлелекне кулайрак күрә. Аның балладаларына да җыйнаклык хас. Хәтта асылы буенча киң фикри офыкларны колачларга чакырган поэма жанрында да Газинур Морат эчтәлекне концентрацияләү юлы белән мөмкин кадәр кыскалыкка ирешә. Мәсәлән, төрле елларда язылган «Лонг-Кеш» (1981), «Җир хәтере» (1982), «Түбә» (1986), «Атом-кирмән» (1988), «Ачлык» (1991) исемле поэмаларда да шагыйрьнең тотнаклы тел-өслүбе үзенә нигез итеп алган кагыйдәләргә барыбер тугры булып кала. Тыгызлыкка ирешүнең, сүз дә юк, серләре байтактыр. Бу уңайдан игътибар иткәнем бар: Газинур Морат кайвакыт фигыльләрне сирәгрәк файдалана, эпитетлар тезеп китү белән мавыкмый; ул исемнәрне яратарак төшә, предмет яки күренешнең исеме аның өчен мөһимрәк санала. Ә шигърияттә мондый алым кечерәк формаларны таләп итә.

Горурлыгым. Мескенлегем.
Таянычым. Абынуым.
Тугрылыгым. Хыянәтем.
Ихтыярым. Табынуым...

*(«Син»)*

Соңгы елларда Газинур Морат үтемле кыска шигырьнең дә чын остасына әверелде, җыйнаклыкка ятышып торган тел-өслүбен туктаусыз камилләштереп, безнең шигърияттә элек-электән яшәп килүче мондый форманың мөмкинлекләрен тагын да киңәйтте. Аның язганнары һәрбер гамьле күңелне дулкынландыра алырлык яңа хакыйкати катламнарны ачуы белән генә түгел, сүзне илаһият бүләге рәве-

шендә кабул иткән шагыйрьнең үзенчәлекле шигъри синтаксисы ягыннан да аерылып тора. Һәммә сүзнең үз аһәңе, үз авырлыгы, үз тәме, үз йөкләнеше булуын сизәсең. Гомумән, кече шигъри кишәрлектәге һәрбер сүз бар яктан да үтәли күренүчән. Менә шундый чакта инде мәгълүм мәкалебез искә төшә: сүз эчендә энҗе бар... Ә Газинур Моратның берничә юллы шигырьләрендә энҗесе күренеп торган сүзләр аеруча күп. Әлбәттә, мондый форманы кыскалык белән чикләү аның шартлы аталышыннан гына киләдер. Гәрчә хикмәтле дүртьюллыкларда сүзләр тәгаен санаулы булса да, аларның тирәнлеген үлчәрлек бернинди берәмлек тә юктыр. Сүз сөйләүдә аңа кыска булырга боерылганын шагыйрь «Автопортрет»ында үзе дә сиздереп куя: «Минем хакта хак булганны Сөйләмәсеннәр бозып; Мин — мәзәк шикелле кыска, Әкият кебек озын...»

Әгәр Газинур Морат үз иҗатында азмы-күпме һөнәри осталыкка ирешкән икән, әйе, ул шагыйрьнең тел-өслүп кебек әһәмиятле мәсьәләгә таләпчән мөнәсәбәттә торуыннан да килә. Буыннар арасындагы дәвамчанлык кабатланудан гына тормый. Белгәнебезчә, алтмышынчы еллар башында әдәбиятка яшен уйнатып килгән Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташлар буыны, һичшиксез, гадәти бертөрлелектән күпмедер тынчуланып калган шигъриятебезне тел-өслүп һәм эчтәлекшәкел ягыннан яшьләрчә кайнарлык белән беркадәр сафландырып җибәрүгә ирештеләр. Мондый фактны инде кире кагып булмый. Әмма шунысын да таныргa кирәк: аларның аеруча ирекле шигырь өлкәсендәге кайбер эзләнүләре модага иярүчән графоманнарның артуына да сәбәпче булды. Классик шигырь үрнәгенең асыл үзәген ватып-җимерүләргә гаммәви «шигырь язу бумы» килеп ялганды. Хәтта профессиональ иҗат оешмасында торган каләм ияләре дә гапгади поэтика кануннарына карата талымсызлык күрсәтә башлады. Ритмга игътибар кимеде. Алама рифмаларның үрчүе тезмәнең тәмен җибәрде. Шигырьнең әүвәлге юлларын бер үлчәмдә башлап, аннары икенче төрле иҗек санына

күчеп, өченче үлчәмдә төгәлләү гадәти күренешкә әйләнде. Абруйлы басмаларда дөнья күргән байтак шигъри әсәрләр тәҗрибәле мөхәррирнең баштанаяк камиллек дәрәҗәсенә җиткерүенә мохтаҗ. Сүз сәнгатенең иң мәһабәт формасы булган шигырьне күрәләтә ниндидер коры карикатурага авыштыра баручылар бермә-бер ишәйде. Кыскасы, шигърият бакчасы пычранды. Бүгенге көндә «шигърият экологиясе» мәсьәләсе бөтен җитдилеге белән көн тәртибенә басты. Менә шундый шартларда яшьрәк буын шагыйре Газинур Моратның үзен чолгап алган әдәби мохиткә тәнкыйди күзлектән каравы, камиллеккә ирешкән тел-өслүбенә һәрвакыт тугры калып, татар шигърияте чисталыгы сагында торуы аның тигез агышлы тирән иҗатына янә бер әһәмиятле кыйммәт өсти.

Чыннан да, фикри сайлыкта утыручы шагыйрьләрнең иҗаты зур әһәмияткә дәгъва кыла алмый. Әгәр Газинур Морат үзенең шигъриятендә ниндидер дәрәҗәдәге фикер иясе булуга ирешкән икән, аның әлеге казанышында «сүз төгәллеге — тел — стиль — мәгънә» кагыйдәсеннән читләшмәве дә чагылыш таба. Шагыйрь әсәрләре аша үткәрелгән образлы фикер күпчелек очракта милләт гаменә килеп тоташа. Аллаһ тарафыннан ирекле итеп яралтылган газиз кавеменең хәләл хакын даулау уе аның сабыр даимилеге белән аерылып торган шагыйрьлек холкына ук салынган кебек. Йөрәк типкән саен сулкылдап алган әлеге мөкатдәс гамь Газинур Моратның шигъри басмаларында гына түгел, «Җәяүле кошлар» исемле мәкаләләр җыентыгында да (Татарстан китап нәшрияты, 2002), хәтта балаларга атап чыгарылган китапларында да («Әкияткә ышанмаучы малай». «Мәгариф» нәшрияты, 2003 һ.б.) әледән-әле саркып чыга. Милләт язмышы турында борчылуын белдерү өчен, һичшиксез, шагыйрь акыл-рух культурасы ягыннан шактый әзерлекле. Безнең әдәбиятта уңышка ирешергә теләгән шагыйрь күпмедер дәрәҗәдә тарихчы да булырга тиеш. Бу җәһәттән Газинур Морат, Ркаил Зәйдуллалар буыны, шөкер, халкыбызның үткәнен кайбер элгәрләренә караганда яхшырак белә. Шуңадыр алар милли тематикада үзләрен вәкаләтле итеп сизәләр.

Җирдә һәркем, халкым, диеп,
Тиеш ләса бер яныргa!..

*(«Ничәнче төн тынгы бирми...»)*

«Халкым» төшенчәсе шагыйрь Газинур Морат өчен төчелек төсмерендәге риторик сүз генә түгелдер. Дөрес, яхшатланып лаф орырга яратучы монафикъ затлар инде әлеге кыйммәтнең дә җелеген суырып баралар. Ә менә Газинур теле белән әйткәнне иңе белән күтәрергә һәрчак әзер. Бер генә мисал... Соңгы сулышын алып яткан СССР империясе үзенең гаргарәсенә якынлашкан чакта, 1991 елның гыйнварында, Газинур Моратка Ригада иҗат сәфәрендә булып кайтырга туры килде. Латыш халкының ирреген танклар ярдәмендә сытарга омтылу фаҗигасен безнең татар шагыйренә шаһит буларак күзәтергә язган икән. (Шушы канлы вакыйгалар тәэсирендә ул шигырьләр бәйләме дә язып кайтты.) Илдәге сәяси вазгыятьнең отыры киеренкеләнгән чагы. Шул исәптән Татарстанда да иҗтимагый җанлану сизелә. Халык тулы мәйданнарда «Азатлык!» шигаре моңарчы ишетелмәгәнчә көчлерәк яңгыраш ала. Дәүләт суверенитеты турындагы Декларацияне халык хуплавы белән ныгыту максатыннан, республикабызның рәсми-милли даирәсе кичекмәстән референдум оештыру хәстәрен күрә башлый. Мәскәү басымы көчәя. Җитмәсә, әле тиздән Русия президентын сайлау да үткәреләчәк. Мөстәкыйльлек юлыннан киткән Татарстан өчен мондый гамәлдә катнашу әзлеклелек кысасына сыямы? Юк, әлбәттә. Моның шулай икәненә тирәнтен инанган милләтпәрвәрләр төркеме, Ирек мәйданында чатырлар корып, 1991 елның маенда сәяси ачлык игълан итте. Мондый тәвәккәл адымга барган гаярьләр арасында шагыйрь Газинур Морат та бар иде. Ачлык тотуның да ярдәме тигәндер: Татарстанда Русия президентын сайлау ахыр чиктә барып чыкмады.

Алып буйлы халык идек юкса,
Яралган соң нинди каннан без?
Илсез калмас, телсез калмас өчен,
Ачлык тотар көнгә калганбыз...

*(«Ачлык»)*

Әле сиксәненче еллар башында ук «Үзгәрешләр көтәм, үзгәрешләр» дип белдергән Газинур Моратның сәяси таләпләр белән игълан ителгән ачлыкка кушылуын да, бездә моңарчы гайре табигый булып саналган шушы четерекле теманы җан-тән аша үткәреп, күләмле әсәр язуын да мантыйкый яктан аңларга мөмкин. Поэманың фикри йөкләнеше ниндидер максат белән ризык-тәгамнән баш тарту хәлләренә генә корылмаган, шагыйрь ачлык төшенчәсенә гүяки зурайткыч пыяла аша карап гомумиләштерүләр ясарга омтылган. Француз язучысы Альбер Камюның эпиграф рәвешендә бирелгән сүзләре дә әсәрнең идея юнәлешен алдан ук ачыклап куя шикелле: «Ирек хакына шәһит китү генә мәгънәгә ия була. Тик шул чагында гына кеше үзенең бөтенләй үк үлмәячәгенә ышана...»

Һәр аерым тема зур метафорага нигезләнсә, гадәттә, иҗатчы алдында тирән катламнар ачылып китә. Бу яктан «Ачлык» поэмасы да нәкъ менә шундый үзенчәлеккә ия. Эпик колачлы шигъри гомумиләштерүләрдә кайчандыр болгар бабаларыбызның урыс халкын ач үлемнән саклап калуы да, гасырлар буе кытлык-мохтаҗлыкта яшәгән илнең инде ачлыкка күнегеп бетүе дә, шулай ук ирланд егетләренең Лонг-Кеш төрмәсендә сәяси ачлык тотудан һәлак булуы да искәртеп үтелә. Юксыллыктан интегүче адәмнәрнең берсен-берсе ашауга кадәр барып җитүләре исә шул заманнарның җинаятьчел хакимияте турында катгый нәтиҗәләр ясауга китерә: «Ачлык-патша хуҗа тәхеткә...» Әсәрдә ачлык темасы, әйе, төрле яклап ачыла. Мең еллар ураза тоткан кавемнең ачлыкны җиңелрәк кичерүен икърар иткәндәй, шагыйрь иман юлыннан тайпылмыйча баруның әҗерле булуына да ишарә ясый. Поэмада татар башын татар ашау яки ана телен табада кыздыру кебек кинаяле гыйбарәләр дә төп шигъри метафораның киңлеккә һәм тирәнлеккә тармакланып китүе өчен астарлы фикри җирлек вазифасын үтәгән. Ә менә җирдә барысын да ашап киләчәк куркыныч Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ образын автор хисап көнен күздә тоткан кисәтү рәвешендә искә алгандыр кебек... Менә шулай үткәннәр аша киләчәккә ка-

раш ташлаган шагыйрь газиз халкының әлегә бүгенгесе өчен җаны-тәне белән борчыла: күпме сынау кичкән татар һаман ач, хәләл бәхетенә ач килеш кала бирә.

Күренә ки, шагыйрь Газинур Моратның күпкырлы иҗатында милләт гаменә һәрдаим өстенлек бирелә. Гомумән, аның хәтта шәхес буларак фикер йөртүе үк шушы бөек уйхис белән ашланган күк тоела: әдәби иҗатта да, иҗтимагый эшчәнлектә дә, көндәлек яшәештә дә... Бу яктан шагыйрь милләт җанлы зур шигъриятебезнең лаеклы варисы кыяфәтендә күз алдына килеп баса. Үтә сентименталь кебек күренгән мәхәббәт шигырьләрендә дә Газинур «сөюен йөрәккә күмгән» мәхзүн булып кала. Үзенең мөкәммәл стилен барлыкка китергәндә дә ул милләт мәнфәгатен алга сөргәндер төсле: инде әйтелгәнчә, газиз халкына хезмәт итүче әдипнең язу рәвешендә ана телен саклау җаваплылыгы да истә тотылырга тиеш. Кайбер нәтиҗәләр ясап әйткәндә, һәрдаим камиллеккә омтылып иҗат итүендә дә аның чын талантларга хас сыйфаты чагыла. Шагыйрь төрле жанрларда бердәй осталык күрсәтә, һәрбер шигъри әсәре тематика, шәкел-үлчәм, мелодика җәһәтеннән аерылып тора. Каләм әһеленең предметны белүе, гадәттә, архитектор материалының ныклыгына тиңләнә. Бу уңайдан Газинур Моратның теманы тирәнтен өйрәнеп язуы аның күздән кичерелгән «Ачлык» исемле поэмасында күренде инде. Кайбер көнүзәк мәсьәләләр көннең үзедәй үлүчән. Шагыйрь андый узгынчы вак-төяк темалар белән алай артык мавыкмый, алынган очракта да аларның иртәгесе көнгә караган мәгънәсен табуга ирешә... Кыскасы, Газинур Морат элгәрләреннән өйрәнә алырдайны яхшы итеп үзләштергән һәм әдәбиятыбызда үзенчәлекле урынын таба алган шагыйрь булып күзаллана. Хәер, остазларының хаҗәти йогынтысын ул үзе дә таный, шуның өчен аларга рәхмәтле икәнен дә сиздерә:

Алардан без гаять тә
Күпне алабыз.
Үзебезне тапкач кына
Үзебез булып калабыз.

*(«Үз-үзеңә...»)*

...Миңа бервакыт Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗминең Газинур Моратка язган хатын укырга туры килде. Чит хатлар белән кызыксыну гадәтем юк-югын, әмма монысында минем исем дә телгә алынган иде... Каләмдәшем хакындагы бәяләмә сүзләре игътибарымны аеруча җәлеп итте. «Хөрмәтле Газинур энем, — дип башлана 1999 елның 15 гыйнварында язылган әлеге хат. — Мин синең «Җир хәтере» исемле китабыңны укыгач та, синең хакта язарга «телем кычытып» тора иде. Менә хәзер «Түбә»не укыгач, тешемне «кайрап» куйдым. Яшьрәк чакта андый эшләр тиз эшләнә иде, хәзер энергия җитенкерәми. Китабың уйландыра, талантың һәр шигырьдән чәчрәп тора. Менә шуларны әйтеп бирергә көч җитәрме икән дип уйланып торам...»

Яшьрәк буын татар шагыйрьләренә карата аеруча хәер хаһлык күрсәтеп яшәгән аксакалыбыз, кызганыч, ихласлык белән белдергән әлеге теләген тормышка ашыра алмыйча китеп барды. Гомеренең соңгы елларында ул чир-сырхау эзәрлекләвеннән арынмады. Кызык, таланты һәр шигыреннән чәчрәп торган яшь каләмдәше турында әдәбиятта ат уйнаткан олуг шагыйрь ничек язар иде?! Хәзер инде аның әйтеп бирергә теләгән сүзләрен безнең колакларга фәрештәләре дә пышылдап җиткерә алмас. Әмма шулай да күңел сизенә, безнең күпчелек фикерләребез аваздаш булыр иде: Газинур Морат, һичшиксез, элгәрләре кайтавазын көчәйтүче талантлы шагыйрьләребезнең берсе.

*Зиннур Мансуров*

# ЭЧТӘЛЕК

## I БҮЛЕК

Вакыт безне ваксытмады бугай . . . 7
Галәми өн . . . 8
Шәмаил . . . 9
Канатлы барс . . . 10
Бу халык... . . . 10
Ил корабын күптән упкын йоткан... . . . 11
Хәтер көне . . . 12
«Булмаса халыкның...» . . . 13
Аран . . . 14
Моназара . . . 16
Сабак . . . 17
Сусанин . . . 18
Кистән . . . 19
Каза . . . 20
1995 ел, 9 май . . . 21
Балбаллар иле . . . 22
Чыпчык карагы . . . 23
Замана . . . 25
Карабах . . . 25
Кош хокукы . . . 26
Болгар . . . 27
Төнге Ригада латыш кызы белән сәяси сөйләшү . . . 28
Ачлык *(Поэма)* . . . 29
И Вакыт... . . . 42
Ул көн... . . . 43
Һәйкәлләр . . . 44
1942 елның кышында киселгән каенга . . . 46
Алма-риваять *(Триптих)* . . . 47
Имитация . . . 51
Кәсеп . . . 51
«Ятимнәргә — түбә булыйм...» . . . 52
Вакыт машинасы *(Поэма)* . . . 53
Литва мозаикасы . . . 64
Без — хәтер! . . . 70
Сүз тәме . . . 71
Былбыл . . . 71
Әкият . . . 72
Кабалану . . . 73

Табыш . . . . . 74
Сурәт турында баллада . . . . . 75
Һәм башкалар... . . . . . 76
«Ирек даулап...» . . . . . 78
Лонг-Кеш *(Поэма)* . . . . . 79
Тузга язылмаган сүзләр . . . . . 87
Кичәге көн батырлары . . . . . 88
Черек күл . . . . . 90
Сталинизм . . . . . 92
Әфганстан-79 . . . . . 92
Саескан һәм Прометей . . . . . 93
Туристлар . . . . . 94
«Күгәрченнәр гөрләшкәнен...» . . . . . 95
«Минем Дагыстаным»ны укыгач . . . . . 96
Кәрлә агач . . . . . 97
Тәкълид . . . . . 98
Кара базар . . . . . 99
Туфан . . . . . 100
«Кабаланмый гына учак яна...» . . . . . 100
Кояш баеганда килгән уй . . . . . 101
Автобиография . . . . . 102
Җыр кирәк . . . . . 103
Ишетәм дә... . . . . . 104
Ә хакыйкать арта... . . . . . 105
Аңлашасы бар . . . . . 106
Яз . . . . . 107
Поездда . . . . . 108
Тарих . . . . . 109
Үзгәрешләр көтәм . . . . . 110
XX гасырга эндәшү . . . . . 111
Мономах бүреге . . . . . 112
Тарихны киредән уку . . . . . 113
Кол . . . . . 113
Ырыс капка . . . . . 114
Биләрдә йөрдек би булып... . . . . . 115
Имла . . . . . 116
Холык . . . . . 117
Халыкара хәл турында . . . . . 117
Татар . . . . . 118
Тарих безгә сәер сер калдырган . . . . . 120

## II БҮЛЕК

Канатлы сүз *(Диптих)* . . . . . . 123
Тынычлану . . . . . . 126
Хәзерге хәлемезгә карата . . . . . . 127
Бар язганы . . . . . . 127
Сукбай . . . . . . 128
М.Ә. . . . . . . 129
Мөхәммәдъяр . . . . . . 130
Хемингуэйны уйлап . . . . . . 131
Дәрвиш . . . . . . 132
Җан сурәте . . . . . . 133
Йәгез, бер дога! . . . . . . 134
Кайтаваз . . . . . . 135
Урманда . . . . . . 136
«Тыңла әле мине...» . . . . . . 137
Сәяси сорау . . . . . . 138
Картлык . . . . . . 138
Сискәнү . . . . . . 139
Иҗат . . . . . . 139
Җете . . . . . . 140
Бала күңелле агай . . . . . . 141
«Җир гамьнәре тулы...» . . . . . . 142
Түбә *(Поэма)* . . . . . . 143
Әйттеләр . . . . . . 151
Бизмән . . . . . . 151
Соңгы мичче . . . . . . 152
Махмырдан язылган шигырь . . . . . . 154
«Соңгы юлга җыенганда...» . . . . . . 155
Гайса яше . . . . . . 156
Гәптәшләр . . . . . . 157
Шагыйрьнең кайтуы *(Баллада)* . . . . . . 158
Әсирлек . . . . . . 160
Таш . . . . . . 161
Әтрәк-әләм . . . . . . 162
Туган йортта балан җыйганда . . . . . . 163
Кол булганчы... . . . . . . 164
Кол Гали сурәтенә карап бер юану . . . . . . 164
Дилемма . . . . . . 165
Карт мәче . . . . . . 166
Шагыйрь . . . . . . 166
Юралмаган төш . . . . . . 166

Әти портретына штрихлар *(Триптих)* . . . . . . . . . . . . . . 167
Кораб . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Чингачгук . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Мәҗүси уй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Югыйсә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Бераз Толстойчарак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Ә шулай да... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Кем аңлар? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Архимедка эндәшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Күләгәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Авылдаш имәнгә мәрсия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Метаморфоза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
О' Генри . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Мигель Эрнандеска, көтүчегә һәм шагыйрьгә . . . . . . . . . . . 181
Тукталышлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Аэропорт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Мунчада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Мин дә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Хөкем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
«Дөрес кенә яшәп булса икән...» . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Алдакчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Кумирлар шәһәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Батырлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
«Ут төрткәннәр җәйгә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Ялалы көз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Уйчан еллар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
«Без — тулпарның дүрт тоягы...» . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Мәкальнең дәвамы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Әй балачак хыяллары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Сабан туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Тыңлап кара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
Археолог . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199
Көзге бакча. Сукмак. Алтын келәм... . . . . . . . . . . . . . . 200
Элегия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Парадокс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Бакчачылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Әкрен генә эри канатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Хәсән Туфанга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Декабрь-79 . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
Һаман бер сорау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Йөзү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Сау бул, Кояш, таңга чаклы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208

Тамыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Казан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Мин — язнықы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
Үлчәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212

### III БҮЛЕК

Төнге әверелеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Сынчыбагар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
Мәңгелек үкенеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Ялгызлык исемле кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . 218
Бәла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
Әйтеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
Аңлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
Кунак ашы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
Көнделнең бер көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
«Мин әкият кебек» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 223
Карт Отелло . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
Идиллия. Күкеле сәгать . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Ялгызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226
Яратырга телим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Печән өсте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
«Ник чыкмадың каршысына...» . . . . . . . . . . . . . . 229
Сөю атлы чаптарга алдан язылган мәрсия . . . . . . . . 230
Эмансипация . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
Олыгаю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
«Әллә сөеп горур булдык...» . . . . . . . . . . . . . . 233
Элегия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
«Былбыллар читлектә елый...» . . . . . . . . . . . . . . 235
Ялгыз карт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Соль мажор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Без адаштык бугай... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
Ә мин сине яратмаска булдым . . . . . . . . . . . . . . 238
Талак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
Урам кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Сәрхуш хатын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
31 декабрь-76 . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Мине шагыйрь иткән кызга . . . . . . . . . . . . . . . . 243
«Күзләреңнән серле мәгънә эзләп...» . . . . . . . . . . 243
Ялвару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
Без яраткан ярлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
Экстаз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Җан эреткеч ләйсән ява . . . . . . . . . . . . . . . . . 247

«Елмай, сеңлем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Төнге этюд . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Бер тәэссорат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Манзара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Дүрт мизгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Әллә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Әй, кызый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
«Тел очымда тора...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
Көзге этюд . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
Хәтернең ак дивары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
Хәтердә калган сурәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255
Үгез елы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Нәтиҗә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 257
Ямьсез хатын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
Үзең бел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 259
Элегия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 260
Мәрхәмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 261
Сине уйладым бүген дә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 262
Хатыңны алгач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 263
«Мәхәббәткә нәфрәт җырлаганнар...» . . . . . . . . . . . . . . . 264
Сине каршылаганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
Кышкы төндә язгы бер уй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 265
Аэропортта көз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
Айну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
Тимерче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 267
Сагаймагыз, ярлар!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
«Җирем — адәми затларсыз...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 269
«Сөюең елап, кул болгап...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 270
Сөймә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 271
Ятим көннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272
Ландыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
Триптих . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
Син . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
Хәерле юл телә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
Син вә мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 276
Чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 277
Ә син төнне ярып пышылдыйсың . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Сагышлы йолдызлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
Сәнгать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
Әгәр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
Сөюнең ал тирмәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
Сагынмыйм да, юксынмыйм да . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282

Гел яманга юрадылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283
Карт һәм алтын балык турында янә бер шигырь . . . . . . . . . 284
Ул кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Картаела, ахры... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Көянтә ясаучы зары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
Таныш түгел бер сылуга . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
Кара хатын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
Шахтер агай җыруы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
Төнге идиллия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290
Аччы, туташ, ишегеңне... . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
Нәркиз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
Аңласа... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
Сине сагынганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292

## IV БҮЛЕК

Бөекләргә таянабыз... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 295
Бәет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 296
Сәрхуш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
Эпитафия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
Типке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
Останың китүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Нигез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Дәрдемәнд кабере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 301
Интернет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 302
Йөзьяшәр карт сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 302
Син хаклыдыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 303
«Кошлар китә кәрван-кәрван...» . . . . . . . . . . . . . 303
Караклар *(Монологлар)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 305
Диптих . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 307
Ирекле шигырь турында . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
Карт һәм чабак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 309
Көпчәк мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 310
Иясез иялэр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 310
Антисемит . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 311
Дин турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 311
Каударланма, каләм... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 311
Дәгъвачы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
Сюрреалист . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
Тоталитаризм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Яңа эра тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Тәүбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
Моңсу шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 315

«Бу янулар яну түгел әле...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 317
Әйтә идем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
Мин киткәндә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 319
Ялгызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 320
Җәлил һәйкәле янында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 321
Гыйбрәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 321
Шикаятьче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 321
Азан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Халык хәстәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 324
Кыш. «Болгар» чатында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 325
Элегия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 326
Йорт казлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
Аюдаг . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328
«Гамьнәр таләп иткән җаның...» . . . . . . . . . . . . . . . 329
«Теләсә дә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Ни әйтим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Яран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 330
Аран. Мәхбүс ат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Кыска шигырь турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Зәвык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Метаморфоза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 332
Заяга узган көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 333
«Таң каршында басып торам...» . . . . . . . . . . . . . . . . 334
Көз. Кошлар өне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 334
«Кемнәр, әйдә, хөсетләнсен...» . . . . . . . . . . . . . . . . 335
Төрле сүзләр йөри . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 335
«Алкышларны аз эчмәде яшьлегендә...» . . . . . . . . . . . . 336
Пушкинны уйлап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 336
Яшиләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 337
«Бөекләр хакында илдә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 337
Шагыйрь авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 338
«Һәркем үзенчә тәхетле...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 339
Янәшәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 339
Халык осталары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
Педант . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 341
Сөләйман патша сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Иң яманы... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Үрмәләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 343
Татарча язу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 343
Китап базары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
«Шәһәр ташларына башың куеп...» . . . . . . . . . . . . . . 346
Хәтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 346

«Сәхнәдә чынлап яшәде...» . . . 347
Күрәзәче карчык әйтте миңа . . . 348
Язмыш . . . 349
Юк . . . 350
Сукбай эт . . . 351
Низаг . . . 351
Көй чакыру . . . 352
Фатир көтә ирләр . . . 353
Ә сәрхушлек безнең — язмыш, ахры... . . . 354
Эчке диалог . . . 355
Курчак театрында . . . 356
Автопортрет . . . 356
Сәер кешегә ихластан язылган мәрсия . . . 357
Юл чатындагы кибет . . . 358
Талчук . . . 359
Мин риза . . . 360
Чират . . . 361
Борынгы шәһәрдә яз . . . 362
Атом-кирмән *(Поэма)* . . . 363
«Мин каладан кайткан кеше...» . . . 373
Атлар . . . 374
Карт сәгать . . . 375
Казан. Черек күл буенда . . . 375
Моңсу шатлык . . . 376
Көзгә мәдхия . . . 377
Кайту . . . 378
Минсез генә... . . . 378
Чичәннәр кайтавазын кемнәр көчәйтә. *Зиннур Мансуров* . . . 379

Литературно-художественное издание

Муратов Газинур Василович
*(Газинүр Морат)*

**НОЧНАЯ МЕТАМОРФОЗА**

Стихи, поэмы

(на татарском языке)

Редакторы *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 7.06.2005. Форматы 70×108 $^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе.«School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 17,5.
Шартлы буяу-оттиск 17,85. Нәшер-хисап табагы 12,04. Тиражы 2000.
Заказ А-430.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.